# Әлфия Авзалова

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2007

УДК 821.512.145-3
ББК 84(2Рос=Тат)-4:85.364.1

Төзүчесе
РАБИТ БАТУЛЛА

Рәссамы
РУШАН ШӘМСЕТДИНОВ

Әлфия Авзалова**:** истәлекләр, әңгәмәләр, мәкаләләр, фоторәсемнәр / Төз. Р.Батулла. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. — 214 б. — 3000 д. — ISBN 978-5-298-01533-2

Теле ачылганнан бирле татар милләтенә армый-талмый хезмәт итүче бөек сәнгатькәребез — Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисткасы Әлфия Авзаловага багышланган бу китапта аның катлаулы тормыш юлы, вакыйгалары һәм сынаулары мул булган иҗат биографиясе тасвирлана.

ISBN 978-5-298-01533-2

© Татарстан китап нәшрияты, 2007
© Батулла Р. М., төзү, 2007

УДК 821.512.145-3
ББК 84(2Рос=Тат)-4:85.364.1

**_Бәхет кошын тоткан кыз_**

*Сабый чагыннан ятим калып, тормыш төбеннән күтәрелгән, үз бәхетенә үз таланты белән юл ярган Әлфия Авзалова — Гөлсем Сөләйманова, Фәридә Кудашева, Рәшит Ваһапов, Илһам Шакировлар кебек данлыклы сәнгатькәрләр сафына баскан, татар җырын яңа эстетик югарылыкка күтәргән шәхесләрнең берсе.*

*Халкыбызның, Нәкый Исәнбәтчә әйтсәк, меңьеллык гүзәл җырчылык традицияләре, аның җырларының үз милли формасы, үзенчәлекле аһәңе бар. Әлфия Авзалованың йөрәгеннән кайнап чыккан җыр сәнгате — милләтебез күңел хәзинәсенең, гасырлардан гасырларга күчеп килгән рухи байлыгының тугры дәвамы ул. Җаны белән халкыбыз җанына тыгыз бәйләнгәнгә күрә, аның илһамлы иҗаты халык күңелен бер сулкылдатып, моңландырып, бер җилкендереп, рухландырып, хөрлеккә, сафлыкка, тормышның ямен-тәмен татып яшәргә, яратырга, яратылырга өнди.*

*Әлфия Авзалова — милли, рухи байлыгыбызның бөеклеген халыкчан аһәңе, ялкынлы, дәртле таланты белән чагылдыручы, киң катлау тамашачыларына бик юмарт җан азыгы өләшүче сәнгатькәр. Аның төрки халыклар арасында популярлыгы, аңа миллионлаган тамашачыларның мәхәббәте һөнәри осталыгы, репертуарының байлыгы, үзәкләргә үтә торган моңы, туган илебезгә, туган җиребезгә карата тирән горурлыгы белән аңлатыла дип беләм.*

*Минтимер Шәймиев*

## МӨХӘММӘТ МИРЗА

* * *

Ак пароход көтеп алдым,
Бөдрә талга сөялеп.
Юлга алдым җырларымны,
Китим әле төялеп.

Җырга сусаган җаннарның
Сусавын ник басмаска?
Пароход куласасы да:
— Җырла, җырла, — ди ләса.

Кара бөрлегән җыйдым ла,
Кызыл бөрлегән җыйдым.
«Бөрлегәнем, бөрлегәнем,
Бөрлегәнем», — дип җырлыйм.

Кәккүк тавышын санадым,
Сөялеп киртәләргә;
Кәккүк дустым әйткән иде
Юл чыгасын иртәгә.

Алмагачның ботагында
Сайрый сары сандугач;
Сандугачтан ник көнләшим,
Мин үзем дә карлыгач (сандугач).

Күзләрем дә кара гына,
Кашларым да чем-кара;
Күңелемдә бер кара юк,
Җырымны тыңлап кара.

Җырымны тыңлап кара син —
Әҗәл даруларымны.
Сиңа гына бүләк итәм
Сулыш алуларымны.

Чиләкләрем мөлдерәмә лә,
Суы чайкала инде.
Сиңа дигән җырларым да
Кала, һай, кала инде!

Кайтуын кайтырсың ла,
Көтеп торучы булса.
Җыларсың да, җырларсың да,
Күңелкәйләрең тулса...

Кирмәнчек тавы ком гына,
Ком булса да гөл үскән.
Күңелем тулы моң гына, —
Мин шул әнкәсез үскән.

Актаныш — Әлем арасы —
Тау менәсе-барасы.
Язмышыма язылгандыр
Караның да карасы.

Ат юлы — алты чакырым,
Атлыйм җәяү, ялгызым.
Җәяүләп чыккан буран да
Бара икән, җыр суза!

Ертылып беткән бишмәтнең
Итәгеннән җыр тарта;
Тишек, тузган чабаталар
Үземә җыр тыңлата.

Җыр шыгырдый — карга бассаң,
Чана тартсаң — җыр чыга;
Кое чыгыры җырына
Кушыл да җырла гына.

Ачлык җырлый, күзләр җырлый —
Җыр дәвамы күз яшьле.
Җырсыз булсаң, тук булсаң да,
Матур булмас ул яшәү.

Кырлач көен, Ыспас көен,
Челлә көен тыңларга,
Мин күнеккән дүрт яшемнән
Җилгә кушылып җырларга.

— Борыл! — диеп, ач ятимлек
Арттан чаба, чакыра...
Борылмамдыр,
Җырлар җырым
Казаннарга чакыра!
Борылмамдыр, монда дуслар,
Якыннарым булса да,
Монда елап калса да...

Пристингә озатып килгән
Җырдашларым, каласыз;
Каласыз инде, каласыз,
Мин калалмыйм — чарасыз...

Агыйделдә туып үскән,
Шунда пешкән җиләк мин;
Замана ятим итсә дә,
Кем өчендер кирәк мин!

Бу заманны хурлыйсылар,
Зурлыйсылар бар әле.
Мин заманны узып җырлыйм:
— Килер көнем ал да гөл (алдале)!

Җырларымда Актанышка
Мин әйләнеп кайтырмын.
Әргәнештә, алсуланып,
Җыр-таң булып атармын!

— Сандугач кайткан! — диярләр
Кызлар, кер чайкаганда,
Әргәнештә өр-яңа җыр
Тугайны айкаганда.

Кибән куйган ир-егетләр

Туктап нидер уйларлар,
Тыңларлар да кибәннәрен
Җырдан коеп куярлар.

Пароходның яңакларын
Үбеп ала дулкыннар, —
Туган яктан аерылу
Җырын җырлый ич алар.

Кузгалаклы балачагым,
Тузганаклы балачак,
Әнкәйләрсез балачагым,
Әкият тулы балачак.
Моң-сагышлы балачагым,
Җырлы-көйле балачак
Елап монда калачак.
Бала җаным, бала акылым —
Гомерлеккә калачагым —
Үзем белән барачак.
Җырларымда яначак!!!
Җырларымда яначак!!!

**РАБИТ БАТУЛЛА**

# Якты йолдыз гасырларда балкыр

Карамый калалмадым шул,
Күзләрем алалмадым:
Җансызга җаннар бирә ич
Елмаеп карауларың.

*Х.Туфан*

Татар халкында мәшһүр хатын-кыз җырчылар аз түгел. Әмма Әлфия Авзалованың мәшһүрлеге аерым бер могҗиза. Аның иҗат гомере бар җырчыларныкыннан да озынрак булып чыкты, шөкер. Салкын яңгырларда, кышкы бураннарда ягылмаган клубларда, СССРның бөтен почмакларында җырлап та, тамагына катлаулы операцияләр ясатып та Әлфия ханымның тавышы кимеми. Кайсы халыкта бар шундый могҗизалы җырчы? Аның бу фидакарь хезмәте хөкүмәт тарафыннан да, халкыбыз тарафыннан да югары бәяләнде. Ул Татарстанның халык артисткасы, Россиянең атказанган арисҭкасы, ике тапкыр Кызыл Байрак ордены һәм бихисап мактау кәгазьләре алган кеше.

Әлфия Авзалова — Актанышның горурлыгы, ләкин Актанышныкы гына дисәк, башка якларны рәнҗетербез кебек. Бер Актаныш кына түгел — Әлфия апа белән бөтен татар милләте горурлана. Һөнәри эстрадада гына да 55 ел өзлексез җырлаган, һәвәскәрлекне, агитбригадалар белән хезмәтен дә санасаң, 63 ел сәхнә тоткан җырчы ул Әлфия ханым. Андый сәнгатькәре булган халык үлемсез.

Әлфия Авзалова 1933 елда Татарстанның Актаныш авылында дөньяга килә. Аңа язмыш кечкенәдән ятимлек әзерләп куйган, күрәсең, 5 яшендә аның әнисе үлеп китә. Болай да гаиләсенә игътибарсыз булган әтисе балаларын бөтенләй ташлый. Ятим калган ике кечкенә кызчыкны әнисенең апасы Закирә алып китә. Ләкин язмыш аны монда да озак тотмый, ул балалар йортына килеп эләгә... Ләкин ачлык, ялангачлык, ятимлек кызчыкны сындыра алмый, ул атаклы җырчы булып китә.

Шушы могҗизалар ясаган атаклы җырчыбыз турында бер метр да документаль фильм төшерелмәгән әле. Кем төшерергә тиеш ул фильмны: телевидениеме, киностудияме? Бу эш белән кем турыдан-туры шөгыльләнергә тиеш? Филармонияме, Җыр һәм бию ансамблеме? Мәдәният министрлыгымы? Кем?

Атаклы сәнгатькәребезнең кыяфәте, җырлау рәвеше, аның үзе сөйләвендә башыннан кичкәннәре, уйфикерләре киләчәк буыннарга калмый бит... Әлфия Авзалова турында тулы метражлы фильм төшерер өчен без ни эшләргә тиеш? Шул фильмны төшерсеннәр өчен Әлфия Авзалова тагын ничә ел җырларга тиеш?

Чыннан да, киноны төшерергә кирәк, анысы шиксез. Киносы булганчы, аның турында китап язарга кирәктер. Шул китап кинофильмның нигезенә ятачак. Әйе, 1995 елда Әлфия Авзалованың «Үзем турында» исемле китабы дөнья күрде. Ләкин ул гына аз.

Минем гаиләм атаклы җырчы Әлфия ханым белән ишеккә-ишек күрше булып торды. Күршеләр буларак без бик еш аралаштык, кунакка йөрештек. Аның өендә кунаклар күп булса, Әлфия апа йокларга безгә керә, безнең өйдә урын калмаса, без Әлфия апаларга кереп кунабыз. Кич утырабыз, аулак өй ясыйбыз. Шушы кич утыруларда мин магнитофонны әйләндереп җибәрәм яки видеокамера белән кич утырганны тасмага төшерә барам.

Сөйләшүләрнең төгәл системасы булмый торган иде. Сүз иярә сүз чыкканнан, башка ни килә, телгә ни төшә, шундый өзек-төтек хатирәләр, мәзәкләр магнитофонда да, видеотасмада да, куен дәфтәрендә дә байтак җыйналган.

Бу язмаларны кәгазьгә төшергәндә, вакыйгаларның эзлеклелеген тәртипкә салмадым, ничек язылган, шулай биреләләр. Тик кайбер бүлекләр (бигрәк тә баштагы хатирәләр) магнитофонга да, видеога да язылмаган, бары тик хәтердә генә сакланганнар. Андый өлешләрне мин Әлфия ханым сөйләгән тәэсирдә «әдәбиләштереп» яздым. Ләкин Әлфия апаның сөйләү үзенчәлеген дә сакларга тырыштым. Ул Актаныш ягындагыча сөйли, туры сөйләмдә мин шул аһәңне сакларга булдым, шуңа күрә хөрмәтле укучым мине Ана теленә игътибарсызлыкта гаепләмәс дип өметләнәм. Төбәк сөйләмнәре дә Ана телебезнең бер кадерле парчасы бит.

Әлфия апа ул — мәзәк сөйләү остасы. Туганнары, якын танышлары утырган табын янында Әлфия Авзалова булса, көт тә тор, кич буе халык күңеле булганчы көләчәк. Ул үзе белән булган аяныч хәлләрне дә, башкалар турында да көлке итеп сөйли белә. Аның мәзәкләре кайвакыт пародиягә әверелә, кайвакыт ул матбугатта язарга ярамаган хәлләр турында да сөйли. Башка бер хатын андый мәзәк сөйләсә, әдәпсез булып күренер иде. Әлфия Авзалова сөйләвендә алар көлке чыганагы була.

Җае чыккан чакта, Әлфия ханым ишетелер-ишетелмәс кенә моңлана башлый. Ул кычкырып җырламый, ул шушы бүлмә эчендәгеләргә генә моңлана, аның бу моңлануы нинди дә булса сагышлы хатирәләр-

гә ияреп уйлануы булса кирәк. Аның шулай моңлануы табындашларга гаять көчле тәэсир ясый, хисләр ташкыны күз яшьләре булып бәреп чыга.

Әлфия Авзалова — серле шәхес. Ул серләрне ачар өчен, ул яшәгән гомерне яшәргә, аның белән янәшә атларга кирәк. Җырчының моңы серле, таланты серле, ул серләрне Әлфия Авзалова үзе дә аңлый-аңлата алмас иде, мөгаен. Без дә аңлый алмабыз, ихтимал. Әмма аңларга тырышып багарбыз!

Шулай итеп, китапны ачабыз.

Бисмилләһ-ир-рахмән-ир-рахим...

# Дуслык

Бу сөйләшү 1996 елның көзендә Зәй шәһәрендә булды.

Янарлык утың барында
Әйдә ян, дөрлә, йөрәк.
Якты да безнең заманга,
Җылы да күбрәк кирәк!

Әйдә ян, дөрлә, йөрәк...
Әлфия безгә кирәк!
Әйдә ян, җырла күбрәк!

*Х.Туфан*

Әлфия Авзалова белән Рәшит Хәмәдиевнең дуслыгы күптәннән дәвам итә. Кайда гына эшләмәсен, Рәшит Хәмәдиев Әлфия Авзалованы, бер бәйрәмнән калдырмыйча, табын түренә чакыра килде. Җырчыбыз Әлфия ханым Зәй авылларында бик еш була. Концертлар куя. Халык аны алкышлый.

Без Зәй төбәгенең хакимият башлыгы Рәшит Хәмәдиев бүлмәсендә.

Р.Батулла. Рәшит әфәнде, сез җырчы Әлфия Авзаловага аеруча игътибарлы була килдегез. Менә әле бүген дә Әлфия ханым Зәй авылларында йөри, сез аңа ун концерт куярга рөхсәт биргәнсез. Башка җырчылар бер-ике концерт куйса, Әлфия ханымга уннан да ким түгел.

Р.Хәмәдиев. Батулла дус, мин бит билет сатмыйм. Һәр артистка мин мөмкинлек бирәм: килсеннәр, куйсыннар, уйнасыннар, җырласыннар, биесеннәр. Халык кассадан үзе билет алып залны тутыра икән, унны түгел, егерме концерт куйсалар да сүзем юк! Әлфия ханым килә, залы шыгрым тулы була. Ул ун концерт куярга тиеш иде, алтысы зур уңыш белән узды. Ләкин мин аның гастрольләрен өзәргә кирәк дип табам. (Сәет углы Рәшит әфәнде табын янында утыручы җырчыга карап.) Әлфия апа, синең авыруың көчле. Сиңа тизрәк операциягә барырга кирәк. Чит илгә барып дәваланырга кирәк.

Президентыбыз да ярдәм итәр, син аңа лаек шәхес. Аның сәнгать кешеләренә ярдәм итми калган чагы юк.

Әлфия. Дөрес, энем, ул хөкүмәт башына килгәч, сәнгать кешеләре иркен сулап куйды, Аллага шөкер. Үтенеч белән кергән кешене буш кул белән чыгарганы юк.

Рәшиткәем, әле бит минем авыруым турында берәү дә белми, халык белми. Минем иң якын кешеләремнең берсе — Хәмәдиев кенә белә. Минем концертларым бар бит әле Зәй авылларында.

Р.Хәмәдиев. Булса булыр. Концерт качмас, Әлфия апа, синең сәламәтлегең биш-алты концерттан кадерлерәк, сәламәтләнгәч килеп җырларсың. Мин сиңа ныклап әйтәм, үпкәләмә. Тиз генә Казанга кайт. Яхшы докторларга күрен. Киявең зур врач, ул да карасын. Син халыкка кирәк, син яшәргә тиеш!

Чыннан да, Әлфия апа, Рәшит әфәнденең киңәшен тотып, гастрольләрен өзеп, Казанга кайтып китте.

# Каен җиләге

Бүтән бер сүз өсти алмыйм
Мин шушы язганыма:
Татар Моңы Алиһәсе —
Әлфия Авзалова!

*Л.Лерон*

1996 елның азакларында Әлфия Авзалованың кинәт кенә тавышы бетте. Әлфия апа моны «юлда салкын тидердем, шуныкы гына» дип юрады. Ләкин тавышы кимегәннән-кими барып, җырлау түгел, хәтта ул бөтенләй сөйләшә алмас дәрәҗәгә җитте. Табиблар Әлфия Авзалованың балаларына, якыннарына җырчыбызның тамагында яман шеш барлыгын әйттеләр. Бөек җырчыбызның гомере өч-дүрт

ай, күп дигәндә бер ел гына калган, дип котны алдылар. Әлфия апаның кызы Зөлфиянең ире — Равил Нигъмәтҗанов — үзе дә табиб кеше, җырчыны коткару эшенә кереште.

Хуҗабикә Рузия ханым Әлфия Авзаловаларга кереп китте. Бераздан чыкты да:

— Карале, — диде. — Әлфия апаның бер дә кәефе юк. Ул күңелсез уйларга баткан, аны чәйгә дәшик, авыр уйларыннан бераз аерылып торыр.

Хәл ителде. Әлфия апаны кунакка чакырдык.

Әлфия апаның тавышы карлыккан, аның тавыш сеңерләре авыру, көчкә генә сөйләшә. Табын янына килгәч, ул пышылдап кына сүз башлады:

— Унлап врач карыйлар да чыш-пыш сөйләшәләр, карыйлар да чыш-пыш... Беттем мин... Егерме бер көн бит. Хәлем юк... Ютәл басты.

Рузия. Уза ул, Әлфия апа... Син тәрәзә кырына, җил өрә торган җиргә утырма, менә монда утыр. (Рузия ханым Әлфия апаның җилкәсенә мамык шәл сала.)

Батулла. Бөркән зәңгәр шәлеңне, Мәйсәрә.

Әлфия. Булырсың монда Мәйсәрә, җырлау түгел, сөйләшергә дә тавыш калмады.

Рузия. Әлфия апа, син үзеңне сакламыйсың бит... Бүген әче җил, син муеныңа шарф та салмагансың, бияләй дә кимәгәнсең, урамнан барасың, яшь кызмыни!.. Тунының бер төймәсен генә каптырган да бара...

— Минем каты чирләгәнем булмады, — диде ул, елмаю аша. — Несмыкание (тавыш җепселләре, тамак сеңерләренең шешүе, ялкынсынуы. — *Р.Б.)* белән дә мин айлар буе җырлап йөри идем, больничныйга чыкмадым... Магаданга чаклы барып җитеп, больничныйга чыксаң, җир убар, өзми идем гастрольләрне. Минем ятып авырганым булмады, менә беренчесе, яткызды бит, мәлгунь, куркыта, малакаем. Әнә шул несмыкание белән айлар буе җырлаганнарның нәтиҗәседер инде бу тамак рагы. Үлемем шушы икән дип уйлыйм.

— Юк, Әлфия апа, әле яшибез, Алла боерса! — дип, кунакны юатабыз.

Рузия, каен җиләге кайнатмасы чыгарып, кунакбикә алдына куя.

Рузия. Каен җиләге белән чәй эч, Әлфия апа. Кыш уртасында каен җиләге белән чәй эчсәң...

Әлфия апа аның сүзен дәвам итә:

— ...җәннәткә эләгерсең, ди...

Көлешәбез. Әлфия апа да елмая.

Батулла. Рузия ханымның үз куллары белән җыйган каен җиләге, Әлфия апа, шифасы чиксез. Аша! Каен җиләге белән мәтрүшкәле чәй эчәбез.

Каен җиләгенең шифасы кагылды бугай, Әлфия апа иркенәеп китте. Аңа бераз хәл керде. Юк-бар авыру гына Әлфия Авзалованы аяктан ега алмый, димәк, эш җитдирәк, шулай да Әлфия апа бездә байтак утырды, тагын чәй яңарттык. Табын янында ул башыннан кичкәннәрнең барысын да безгә сөйләде. Сөйләү түгел иде ул, әчке монолог, аның үзе белән, яшь чагы белән сөйләшүе, узганнарның моңсу хатирәсе иде. Соңыннан гаиләбез белән аны ишеге төбенә хәтле озатып куйдык.

## Беренче кинотасма

Гүзәл дә түгел кебек син,
Чибәр дә түгел кебек.
Ямьлерәк ләкин барыннан
Синдәге сөйкемлелек.

*Х.Туфан*

Әлфия Авзалова хастаханәгә кереп ятты. Дөнья хәлен белеп булмый. Видеокамера алып аның янына киттем. Камерага ничек төшерелгән, сөйләшү шулай бирелә. Әлфия апа иреннәре белән генә сөйләшә. Аның хәлен белергә Зәй хакимияте башлыгы Рәшит Сәет улы Хәмәдиевнең ярдәмчесе Рәис Нәҗипов та килгән. Бу 1997 елның 18 гыйнвары иде.

Әлфия апага сөйләшергә ярамый, аңа операция ясарга әзерлек бара. Ләкин ул табиблар кушканга буйсына торган хатын түгел, барыбер сүзгә катнаша:

— Зәй ягы бит ул... Зәй кебек матур җир юк дөньяда. Зәйдән чыккан язучылары гына да ни тора, җүләр! Зәйнең хуҗалары ни тора! Рәшите белән Рәисе алтын бәясе, җүләркәем. Аларны бер күрсәң, авыру булсаң, шундук тереләсең. Аларның ачык чырайларына, якты йөзләренә карап сикереп торасың, валлаһи. Рәхмәт аларга! Кунакчыл халык! Өч концертка дип килсәм, унбишне биреп китәм мин Зәйдә.

— Әллә, мин әйтәм, Зәйгә бер йорт салып, шунда яшәргә кайтасыңмы? — дим.

— Исәп шулай иде дә бит... — ди Рәис Нәҗипов.

— Алай булмас инде, — ди Әлфия ханым.

— Яңа йортка күчендең, Зәйгә китмәссең инде, — ди Рәис.

— Күчми идем мин ул йортка, анда Батулла тора, диделәр. Йөгердем хуҗаларга. Биргән акчагыз бар төзелеш өчен, акчагызны кире алыгыз, Батулла гаиләсенә күрше булып күченәм, дидем. Күчендем, күршеләрем әйбәт. Ипи-тозга гына түгел, үземә кунаклар күп килгәндә, мин аларга кереп йоклыйм, алар миңа керә. Бергә-бергә гомер итсәк иде, Ходаем!

Батулла. Әлфия Авзалова белән күрше булу теләсә кемгә тәтеми ул.

Рәис. Безгә дә бик җайлы, Әлфия апа да, Батулла да бер йортта...

Батулла. Әлфия апа, соңгы концертларың кайда булды?

— Зәйдә җырладым... Аннан Тукай районына илтеп куйдылар. Ике тарафта да бик зур уңышлар белән концертлар куйдык, Аллага шөкер. Яңа ел алдыннан...

— Әлфия апа, ничә ел җырладың инде син?

— Кырык биш ел булды, кырык алтынчыга китте.

— Бу профессиональ сәхнәдәме?

— Профессиональ сәхнәдә.

— Болай да җырладың бит инде син, әйтик, ничә яшьтән җырлый башладың?

— Анысы бит аның башка... Анысы икенче сыйныфта бит аның...

— Икенче сыйныфта сәхнәгә чыгыпмы?

— Ие инде. Бишенче, алтынчы, җиденче сыйныфларда ук җырлый идем инде. Агитбригада белән йөрдем Актаныш авыллары буйлап... Казанга шомарып килдем инде мин. «Кәккүк»ләрне, «Гөлҗамал»ларны җырлап...

— Әлфия апа, син үзеңне уникаль, даһи шәхес дип таныйсыңмы?

— Мин аны яшь чагымда белмидер идем, дөресен генә әйтим, шуннан белегез, үземдә бер генә пластинкам да юк, бөтенесе кешедә. Таратып бетердем. Үземнең җырымнан мин бервакытта да риза булмадым. Ошамый җырлавым. Бүген бик күп җырчылар җырлый, тасма әйләндереп, ә минем шул тасмам да юк. Кассета да юк. Шуннан уйлап кара инде, мин үземне зур итеп санамадым. Олыгая башлагач, үземнең җырларымны тыңлыйм да уйлап куям: нинди киң сулыш, нинди тавыш! Соңгы елларда җырлаганнарымны да тыңлап карыйм. Аллага шөкер! Барысы да үз урынында!

— Һәркемнең үз остазы бар, әти-әнисе остаз яки укытучысы була дигәндәй, кем синең остазың?

— Актанышта багана башындагы (районга бер генә радио иде бит) радиодан Гөлсем Сөләймановны тыңлый идем. Бәләкәй генә мин кызчык, Гөлсем апа җырлап бетергәнче, баганага сөялеп басып торамын. Аннан Зифа Басыйрова килеп чыкты. Аны йотлыгып тыңлыйдыр идем. Икесен дә бик нык яраттым. Опера җырчыларын да яратам мин. Хәзерге опера җырчыларыннан Зилә белән Венераны мин беркемгә дә алыштырмыйм. Хәтта вафат булган данлыклы җырчыларга да.

— Татар халкының җырчылары тарихта күп булган. Әйтик, Фәттах Латыйпов, Камил Мотыйгый, Газиз Әлмөхәммәтов, Рәшит Ваһапов, Усман Әлмиев һәм башкалар бик мәшһүр җырчылар иде. Ләкин шул мәшһүрләр арасында аеруча дан яулаганнар сирәк. Җырчы үз заманасында вакыйга ясаса гына даһига әверелә. Вафатыннан соң да аның турында риваятьләр сөйлиләр. Җыр сәнгате өлкәсендә вакыйга ясаган артистыбыз Гөлсем апа Сөләйманова булды. Рәшит Ваһапов татарның җанына, бәгыренә үтеп керә алды. Аннан соң — Илһам Шакиров!

— Менә мине олы җырчыга санасагыз, Әлфия апагызны да вакыйга ясаган артистка дип уйласагыз, мин сезгә шуны әйтәмен: мин җырларга Илһам Шакировтан өйрәндем. Аның матур бормаларын кабатларга, аның милли аһәңен тотып алырга тырыштым. Илһам олы җырчы гына түгел, ул әле остаз да бит. Аңа охшарга тырышалар, аңа охшатырга тырышалар. Аннан өйрәнәләр. Кызганыч, Илһамдагы кебек ул милизмнар башка берәүдә дә күренми әле... Мин шунысына шаккатамын, Илһам җитмеш яшенә якынаеп килгәндә дә тавышын югалтмады. Югыйсә ул режим белән дә яшәмәде. Тавышымны саклыйм дип, җылы өенә бикләнеп тә утырмады, кышкы салкыннарда, җәйге яңгырларда да җырлады. Ә тавышы — саф. Гайрәте кайтыш түгел. Моны могҗиза дими ни диярсең?

— Иң яраткан җырың?

— Бала вакытымнан ук «Кәккүк»не яраттым. «Кәккүк кызы» дип чыгардылар гәзиткә язып... 1957 елда. Ахунҗанов исемле кеше шулай мактап язды, мин ул Ахунҗановны белмим, күргәнем булмады, әмма «мәкаләсе төпле» дип сөйләделәр. «Кәккүк», «Гөлҗамал», «Казан сөлгесе», «Болын»... Мин сәхнәгә борынгы көйләр белән килдем. «Болын» җыры — һәм сүзләре, һәм көе-моңы белән үзгә бер әсәрдер.

Бигрәк матур болын, бигрәк матур,
Нигә икән былбыл кош булмадым?
Нигә, чут-чут сайрап,
Агач башларына кунмадым?

Сүзләре аянычка, үкенечкә корылган. Димәк, көе дә сагышка тартырга тиеш, һәм ул шулай да. Кеше үзенең үткәнен, хисләрен шушы сүзләр аша әйтә икән, димәк лирик каһарман нриндидер фаҗига кичергән. Ләкин без аның нинди бәлаләргә дучар булганын төгәл белмибез, белүнең кирәге дә юк. Ул болай да сагышка, уйларга этәрә. Һәркем шушы җырда үзенең үкенечен күрә.

Алга таба җыр дәвам итә:

Болыннарда анда, тезелеп-тезелеп,
Су буенда таллар, ай, үскәннәр.
Болыннарда, кызарып-кызарып,
Кызыл карлыганнар пешкәннәр.

Бу дүртьюллык һични сөйләми кебек. Тезелешеп таллар үскән. Кызарып карлыган пешкән. Шуннан ни? Әлбәттә, ул романсны хәтерләтә. Сагыш, моң, үкенеч һәм азагы булмаган хисләр, мәхәббәт. Хәзер шундый конкретсыз гына, ассоциацияләргә генә корылган әсәрләрне «япон шигърияте» дип әйтәләр бугай. Хис бар икән — шигърият бар, хис бар икән — җыр бар.

Ләкин хисле сәнгать әсәрен кабул итәрлек хисле күңел дә булырга тиеш. Хис тапшыручы булып та, башка берәүнең хис алу мөмкинлеге булмаса, сәнгать әсәре бушлыкка атыла. Татарның борынгы, моңлы, читләтеп әйтүләргә корылган озын җырларын бүгенге яшьләр аңламый икән, кабул итә алмый икән, ике яклы элемтә җитешми дигән сүз.

Әлфия Авзалованың мондый фәлсәфәгә керергә мөмкинлеге дә, вакыты да, әзерлеге дә юктыр, ләкин олы талантның сиземләве, эчке аңы, ассоциацияле бу әсәрне халыкка җиткезә алуы ул — аның могҗизасы.

— Бу моңны каян килгән дип уйлыйсың?

— Ятимлектән! Әтием җырчы иде. Көтүче. Әти киң күкрәкле. Авылның башыннан кайтып килгәндә җырлый иде, бөтен авыл яңгырап тора. Бәләкәй вакытта мин аның моңын аңламаганмындыр. Моң килә ятимлектән, авырлык күрүдән... Кукәй эченнән чыкканнарда моң була алмый. Әнә минем кызларда моң юк. Алар рәхәттә үстеләр. Ә мин хәер сорашып үстем.

— Кызың Зөлфия сөйләп тора, әни бик күп кешеләргә ярдәм итте, ди.

— Гомер буе бирдем... Ятимнәргә гел биреп тордым. Үземдә генә дә, сеңлем үлеп, алты ятим калды. Аларга булышып торам.

— Мәшһүрлек бар синдә! Данлы кеше син! Сине яраталар! Сине белмәгән кеше юк! Син тормышыңнан канәгатьме? «Үзем турында»ны укып, кешеләр елый. Узган якка борылып карагач, ни әйтер идең?

— Бик авырлык күреп үстем бит инде... Салкын пич башында үстем, әни үлгәч... Шул яшьлегем кайтса, шул авыр тормышка мин кире кайтыр идем! Үлмәдем бит! Тырыштым! Кемгә кер удым, кемгә идән юдым. Кайтыр идем шунда, шул салам түбәле ятим өебезгә кайтыр идем... Үкенмимен! Ризамын! Яшьлегем кире кайтса... тормышның кадерен белер идем. Җиңел тормыш — сөенеч тормыш түгел ул. Аллага шөкер, эшләп алдым, димен. Тәмсез булса да, тәмле, дидем. Аллага шөкер, бу бар, дидем. Риза мин. Хәзерге тормыштан да риза мин! Элекке тормышны да сагынам мин.

— Сиңа озак сөйләшергә ярамый! Без китик!

— Сәламәтлән, Әлфия апа! — дип, без аның белән саубуллаштык.

# Карлыгач җыры

«Картаямыни йөрәк...» — дип
Җырламаган көн сирәк...
ӘЛФИЯ картаймаганда,
Нишләп картайсын йөрәк!

*Л.Лерон*

Врачлар Әлфия апаны тикшергәннән соң, вакытлыча гына хастаханәдән чыгардылар. Аны кич утырырга өебезгә чакырдык. Аңа җырларга ярамый, кычкырып сөйләшергә ярамый.

— Әлфия апа, синең иң беренче җырлаган җырың нинди җыр иде ул?

Пышылдап кына:

— «Карлыгач җыры»!.. — диде җырчы.

— Ничек булды ул хәл, сөйлә әле?

— Икенче сыйныфта укыган чакта Курчак театры килгән иде. Бөтен бала-чага эскәмикә астына кереп тулдык. Спектакльнең исеме дә «Карлыгач җыры» дип атала иде. Анда бик матур җыр бар иде. Шул җырны бер ишетүдә отып алдым...

Әлфия апа бераз моңланып алды да шул җырны әкрен тавыш белән көйли башлады:

Һаваларда очкан карлыгачлар
Болытларга кереп югала.
Кыз булганчы, булсаң канатлы кош —

Тоткын булмас идем дөньяда.

Түгәрәк күл матур була,
Су белән тулса гына.
Тусын кыз бала дөньяга,
Бәхете булса гына.

— Иң беренче хәтердә калган җырым шушы...

Җыр бик тә моңлы иде, тәэсирле иде. Тыңлаучыларның күзенә яшь килде. Әлфия апа тагын балачак хатирәләренә кереп китте, ахрысы, ул тынып калды, уйга чумды.

— Ятимлек тә бар, сагышы да бар. Бу җырны минем өчен чыгарган кебек, минем өчен җырладылар кебек. Иң беренче җырым минем шушы булыр... Мин аны бөтенләй онытканмын... Мәктәптә бит, малакаем... сугыш вакытында дүрт-биш класс бергә җыела да, Әлфияне җырлатабыз, диләр. Гел бер сәгать буе мине җырлаталар... Калку урынга басам да җырлаймын...

Бу утыруда без Әлфия апа турында документаль фильм төшерергә кирәк дигән фикергә килдек һәм, киләсе елда ул тасма төшерелеп бетәргә тиеш, дидек.

# Җанатар

Бармыни безнең татарның
Хәсрәтсез торган чагы?!
Хәсрәтне оныттыра кайчак
Моңлы Актаныш ягы.

*Р.Әхмәтҗан*

Әҗәлләрең җитсә, әйт үземә,
Йәнбикә, Йәнбикә,
Синең өчен үзем үләрмен.

*Халык җыры*

*Күп тырышлыклардан соң, чит илләрдән дарулар кайтартып, тәҗрибәле яхшы табиблар ярдәмендә Әлфия апаның тамагына операция ясадылар. Бу эшне атаклы хирург Рифкать Минһаҗ улы Таҗиев башкарды. Аллага шөкер, табиблар вакытында өлгерде. Әлфия апа бик тиз савыга, тавышы ачыла башлады.*

*Әлфия Авзалова янә Зәйдә, хакимият башлыгы Рәшит Хәмәдиев чакыруы буенча кунакта. Рәшит әфәнде — Әлфия Авзалова өчен җан атучы шәхес.*

*Бу әңгәмә 1997 елның 12 февралендә булды.*

Рәшит. Котлыйм, Әлфия апа! Син вакытында күренгәнсең докторларга.

Әлфия. Рәхмәт, Рәшиткәем, син кайтарып җибәрмәгән булсаң, бәлки, мин...

Салмак кына чәй эчәбез. Дәвам итeләчәк гастрольләр турында сөйләшәбез.

Әлфия. Рәшит энем, без синең белән беренче тапкыр Зәйдә таныштык бугай?

Рәшит. Ул вакытта мин колхоз рәисе булып эшли идем. Бу җитмешенче еллар иде. Райком секретаре, мине чакыртып: «Мәшһүр җырчы Әлфия Авзалова килә, аны каршы алу, аның белән очрашуларны оештыру сиңа йөкләнә, йөзгә кызыллык китермә», — диде.

Әлфия. Хәтерлим әле, син ул чакта су сөлеге кебек озын егет, соры костюмнан, мәһабәт идең. Мин бит әле ул вакытта йолдыз түгел идем.

Рәшит. Йолдыз! Йолдыз идең инде, Әлфия апа. Син бит яшьтән үк йолдыз булып киттең.

Әлфия. Безнең дуслык шул көннән башланды.

Рәшит. Әлфия апа, мин сине яратам бит. Җырларың өчен, моңың өчен. Татар халкына шулкадәр күп хезмәт иткән кеше син. Мин шулкадәр сөендем шушы эшнең миңа тапшырылуына. Чөнки мин синең җырларыңны тыңлап үскән кеше, синең моңыңа ерактан торып гашыйк булган кеше. Әлфия Авзалованың үзен күреп, аның белән танышуны мин төшемдә дә күрмәгән...

Син, Әлфия апа, татар халкына армый-талмый хезмәт иткән кеше: чанада, арбада, җәяү йөреп хезмәт иткән артистка. Авыр юллар йөргән кеше, микрофонсыз, аппаратсыз җырлаган җырчы. Күп кенә җырчыларыбыз әкрен генә төшеп калды бит инде. Гаҗәп шәхес бит син, Әлфия апа. Синдәй озак сәхнә тотучылар бик сирәк бит. Каян килә, ничек шулай ул, Әлфия апа?

Әлфия. Барысы да Аллаһы Тәгаләдән, Рәшит балам, сиңа зур талант бирелгән икән, син аны бәрәкәтле итеп куллана да белергә тиеш. Әнә шул талантка кушарга тагын бер нәрсә кирәк — тырышлык. Ятимә

кыз, тырышмаса, бәреп чыга алмый. Син дә бит минем сыман ятим калган кеше, Рәшит энем. Син дә үз тырышлыгың белән күтәрелгән кеше. Син мине беркайчан да ярдәмеңнән ташламадың, иң авыр чакларымда син сүзең белән, гамәлең белән ярдәм иттең, рәхмәт.

Рәшит. Әлфия ханым, син бәхетле хатын дип уйлыйм мин. Бер француз философы болай дигән: «Бәхетле тормыш була алмый, бәхетле мизгелләр генә була». Сиңа халык аягүрә басып кул чаба. Шул вакытта син нинди халәттә буласың?

Әлфия. Шуннан да зур бәхет юк. Исән-сау савыгып, ныклап аякка бассам, тагын җырлаячакмын, мин тагын бәхетле. — Әлфия апа сагышлы үткәннәренә әйләнеп кайта. — И-и, күрде инде безнең башлар... Өсте өстенә язалар иде, барын язсалар, үртәлмәс тә идем, югын язалар бит.

Батулла. Әлфия апа, «күп егетләр белән йөри» дип дөрес язганнар түгелме соң?..

Әлфия. Беләсеңме, апаем, балаларымны ташлап, теләсә кем белән йөрсәм, мин нинди хатын булыр идем? Мин беркайчан да балаларымны, оныкларымны, үги туганнарымны онытмадым. Шуннан үз-үземә әйттем: сөйләсеннәр, шуннан минем җырыма ни зыян? Мин барыбер ул гайбәтләрне җиңәчәкмен, мин олы җырчы булып калачакмын, дидем. Аллага шөкер, һаман җырлаймын. Ходай Тәгалә гомерлеккә биргән бу сәләтне...

Рәшит. Кыңгырауны яхшы атка гына тагалар. Юк-бар кеше турында гайбәт чыгара алмыйлар. Әлфия апа, синең турыда чыгармыйча, кем турында чыгарсыннар? Җырчылар, артистлар турында кеше гайбәт сөйли икән, бу алар өчен пропаганда, имидж бит. Гайбәт өчен бер дә кайгырасы юк. Димәк, сиңа халык битараф түгел. Димәк, сине яраталар, хөрмәт итәләр. Сине, бәлки, шулай күрәселәре киләдер... Синең һәрбер җырың аерым сәнгать әсәре бит. Син һәрбер җырның, һәр сүзнең ничек җырланасын, ничек әйтеләсен беләсең. Бу Ходайдан бирелгәндер. Мин синең җырларны күземне йомып тыңларга яратам. Сихерләнеп тыңлыйм. Минем кебекләр бик күп бит.

Әлфия. Үземә болай әйткәннәре булмады. Рәхмәт, улым, Рәшиткәем! Синең кебек мине аңлаучы гына юк.

Рәшит. Аңлыйлар, Әлфия апа. Менә мин Зәй хакимияте башлыгы бит инде. Мин синең концертларга кешене милиция белән куып китертмим бит. Залларың шыгрым тулы. Бу бит халыкның сине аңлавы, яратуы, хөрмәт итүе...

Әлфия. Аллага шөкер!

Рәшит. Җырчылардан син кемне якын итәсең димме, яратасың димме?

Әлфия. Чулпанны тыңладым күптән түгел генә. Аңа сорау бирделәр: «Җырчылардан кемне яратасыз?» — диделәр. Анда Илһам да юк, Әлфия апаң да юк, башкалар да юк. «Салаватны, Хәнияне», — диде. Мин дә аларга каршы бара алмыймын.

Рәшит. Димәк, Хәния белән Салават?

Әлфия. Бүген алар ике йолдыз.

Рәшит. Журналистларча бер сорау бирим әле, Әлфия апа. Алдагы планнарыгыз?

Әлфия. Илһам белән икәү программа төзеп, гастрольгә хушлашу концертларына чыгу! Мин бер бүлек, ул икенче бүлекне җырлый. Халык сагынды безне, халык кызыксына: нишли Илһам бүген, Әлфия кайда йөри?

Рәшит. Якты Күл авылында син концерт куйдың. Ике әби сиңа чәчкә түгел, сандыкларында яткан күлмәклек алып килгәннәр иде. Ул әбиләргә председатель дә кушмаган, хакимият башлыгы да боермаган, үз сандыгындагы күлмәклекне алар сиңа карата олы хөрмәтләре булганга алып килгән. Бу бәхет түгелмени?

Халыкны, кешеләрне хөрмәт итү ул — бәхет, Әлфия апа. Син дә бәхетле, сине халык хөрмәт итә. Сиңа халык аягүрә басып кул чапты. Бу бәхет түгелмени?

Әлфия. Бәхет.

Рәшит. Шулай булгач, төкер гайбәтләренә! Шул бәхет өчен көрәшергә кирәк, авыруыңны җиңәргә кирәк, шул бәхетле тормышта, ичмасам, бер егерме ел яшәргә кирәк.

Әлфия. Җырларга кирәк.

Рәшит. Синең җырлавың — ул үзе бәхет.

Әлфия. Җырламасам, мин — мәет.

Рәшит. Әлфия апа, син: «Яратам, Рәшиткәем, улым», — дип, салпы якка салам кыстырырга яратасың, үпкәмне дә әйтим әле.

Әлфия *(гаҗәпсенеп Рәшиткә бага).* Үпкә? Нинди үпкә ул?

Рәшит. Ие, син теге җырны миңа язып бирәм дип, күпме йөрисең, әле җырның миңа килеп кергәне юк. «Алар минем хәлемне белми, мин аларныкын беләм»не.

Әлфия. Әле язылмаган бит ул җыр. Минем башта гына ул.

Рәшит. Тавышың авыру, ләкин салмак кына көйләп күрсәт әле. Мөмкин булса. Әле аны Батулла да белмидер.

Әлфия *(тамагын көйләштереп ала да ишетелер-ишетелмәс кенә моңлана башлый).*

Йөрәгемдә, хисләремдә

Хушлашам кошлар белән.
Алар минем хәлемне белми,
Мин аларныкын беләм.
А-а-а-а...
Алар минем хәлемне белми,
Мин аларныкын беләм.

Әлфия апаның болай да зәгыйфь тавышы тагын да салмаклана, ул сүзләрен генә көйгә әйтеп бара. Бу речетатив моңны, хисне тагын да арттыра төшә. Рәшит Хәмәдиевнең, Рәис Нәҗиповның күңелләре тулып аша. Һәрберебезнең күзендә яшь, алагаем олы гәүдәле Рәшит әфәнде дә, сабый бала сыман, күз яшьләрен тыя алмый.

# Кич утыру

Күк капусын гомергә бер
Безгә дә Тәңре ачты, —
Иңдерде Актанышка ул
Иң моңлы сандугачны.

Сүнгән күңелгә сөюне
Ул гына сала икән.
Халыкны бер сандугач та
Юата ала икән!..

*Р.Әхмәтҗан*

— Балалар! Бүген без Әлфия Авзалова белән кич утырабыз. Әлфия апа, синең урын менә шушы керешле култыксада булыр. Нурбәк, Байбулат, Әлфия Авзалова, Батулла, Рузия, синең оныгың Рената, кызларың Гүзәл белән Зөлфия бүген кич утырабыз.

Әлфия апа кич утырырга ярата, без дә яратабыз, балалар да ярата. Табын янында Әлфия апа нинди генә кызык хәлләр турында сөйләми, нинди генә пародияләр күрсәтми. Бу кич утыруларны бөтен гаиләбез белән көтеп алабыз.

— Иске моңнарны яңартып алыйк әле, Әлфия апа! — дидем.

— Аулак өйдә. Элек аулак өйдә шушылай иде бит. Хәллерәк кешеләрдә була торган иде инде ул мондый аулак өй. Бездә бит сөртергә сөлге юк иде мин үскән йортта. Иске күлмәк якалары дисеңме, шундыйлардан ясалган чүпрәк-чапрак кына.

— Әлфия апа, мин бая, «иске моң» дип, бик үк дөрес әйтмәдем. Моң искерми ул!.. Менә бу уйнаткыч, иске патефон. Синең җырлар монда...

— Боларның берсе дә миндә юк, каян җыйдың син боларны?

— Мин синең җырлар язылган патефон тәлинкәләрен җыйдым. Шуларны тыңлап утырырбыз. Монда Гөлсем Сөләйманова, Рәшит Ваһапов, Зифа Басыйроваларның тавышлары язылган иске патефон табалары. Алар өр-яңа кебек сакланганнар. Хәзер тыңлап багарбыз. Синең үз тәлинкәләрең бармы?

— Юк! Бер генә пластинкам да үземдә юк. Чөнки мин үземнең җырлавымнан риза түгел идем. Яңа чыккан пластинкамны бер-икене ала идем, күз буярга гына. Кеше сорагач, биреп бетерә торган идем.

— Күрәсең, ул даһи иҗатчыларга хас гадәт... Элек патефон авылда бер-ике кешедә генә була торган иде. Безнең әти беренче булып авылга патефон алып кайткан. Бу патефон табалары атамнан калган. Алар өр-яңа шикелле сакланган. Менә хәзер синең яшь вакытта башкарган «Сәлимәкәй» җырыңны уйнатабыз.

Патефонда «Сәлимәкәй» җыры яңгырый. Әлфия апа, үзенең яшь тавышын ишетеп, уйга кала, аның янында төпчек кызы Зөлфия чөмәшкән, олы кызы Гүзәл диванга утырган, алар да җырны тыңлый. Әлфия апа ара-тирә җырның сүзләренә кушылып кабатлап куйгалый, кайчакларда кушылып җырлый да. Ул сабыр, борчусыз күренә. Әмма Зөлфиянең йөзенә баксаң, җан тетрәп куя. Зөлфия анасының яшь вакыттагы саф тавышы аша анасының бар фаҗигасен, авыр тормышын, бөек шөһрәтен күрә кебек. Аның күзләре дымланган. Ул сиздермичә эчтән генә, сабыр гына елый иде. Гүзәл дә, диван култыксасына карап, тирән уйга талган.

— Әлфия апа, бу җырны ничә яшьтә җырлаган идең?

— Хәзер әйтәм. Казанга килгәндә миңа уналты тулып, унҗидегә чыккан идем инде... Рәфкать Гомәров баянда уйный. Ул, училище бетереп, минем бригадага килде. Шәп музыкант иде, мәрхүм.

Әлфия апаның яшь чагында җырлаган тагын бер җыры патефон табасында яңгырый. Бусы Сөембикә Вәлиева иҗат иткән җыр.

Кайтам, диеп әйттең,
Еракларга киттең.
Салдың мине сагыш утына...

Әлфия апа үзенә үзе кушылып җырлый. Ләкин аның тавышы элеккеге кебек саф, нечкә түгел, бераз утыра төшкән, табиб пычагыннан соң калынайган.

Зөлфия бу җырны тыңлаганда күз яшьләрен тыя алмады, аның ике яңагыннан кайнар яшьләр ага да ага, әйтерсең лә Әлфия апа үзе елый. Ләкин Әлфия апа тыныч кына моңлана. Зөлфия әнисенең күз яшьләре белән елый кебек.

Ник соң моңсу була
Кичен айга карау?
Ник соң йөрәк сызлый, моңлана?
Күңел кошы аның
Еракларда булса,
Сагына, уйлый икән
Кыз бала.

Сабырлыгым бетте,
Каушыр көннәр җитте.
Кайтчы, иркәм, тизрәк
Кайт инде, а-ай-и, кайт инде...
Кайтам, диеп әйттең,
Еракларга киттең.
Салдың мине сагыш утына...

Зөлфия, безгә күз яшьләрен күрсәтмәс өчен, анасының аркасына яшеренде. Ике учы белән күз яшьләрен сөртә иде булса кирәк. Әлфия апа да кызының күңеле мөлдерәмә тулганын сизенде сыман, ләкин сизмәгәнгә салышып сүз башлады:

— Әле генә беренче җырны тыңладык. Атказанган артистыбыз, музыкант Рәфкать Гомәров уйнады миңа. Хәзер мәрхүм инде. Япь-яшь, мәһабәт буйлы, баһадир кебек җегет минем бригадама килеп кушылды. Күрәсез, ничек матур, моңлы уйный Рәфкать, ул да ятим үскән егет, минем кебек үк. Икенче җырым «Кайт инде» дип атала, Сөембикә Вәлиева сүзләре һәм көе. Искиткеч матур сүзләр, нинди хис бу җырда... Картлыктан, үлемнән качып булмый. Шушы җырны шушылай итеп, саф тавыш белән җырлаучы табылса, үлеп китсәм, гүремдә шатланып ятар идем. Мин бәхетле булыр идем, шундый кеше табылса. Кем җырлар икән менә шушы җырларны шулай итеп? Искиткеч бит! Нинди йөрәк кирәк, нинди бәгырь кирәк моны җырлар өчен!

Патефонга Гөлсем Сөләйманова тәлинкәсен куябыз. Әлфия апа да, башка кунаклар да тарихка сәяхәт кылабыз. Атаклы җырчының җыры барыбызны да әсир иткән.

— Гөлсем Сөләйманова белән син таныш идеңме?

— Гөлсем апаны мин аны сәхнәдә күрмәдем, сәхнәдә җырлаганын тыңлаганым булмады. Бер тапкыр базарда очраттым, икенчесендә радиога кереп киткәнен күреп калдым. Гади генә киенгән, модница түгел иде ул, шикарно булып йөрмәгән ул. Гөлсем апа шаян түгел иде, миңа калса. Аның йөзе тулы моң иде. Моңлы йөзле кешеләр шаян җырлар җырламый да кебек. Нигә гел сагышлы җырлар гына җырлыйсың, шаян такмаклар да җырла, дип, аларны мәҗбүр итеп тә булмыйдыр. Аларны шаянлыкка өйрәтеп тә булмый...

— Менә син, Әлфия апа, моңлы җыр алсаң, моңга күмеләсең, дөньяны моңга күмәсең, шаян җыр булса, син аны шаянлык белән чәчрәтәсең.

— Чөнки мин үзем шаян кеше, тормышта мин бик шаян бит. Кызык тыңларга, кызык сөйләргә үлеп яратам.

— Синең җырларыңда сүз белән көй аерылгысыз, алар бер-берсен тулыландыра. Ачык дикция, яхшы артикуляция. Моны сиңа кем өйрәтте?

— Үзеңнән килә ул. Нәрсә турында әйтергә теләгәнеңне беләсең, шуны халыкка сүз боткасы белән аңлатып булмый бит. Ярату турындамы ул җыр, аккан сулар турындамы ул, синең сүзләрең йөрәгеңнән өзелеп чыгарга тиеш. Челтерәп аккан чишмәләрнең тавышларын, күңелеңдәге хисләрне аңлашылмаган сүз белән аңлатып булмый бит инде!

— Әлфия апа, тавыш мөмкинлекләре чамалы булган кеше дә яхшы җырчы булып китә аламы?

— Андый хәлләр дә булырга мөмкин. Халыкны ничек итеп үзеңә җәлеп итәргә кирәк бит әле. Сәхнәгә чыгып моңаеп тору гына җитми бит. Сара апа Садыйкованың тавышы бик көчле булмаган. Күнегүләр ясый-ясый, тырыша-тырыша, Сара апа олы җырчы булып китә. Опералларда, музыкаль комедияләрдә ул сәхнә тоткан зат. Аның замандашы Хәкимә Чамаева да Мәскәүдә Опера студиясендә укый. Тавышы шаккаткыч көчле, моңлы була. Ләкин җырчы буларак ул үсмәде, төшеп калды. Усман Әлмиевнең дә тавыш диапазоны әллә ни киң түгел иде, ул тавышын кадерләп саклый алды, һәрвакыт күнегүләр эшләде. 90 яшендә дә аның тавышы утыз яшендәге кебек. Сәләтлеләр күп, атаклылар гына аз. Тырышлык хәл итә язмышны. Әгәр дә син кечкенә тавышың белән дә матур итеп, моңлы итеп, сүзләрен аңлаешлы итеп, сәхнәгә чыгып халыкны җәлеп итә аласың икән, син — җырчы!

— Мин Усман абый белән Әлфия Авзалованы бүгенге җырчыларга үрнәк итеп куяр идем. 70–90 га җитеп тә үз тавышларын югалтмаган җырчылар аларга үрнәк булсын иде.

— Мин әле һаман да тавышымны сакларга тырышамын. Җен шикелле эшләмәсәң, сәхнәдә кирәгең калмаячак.

— Әлфия апа, гастроль вакытында булган берәр гадәттән тыш вакыйга турында сөйлә әле.

— Мәскәүдә зур залларда «Зиләйлүк»не җырладым. Туктале, мин әйтәм, Илһам кебек бормалап, милли моңнарны бер җырлаем әле, дидем дә җырлап җибәрдем. Зал тулы халык. Бер куплет җырлап бетерә алмадым, залдан кычкыралар: «Әлфия ханым, Әлфия ханым, туктатыгыз бу озын җырны! Безгә әби-бабайларның җырлары кирәк түгел! Безгә эстрада такмаклары кирәк», — диләр.

— Син нишләдең инде?

— Нишлим? Көлдем дә, яхшы, егетләр, мин әзер сезнең заказны үтәргә, мин әйтәм, әнә зур яшьтәге дусларым килгән, алар өчен, аталарыгызны хөрмәт итеп, хет тагын бер куплетын җырлап бирим, дидем дә яңадан «Зиләйлүк»не башладым. Җырлап бетердем. Зал шартлый язды, «бис, браво!» кычкыралар. Аннан соң заман җырларына тотындым. Заман җырларым да минем моңлы җырлар бит.

— Мин синең бөтен язмаларыңны тыңлап-барлап чыктым һәм шундый бер фикергә килдем. Синең репертуарда сагышлы җырлар да, шаяннары да җитәрлек. «Күл буена килсәң иде» җырын мин патефон тәлинкәсендә тыңладым, тәлинкәдәге шаян җыр салмак яңгырый, шаян түгел кебек, ул сузынкы язылган, дәрт, шаянлык җитенкерәми. Шушы шаян җырларыңны мин ничә тапкыр сәхнәдә тыңладым, анда син ут чәчәсең шаян җырларыңда. Нур чәчеп торган дәрт була син аларны башкарганда.

— Сәхнәдә бит анда башка, тасмага-тәлинкәгә язылганда — башка. Халык сиңа карап утыра, син аларның карашларын күрәсең, теләкләрен, хисләрен тоясың. Радиода, микрофон алдына килеп баскач, тимер арасына... хис тә, моң да югала. Халыкның үзенә турыдан-туры тапшыра алмыйсың син талантыңны, моңыңны. Мин җырларымны халыкның күз алдында иҗат итәм.

— Димәк, сиңа тере тамашачы кирәк?

— Шулай! Тамашачының күзе, колагы, игътибары кирәк. Мин бушлыкка җырлый алмыймын. Коры стенага карап җырлау кешенең ярты дәртен, ярты сәләтен урлый, бик күп мөмкинлекләрне әрәм итә.

— Матур, мөлаем җырчылар бик тиз генә танылып китәләр дә кабынган кебек тиз генә сүнәләр, сәхнәдән төшәләр.

— Кайберләре беренче уңышыннан бик масаеп китә, мин генә яхшы җырчы дигән кыяфәт ала. Үзләренең Алла биргән сәләтләрен үстерү ягын уйламыйлар. Үзеңнең иҗатың белән риза булу ул — җимерелүнең башы. Гомергә канәгатьләнмә үз җырың белән. Иҗатыннан риза кеше бер урында таптанырга мәҗбүр була. Бер урында таптану халыкны туйдырып бетерә. Яңалык, яңалык кирәк иҗат кешесе өчен, җыр өчен бигрәк тә. Тегеннән эзлә, моннан тап, ат кебек эшлә. Талант бит ул — ат. Атны да бит тәрбия кылырга кирәк, ашатырга-эчертергә, юып, ялын тарап, елкылдатып торырга кирәк. Ашатмыйча каты җигә башласаң, ерак китә алмыйсың, егыла да үлә синең атың. Тавышны да шулай тәрбияләп торырга кирәк, яшьләргә киңәшем шул.

— Иң беренче һөнәрең турында сөйләшик әле.

— Ятим балалар йортында җиденчене бетергәч, авылга кайттым мин. Шулчак Актанышыбызга райкомның беренче секретаре булып Сәхаби абый Камалиев дигән кеше килде. Мине җырлата башладылар, килгән кунаклар алдында да, бәйрәмнәрдә дә мине программага язалар. Җырлыйм да җырлыйм. Агитбригадада йөрим, колхозларда тамак та туя башлады. Бу баланың өстенә кияргә бернәрсәсе дә юк, иптәшләр, бераз акча эшләсен, дип, мине МТСның бәләкәй генә өенә урнашкан избачка китап биреп торучы итеп куйдылар. Хезмәт хакы билгеләделәр, өс-башымны карый башладым.

— Сине сыер савучы булып эшләгән, диләр, шул дөресме?

— Гомеремдә дә эшләгәнем юк! Сыерны бит савасы аны, саумадым, кәҗәбез дә булмады безнең... Бәхетемә, шушы Камалиев килеп, мине сәнгать юлына кертеп җибәрде. Мин инде шунда үземнең җырчы булачагымны сизенә идем.

Патефонда «Шахта» көе яңгырый. Барыбыз да җыр тыңлыйбыз. Тарихта калган тавыш яңгырый. Әлфия апа инде болай итеп беркайчан да җырлый алмаячак. Аның тавышы утырган, калынайган. Ул үзе дә бу җырны чит җырчыны тыңлаган кебек тыңлый.

— «Шахта» көе турында фәлсәфә куертмакчы булам бүген, — дидем, җыр туктагач. — «Шахта»ны барыбыз да җырлап үстек. Гармунда уйнап үстек. Бик күп җырчылар җырлый инде аны, барысы да үзенчә матур җырлый. Әлфия Авзалова башкаруында җыр башкачарак яңгырый. Икенче өлешендә син югары октавага, нечкә тавышка күчәсең. Бу ысул бер генә җырчыда да юк шикелле. Бу Әлфия Авзалованың табышымы, әллә сезнең якта «Шахта»ны шулай нечкәртеп бетерәләрме?

— Башкалардан үзгәрәк җырлыйсы килә бит.

— Бәлки, калын тавыш белән тәмамларга синең диапазоның җитмидер, шуңа күрә син нечкә аваз белән бетерәсеңдер?

— Юан тавышта да бетереп була, югарысында да бетереп була, диапазоным киң бит минем. Әмма мин «Шахта»ны шулай нечкәртеп җырлыйм, миңа шулай ошый.

— «Шахта»ны җырлаганда, синдә нинди хисләр уяна?

— «Шахта»ны җырлаганда, мин шахтага китүчеләрне күз алдыма китерәм. Алар сугышка киткән кебек китәләр иде, кайберләре, басылып, җир астында кала, кайсысы газ шартлап үлә, кайберләре гарипләнеп кайта. Гаиләләре җылый, туган-тумачалары җылый, мин шуларны күз алдыма китереп җырлыйм, халыкның өметен, фаҗигасен җырлыйм мин. Үзеннән-үзе күз алдына килә алар. Егете, ире шахтада басылып үлгәч, ятимә калган кыз, ятимә калган хатын булып җырлыймын ул җырны. Мин тол калган хатынга әвереләм. Мин шахтада басылып үләргә китә торган егет булып алам.

— Җырны әзерләү турында беләсе килә. Менә синең кулга — яңамы ул, искеме ул — җыр килеп керде, нотадамы ул, нотасызмы, шушы җырны өйрәнә башладың ди. Әлфия Авзалова нидән башлый?

— Дөресен әйтим, мин, сүзләре мәгънәле булмаса, көй шәп булса да, җырларга алынмыймын. Минем өчен сүз көйдән дә мәгънәлерәк булырга тиеш... Минем бу турыда уйланганым булмады, син сорагач, җыр иҗат иткән чакларымны искә төшерәм... Мин башта җырны хиссез генә, коры гына өйрәнәм. Кабатлаган вакытларда артык ертылмыймын. Спортсмен башта салмак кына күнегүләр ясый, ә ярышта җене белән тырыша. Мин дә, сәхнәгә чыкканчы, сабыр, хиссез кебек, тамашачым каршысына чыгып баскач, мин инде җырны иҗат итәм.

— Синең тавышны табигать тарафыннан куелган тавыш, дип сөйлиләр. Нәрсә ул табигать тарафыннан куелган тавыш?

— 1951 елда мине Җыр һәм бию ансамбленә алдылар. Композитор Александр Ключарев әйтә: «Мондый матур озын көйләрне җырларга кем өйрәтте, синең бит тавышың табигатьтән үк куелган», — ди. Мин: «Авылдагы укытучым Мәрзия апа Юнысова өйрәтте», — дим. Ул баянчы апа иде. Ничек сулыш алырга, ничек авызны ачарга ул мине өйрәтте. Аннан соң авылымдагы Мәсгут абый Әхмәтшин, ул гармун ясый иде. Шул Мәсгут абый мине җырларга өйрәтте.

Их, шул халык талантларын консерваториягә, музыкаль училищега җыр дәресләре бирергә куярга иде.

— Була матур гына, мөлаем гына җырчылар, ләкин алар тиз танылып та, тиз генә сәхнәдән төшеп калалар. Синең озак еллар сәхнә тотуыңның берәр сере бармы?

— Аның сере бер генә — Аллаһы Тәгаләдән бирелгән сәләт. Тавышымны саклаем дип, мин муенымны төреп йөрмәдем, тавышымны саклаем дип, мин, авырсам да, бюллетеньгә чыкмадым, порез белән дә җырлап йөрдем. Порез — тавыш җепселләренең, бугаз сеңерләренең өзелүе, ялкынсынуы. Порез булган җырчы, савыкканчы, «стенага терәп атабыз» дисәләр дә, җырламаска тиеш. Себердәге утыз концертны өзеп, хастаханәгә кереп ятмадым. Порез белән дә җырларга туры килде. Җырладым. Ләкин тавышым әле һаман — Аллага шөкер.

Әмма Әлфия апаның әйткәннәре, тавыш җепселләрегез авырганда да җырлагыз, дигән сүз түгел, аның тавыш аппараты, мөмкинлекләре башкаларныкыннан нык аерылып тора, шул сәбәпле генә ул тавышсыз калмаган.

— Әгәр дә сине якташларың, җырчы бул, дип, хәерле юл теләп озатып калмаган булсалар, сине нинди язмыш көткән булыр иде икән?

— Мин барыбер җырчы булыр идем. Язмышым шул бит минем. Мин башка һөнәрдә үземне күз алдына да китерә алмыйм. Эштән тайчанмаем мин, утынын да ярам, печәнен дә чабар идем, ләкин Алла биргән ул җырчы куәтен кая куяр идем? Әлбәттә, барыбер җырга барып тоташкан булыр иде минем язмыш.

— Синең репертуарда драматик җырлар белән шаян җырлар да аз түгел. Син шуларның кайсысын алгарак куясың? Фаҗигалесенме, көлкелесенме?

— Аера алмыйм... Миңа икесе дә кадерле. Моңлы җырларны мин бик теләп, җаным белән җылый-җылый җырлыймын. Шаян җырларны да өзелеп сөямен. Күпме кыенлыклар, ятимлекләр күрсәм дә, мин табигатем белән шаян кеше бит.

— Авылдан авылга, шәһәрдән шәһәргә күчеп йөри торган артистларга бала үстерү, бала тәрбияләү шактый кыен эш. Бигрәк тә ялгыз хатыннарга. Синең балаларың татарча белеп, тәрбияле булып үстеләр. Балаларыңны кемгә калдырып чыгып китә идең?

— Җыракайга! Җырак апага! Анам белән бертуган апамны без шулай дип йөртәбез. Җыракай мине үстерде, балаларыма әби булды, аларны да тәрбия итте. Авыр туфрагы җиңел булсын. Җәйге гастрольләрдә балаларымны үзем белән алып йөри идем.

— Әлфия Авзалова — кыен язмышлы кеше, ятимлекнең эчендә яшәгән кеше, ләкин күп кеше көнләшерлек дәрәҗәгә ирешкән кеше. Халык җырчысы булган кеше. Шул ятимлектә дә син үз ятимнәреңне, туганнарыңның ятимнәрен дә карап үстердең. Ике кызыңны башлы-күзле иттең. Инде оныкларыңны үстердең. Балаларың, туганнарың каршында синең бурычың үтәлгән. Бер бурычың балаларың каршысында булса, икенчесе — оныкларың каршында. Өченче бурычыңны — халкың каршындагы бурычыңны — намус белән үтәдең син. «Менә шушы игелекле эшләрне башкардым, үлсәм дә үкенмим!» дигән сүзне әйтә аласыңмы?

— Үләсе килми, күршекәем! Үзем өчен яшәмәдем бит әле! Җырлыйсы җырларым бар, халкыма әйтәсе сүзләрем бар. Халкыма, Казаныма, дусларыма бик зур программа әзерләп, көзге байлыклар кер-

гәч, шушы 1997 елда, Алла боерса, матур концертларымны бирермен дим. Үлем турында уйламыйм әле. Картайсак иде әле, картлыкның рәхәтен күрсәк иде әле!

## Тәнәкәй

Иртә-кич сайрый да сайрый —
Юана татар җаны.
Шулай ярата икән ич
Сандугач кына аны!..
Сайрый күр! Җиде... юк, җитмеш, йөз!
Миллион татар тыңлар!..
Синең җырың җыр гынамы? —
Сандугач сузган моңнар!..

*Р.Әхмәтҗан*

Чыннан да, Әлфия апа бар кыенлыкларны, шул хисаптан каты авыруын да җиңеп, тагын каты авыруга дучар булып (2003 елның гыйнвар аенда аның башына кан сауган иде), ул тагын аякка басты, савыкты, шөкер.

Уйнаткычта Әлфия Авзалова башкаруында «Тәнәкәй» җыры яңгырый. Бөтен кич утыручылар да җыр тәэсирендә. Әлфия ханым, диванга янтаеп утырган килеш, яшь тавышын тыңлый.

Кияүгә бирәм, бараһыңмы, балакай?
Барам-барам, әсәем,
Басылды бит йөрәккәем, —
дип әйткән ди кызы, шатланып.

Башкорт һәм татар халкының иң борынгы, матур җырларыннан берсе «Тәнәкәй»не Әлфия Авзалова аеруча үзенчәлекле итеп башкара. Бу җыр шаян сюжетка корылган. Анасы кызына кәҗә бүләк итә. Кыз: «Нишлим мин ул кәҗә белән?» — дип, бүләктән баш тарта. «Кияүгә бирәм», — дигәч, кыз шатланып риза була. Ана кызының өлгергәнлеген, аның балигъ булганын тикшереп бага кебек. Кәҗә бәтие белән уйнау түгел кыз башында, кызның хыялында кияүгә чыгу. Ләкин шушы шаян сүзләргә халкыбыз гаҗәеп озын, моңлы көй чыгарган. Әлфия апа аны шундый моңлы итеп башкара. Шаянлык белән моң янәшә, сөю дәрте белән сагыш янәшә. Тормыш кебек катлаулы бу җыр. Әлфия апа, үз тавышын уйнаткычта тыңлаганда, тирән сагышкамы, әллә тирән хатирәләргәме кереп китә? Ул ара-тирә җырга кушылып ала, аның иреннәре уйнаткычтан ага торган тавышка синхронно ачыла, ябыла башлый, аннан соң ул тагын тыңлаучы гына булып кала.

Җыр туктагач, Әлфия апа да, башкалар да иркенәеп куя. Моң бит ул — йөк, күңел йөге, аны күтәрә белергә кирәк. Ул йөк сине тирән кичерешләргә сала, ул йөк сине ләззәтле сызлануга китерә. Шул авыр ләззәттән котылуга сөенеп, кешеләр иркен сулап куя. Атаклы җырчыбыз да нииндидер йөктәнме, хатирәләрдәнме, кичерешләрдәнме азат булганына сөенгән кебек, көр тавыш илә әйтеп куйды:

— Гап-гади сүзләр, теләсә кем язардай ябай сүзләр... — диде. — Гап-гади сүзләрнең эчендә тирән мәгънә ята... Ә моңы! Моңы гимн бит! Нииндидер халык даһие шушы җырны чыгарган, җырлаган, башкаларга тапшырган бит!

— Һәм шул халык даһие чыгарган даһи җырны татар халкының даһи җырчысы башкара, — дидем мин.

## Җыр-моң турында

— Әлфия апа, без синең турыда фильм төшерергә йөрибез. Профессиональ камера, профессиональ оператор тапканчы, мин һәвәскәрләрчә генә сине тасмага төшерим әле. Студия шартларында түгел, Батулла өе шартларында. Шуңа күрә безнең сөйләшүебез дә кич утырудагы кебек булырга тиеш. Иркен сөйләшү булырга тиеш. Сөйләшүне башлап җибәрер өчен, бер тапталган, ышкылып, шомарып беткән сорау сиңа. Унсигез яшеңә кире кайтсаң, син нишләр идең?

— Егетләр турында уйлар идем. Нинди егет белән танышырга? Кыз кешенең аннан башка хыялы була аламыни ул? Бик яхшы булыр иде дә ул унсигезгә кайту, кайтып булмай.

— Үлем турында уйлаштыргалыйсыңмы?

— Олыгайган саен үлем турында уйлыйсың икән ул.

— Син җырлый алмый башласаң, тфү-тфү, бу сиңа янамый, җырлаудан туктагач, нииндирәк хисләр кичерер идең яки син үзеңә башка бер шөгыль табар идеңме? Оныкларыңа бияләй, башлык бәйләр идеңме?

— Уйлап торам да, әгәр дә җырлый алмасам, ике кулсыз калган кебек булыр идем... Казанда җырламаганыма дүртенче ел китте. Ике генә көн элек Г... концертында булдым. Кешеләр чәчәк бирәләр дә төшеп китәләр. Кул чәпелдәтүче дә юк. Мин чыктым, минем башым күренүгә үк китте алкыш. Мин җырламыйм бит, котларга гына чыктым, аптырагач уйлап куйдым: мине халкым сагынган, мин халыкка кирәк икән, дидем. Быел Казанда концертлар бирәчәкмен, Алла боерса... Зыкиналар җырлый бит... Тавыш кирәк, кыяфәт кирәк. Икесенең берсе булмаса, сәхнәгә чыкма. Туктарга кирәк. Бәйләү белән шөгыльләнә алмыймын. Дусларым күп. Дусларым ул — халкым дигән сүз.

— Ни өчен кеше җырлый икән? Җыр нигә кирәк? Җырчы нәрсә турында җырларга тиеш? Җырчының максаты бармы?

— Минем максатым — халкыма җырлау. Халкың булмаса, тавышың нинди генә көчле булса да, сине тыңлаучы, ишетүче булмаячак. Җыр минем өчен яшәү көче, яшәү тәме. Мин өйдә җырламаем, апаем. Кайбер кеше әйтә: «Эчем пошса, кычкырып җырлый башлыйм», — ди. Эчем пошса, мин җырлый алмыймын. Мин халыкка җырларга өйрәнгәнмен. Музыкантым Кәрим Габидуллин өенә барып җырлыйм мин, күнегүләр ясыйм. Ялгыз гына җырламаем. Әйтәләр: «Син өйдә дә җырлыйсыңдыр инде?» — диләр. Җырчы буш өйдә ни өчен җырласын, профессиональ җырчы күнегүләрдән тыш өйдә, ялгызлыкта җырларга тиеш түгел. Җырсыз калуымны мин күз алдына китерә алмыйм.

— Классик музыка турында сөйләшеп алыйк әле... Классик музыка дигәннән, мин иң беренче, әлбәттә, татар музыкасын күз алдында тотам, аннан урыс музыкасын, бөтендөнья классикасын әйтәм. Рөстәм Яхин, Мансур Мозаффаров, Сәйдәш, Габәши... Синең репертуарыңдагы халык җырлары белән классиканың мөнәсәбәте нинди чагыштырмада? Син халык җырлары белән дан алдың, үстең.

— Классиканы бик яратам, классикасыз җырчы була алмый! Романсларны күп җырладым. Опера тыңларга бик яратам. Яхшы җырчыларны инде... Сәйдәшнең, Яхинның йөрәккә үтеп керә торган моңнарын мин алдым... Мин хәтерләмим, классиканы җырлаганда халыкның шаулап утырганын. Димәк, тапшыра белсәң, классиканы халык ярата... Урыс җырларын да күп җырладым. Урысча җырларга мин Руслановань тыңлап өйрәндем. Тукай төбәге, Чаллы ягында урыс авылларында да җырлап йөрдем, ду килеп кул чаба урыслар. Рәхмәт әйтеп калалар.

Җырны аны тапшыра белергә кирәк. Ни турында җырлаганыңны аңларга кирәк, ни әйтергә теләгәнеңне аңларга кирәк һәм шуны йөрәк аша, моң аша залга тапшырырга кирәк. Йөзнең унысына барып җитсә дә яхшы. Җырчы кешеләр күңеленә якты хис бирер өчен җырлый. Җыр ул бай кешене дә җылата ала, ярлыны да көлдерә ала. Җыр ул халык язмышы турында булырга тиеш. Шаян җырмы ул, такмакмы ул, классикамы ул — халык язмышы турында булырга тиеш. Яки халыкның узганы, бүгенгесе, яки киләчәге турында. Халык арасыннан чыккан җырчының максаты Аллаһы Тәгалә тарафыннан биргән талантын үстереп, халыкка кайтару булырга тиеш. Шул максатлар өчен ул, йогалар, сихерчеләр кебек, могҗиза булдырырга тырышырга тиеш.

— Соңгы вакытларда син караңгырак төсле күлмәкләр киеп сәхнәгә чыгасың. Бу синең зәвыгыңмы?

— Кара күлмәк кигән хатын-кыз озынрак күренә, кара күлмәк буйны озын күрсәтә. Юанлыкны яшерә кара төс.

— Син Зиннур Гыйбадуллин белән озак еллар кулга-кул тотышып иҗат иттең. Ни әйтер идең бу турыда?

— Чын мәгънәсендә ул минем иҗат кисәгем! Ул минем иҗат тегермәнемә су җибәреп торучы булды!

— Әлфия Авзалова, Зиннур Гыйбадулин һәм Гөлшат Зәйнашеваны Өчлек иҗат лабораториясе дип атарга буламы?

— Була! Ул шулай булды да!

— Өчегез бергә иҗат иткән җырларның саны бармы?

— Унике җыр! Мин аларны еллар буе җырлап йөрдем. Халык кат-кат җырлата иде. Репертуарда булмаса, залдан сорап җырлаталар иде ул җырларны. Репертуарымның туксан проценты Гөлшат сүзләренә язылган җырлардан тора. Гөлшат Зәйнашева сүзләренә җыр язмаган композиторлар юк иде безнең заманда.

— 1957 елда татар халкына олы бәхет иңде. Ирләр тавышы — Илһам, хатын-кыз тавышы — Әлфия. Татар халкын шушы ике канат 50 ел буе яшәтә. Моң канаты! Илһам синнән өйрәндеме, әллә син — Илһамнанмы? Әллә сез бер-берегезне тулыландырып тордыгызмы?

— Илһам соңрак килде ул җырга, ул консерваториядә укый иде, мин инде җырлый башлаган идем. Илһам килде ансамбльгә, мин Илһамны йотлыгып тыңлыйм. Илһамнан берничә форшлаг (борма) өйрәнеп алдым. Аннан моң бормаларын эләктергәләдем. Икебездә дә башкорт ягының моңы бар. Илһам белән бергә эшләү ул минем өчен мәктәп иде. Җыр башкару техникасы буенча Илһам дәресләрен алдым мин. Мин аны гомерем буе маяк дип атадым, ул миңа җыр өлкәсендә маяк булды.

## Якташлар, теләктәшләр

«Юк, кайтмас яшь гомер,
Калды ул еракта...» —
Бүген дә шушы җыр
Яңгырый йөрәктә.

Бу җыру — үткәннән,
Яшьлектән истәлек:
Хәлләрем шундыйрак —
Тыялмыйм хисләрем...

Яшьлекне минем дә
Сагынган мәлләрем:
«Яшь гомер бер узгач...»
Шундыйрак хәлләрем.

Шушы Җыр, шушы Моң
Хәтерем түрендә.
Җырчыга кушылып
Кабатлыйм бүген дә:
«Яшь гомер бер узгач,
Кайтмый ул яңадан...»
...Олыгаям, ахрысы, —
Яшь ага яңактан.

*Л.Лерон*

1997 ел, 14 апрель. Казан. К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры. Актаныш һәвәскәрләре концерты.

Сәхнәгә Әлфия Авзалова чыга. Аны аягүрә басып каршы алалар.

Әлфия. Рәхмәт, дусларым! Унҗиде яшемнән җырлыйм. 46 нчы ел китте минем җырлый башлаганыма. Һаман җырлыйм әле, Аллага шөкер. Ләкин җырламый тордым җиде ай. Авыру екты үземне. Котылдыммы мин аннан, котылмадыммы, әмма аяк өстендә сезнең каршыда басып торам, шөкер. Сезнең каршыга чыгуым белән бәхетле мин! (Тамашачы кул чаба, алкышлый.) Рәхмәтләр яусын барыгызга да! Минем авыруым турында Себердә дә, Мәскәүдә дә ишеткәннәр. Барысы да минем өчен борчылып, хәлемне белешеп тордылар, рәхмәт! Яхшы врачлар мине дәвалады. Рифкать Таҗиев миңа операция ясады. Алтын куллы врач! Рәхмәт! Аллаһы Тәгалә күпме гомер биргән, шуны яшәрмен, иншалла. Сезнең өчен яшим, сезнең өчен җырлыйм. Махсус Әлфия апагызга багышлап язылган җыр. Свердловскида яшәүче Илгиз Сафиуллин җыры — «Киек казлар»...

Күктә моңлы җыр калдырды
Киек казлар чылбыры;
Яңа язларга кадәр
Сагынырмын бу җырны.

Җыр бик моңлы, Әлфия апа аңа үз моңын, үз җанын да өстәп башкара. Залда утыручыларның күбесе сиздермәскә тырышып кына елый. Күз яшьләрен никадәр тыйсаң, шулкадәр ныграк тышка бәреп чыга. Бу җырдан халык тетрәнгән иде. Бу халәтне аңлатуы кыен булыр. Ни өчен халык елый? Әлфиянең моңыннанмы, сүзләренә хисләнепме? Әлфиянең сабый чактан ук ятим үскәнлеге турында уйланыпмы? Миңа калса, халыкны ике төрле хис биләгән иде бу кичтә. Көйнең, сүзләренең моңына Әлфиянең даһи моңы кушылып, халыкның иң нечкә күңел кылларын тибрәтсә, халыкның бер өлеше, минемчә, моң патшабикәсе Әлфия Авзалованың катлаулы операцияләрдән, чирдән котылып, янә иҗат вахтасына басканына куанып елый иде. Әйе, шулайдыр. Җыр соңында халык Әлфия апаны аягүрә торып озак алкышлады.

Бу кичәдә Әлфия апа тагын ике җыр җырлады. Аның һәр җыры алкышларга күмелде. Аны кат-кат сәхнәгә чакырдылар, аягүрә басып, озак алкышладылар. Бу атаклы җырчының яңадан сәхнәгә, җырга кайтуы иде.

# Бозылган ураза

— Балачак. Җыракай белән генә торабыз бит. Төрмәгә кермәгән ие әле Җыракай. Бәрәңге кырып, мин җыеп кайткан алабутаны кушып, эпекәй сала, пешкән бөтеннәрне киштәгә тезеп куя. Бу эпекәйләр Җыракайга сәхәргә торгач авыз ачарга дип пешерелгән. Җыракай, димен, мин дә ураза тотам, димен. Сәхәргә торып эпи ашарга исәбем. Җәйге озын көннәр. Җыракай: «Ураза тот, су да эчмә, көне буе ач йөр, сәхәрдә генә ашарбыз», — дип, ураза тотарга өйрәтә бу мине. Сәхәрдә тәмле әйберләр ашый ул. Шуларны ашарга бит минем исәбем. «Әйдә, кызым, кабатла: илаһи ният кыйлдым вә рамазан минәл фәҗави халисалла тәгаләйһи Аллаһу әкбәр», — дип ниятләтте. Шулай кабатлап, кичен авыз ачтык. Юынабыз да йокларга ятабыз.

Уяндым, көндез булды. Җыракай эшкә киткән. Эпине шүрлектән алып, астыннан кисеп ашыйм, малакай. Кисеп алган урынын аска куям, эпиләр бөтен булып күренеп тора. Мин берничә эпине шулай башладым. Әби сиздe эшемне: «Һай, Алланың каһәре суккыры, Алланы алдадың бит син! Үзең, ураза тотам, дидең, үзең урлап ашыйсың», — ди.

Шулай итеп, мин уразамны боздым.

Җыракай миңа кырыс та булгандыр, ләкин ул минем балаларымны караштыр, аларны үстереп, кияүгә биргәнче карап вафат булды, урыны җәннәттә булсын!

# Шомырт кызы

Күк капусын гомердә бер
Безгә дә Тәңре ачты;
Иңдерде ул Актанышка
Иң моңлы сандугачны.

Сандугач дигәнебез ул,
Әлбәттә, Әлфиябез;
Йөз яшә безнең бәхеткә,
Тәңредән иңгәнебез.

*Р.Әхмәтҗан*

Кич утырырга сөйләшкән идек. Ишектә Әлфия апа. Аның өе тулы кунак, Кипрдан кияве Равил белән кызы Зөлфия, аларның ике кызы, олы кызы, аның ике баласы кайткан. Өендә урын калмаган чакта, Әлфия апа безгә кереп кунгалый.

— Шөкерме хәлләрегез?

— Шөкерле-бөкерле, Әлфия апа, әйдә уз!

Әлфия апаның кәефе шәп.

— Карчык! — дип, хатыныма эндәшәм.— Кәмпер керде!

Мин, шаярып кына, Әлфия апаны «кәмпер» дип йөртәм, ул үзбәкчә «карчык, әби» дигән сүз.

Әлфия апа көлә:

— Чукынмыш! Миннән гел кәмпер ясап бетердең...

— Карчык, кәмпер керде, чәй-табын әзерлә, без озак сөйләшәчәкбез.

Табын янына җайлаштык. Бу «кич утыру» дип атала. Кич утыруда балалар да катнаша. Һәркем Әлфия апаны тыңларга, аңа сораулар бирергә хаклы.

— Әлфия апа белән әңгәмә корабыз бүген... Синең белән күптәннән утырып сөйләшергә, иркенләп гәпләшергә җыенып йөрибез, һаман дөнья безне куа... Бүген син дә буш вакыт таптың, минем дә вакыт тыгыз түгел... Синең хикәятеңне бөтен вак күренешләре белән язарга тиешбез.

— Мин Актаныштa үзешчәннәр белән җырлап йөргән кыз бит инде. Кара чәчле, кара кашлы, кара күзле, кара толымлы идем. Мине «Шомырт кызы» дип йөртәләр иде. Чөнки мин гел «...шомыртым»ны җырлый идем.

Әлфия апа салмак тавыш белән «Өй артында шомыртым» җырын башлый. Аның куәтле тавышы бүлмәгә сыймас иде, ләкин ул үз тавышының мөмкинлекләрен бик яхшы белә. Аннан, кычкырып җырлауга караганда, салмак моңлануның үзенең бер сихере, ләззәте бар. Әлфия апа беркайчан да мәҗлесләрдә: «Әйдә, Әлфия Авзалова, җырлап җибәр әле безнең өчен!» — дигәннәр шаукымына бирелеп, авыз күтәреп җырламады. Ул үз кадерен үзе белә. Ике сәгать сәхнәдә җырлап кайтканнан соң, тагын кемдер өчен өч сәгать җырлап утырсынмы?

Өй артында шомыртым бар,
Яннарында бөрлегән шул,
Яннарында бөрлегән;
Синнән башка сөйгәнем юк,
Син бит минем бер генәм.

Ишетелер-ишетелмәс кенә җырланган бу җыр гаять тәэсирле иде, табын янындагы балалар: Нурбәк, Байбулат, Әлфия апаның оныгы Рената, хуҗабикә Рузия ханым да Әлфия апаны тыңлый.

Бу аерым бер сәнгать, моны сәхнәдән дә, радиодан да, телевидениедән күреп тә, ишетеп тә булмый. Әлфия апаның драматик таланты шушы салмак җырга туплана, монда тавыш гайрәтен билгеләүче юк, тынның озынлыгын үлчәүче юк, монда бары тик күңел моңы, җан тетрәве генә бар. Бу сабыйлар өчен генә түгел, без, олылар өчен дә вокал дәресе иде. Әлфия апа җырламый, ул җаны белән хисләрен сөйли иде.

Өй артында шомыртым бар,

Чәчкәләре хуш исле шул,
Чәчкәләре хуш исле;
Шомырт янында айрылдык,
Оныта алмыйм шул кичне.

Могҗиза тәмам. Рузия ханым, күз яшьләрен күрсәтмәскә тырышып, чәй хәстәрләгән була. Нурбәк белән Байбулат кул чаба.

Рената:

— Әннә-кә, еще-еще! — дип кычкыра.

Оныклары әбиләрен «әннәкә» ди.

Җырчы моң мохитеннән чыгып елмая.

— Халык үтереп кул чаба торган иде. Кая гына барсам да, теге кара кыз, Шомырт кызы килгән, дип, халык клубка җыела, гел шул «...шомыртым»ны җырлаталар. Кешеләргә минем җырларым ошый, бәлки, мин башкаларга караганда моңлырак җырлаганмындыр, бәлки, мине сабый буларак алкышлаганнардыр, бәлки, ятим икәнемне белеп, миңа аеруча миһербанлы булгандыр халык...

— Әлфия апа, «Өй артында шомыртым»ны бөтен җырчылар да бер үк сүзләр белән җырлый. Җырлар китабында да шул ук сүзләр, ә менә син гел бүтән сүзләр әйтәсең. Ул сүзләрне әллә син үзең уйлап чыгарасыңмы?

— Үзеннән-үзе шулай җырлана инде ул. Актанышта шулай җырлыйлар иде.

— Кечкенә чактагы хатирәләрең?

— Әтәем клиндер алып кайтты беркөнне. Клиндерләр тезмәсен муеныма кигезде. Ул шатланганымны белсәгез!.. Ул клиндернең хуш исе!.. Бишектә икенче кыз бала ята. Флюра исемле... Шул клиндерләрнең берсен, теш белән сындырып, озак кына чәйнәп, бишектәге сеңлемә каптырдым... Бер клиндерне сеңлемә чәйнәп каптырам, икесен үзем ашыйм...

Бервакытны әтәй әллә каян миңа яңа ботинка апкайтты. Үзе җырчы булган. Әтәйнең тавышы урамның башыннан башына ишетелә торган булган. «Әнә, Авзалетдин кайта, тагын салмыш», — ди торган булганнар. Ботинканы кидем дә урамга чыктым. Аяктан салдым каталарымны.

— Нигә салдың инде, киеп йөрсәң ни булган?

— Тузмасын дип. Уйнаганда тузан кунмасын дип... Исемдә, аяктан салдым да, дус кызлар, малайлар мине урап алган. «Каталарың матур да матур», — диләр. Уенга бирелеп, каталарымны урамда калдырып кереп киткәнмен. Миңа ул вакытта дүрт яшь чамасы гына булган әле. Инәем әйтә: «Кайда ботинкаң?» — ди. Йөрәгем жу итте. «Монда гына куйган идем», — дип, инәйне тегендә алып барам, монда алып килəм. Кое янына алып киттем. Инәй сугып җиппәрде, малай, барып төштем... Инәй усал иде... Җәй узды, көз җитте, яфраклар коелып бетте, мин һаман ботинка эзлим.

— Менә синең каталарың! — дип, малайлар таяк башына киндерәләреннән элеп, минем ботинкаларымны алып килеп күрсәттеләр. Кемдер көнләшеп аларны яшереп куйган булган. Аны агач башына ыргыткан булганнар, яфраклар коелгач, ботинкаларның эленеп торганын малайлар күргән. Урламаганнар! Ыргытканнар гына... Шунда инәй мине бик каты кыйнады. Гомергә дә онытмыйм...

Әлфия апа туктады. Суынган чәенә карап уйга калды. Аның йөзе гаять сагышлы иде, без, аның бала чагына кайтып төшкәнен аңлап, сүз кузгатмадык.

Әлфия апа ике учы белән йөзен каплады. Ул үксүен тыярга тырыша иде. Күз яшьләрен йотып дәвам итте:

— Инәй тиф белән авырый башлады. Өйдә берсеннән-берсе кечкенә өч кыз бала. Инәйнең үлгәнен хәтерлим. Ләкин мин җыламадым. Курчак белән уйнап утырдым. Агач кашыкларга чүпрәк-чапрак бәйләп, үзем ясаган курчаклар иде алар...

Инәйне җирләделәр. Инәйдән соң озак тормады, яңа туган сеңлем дә үлде.

— Әниең үлгәч, сез кем кулына калдыгыз инде?

— Әби килде Актаныштан... Ул вакытта әби түгел әле ул — хатын. Дүрт ирдән аерылып кайткан хатын. Закирә апа. Инәемнең апасы иде ул. Дүрт иргә барып, ник берсеннән бәбәй тапсын! Шул апам безне Актанышка алып кайтты. Дүрт яшенә җиткәч, Флюраны детдомга бирде. Такталачык дигән авылга. Мине үзенә алып калды... Сугыш вакыты... Ач... Әбием икмәк белән тотылды, кесәсеннән арыш чыккан... Төрмәгә утырттылар, мине детдомга бирделәр. Әбине биш елга утырттылар.

— Яшь баласы бар дип тә тормаганнар!

— Бала сиңа! Алдылар да киттеләр... Китәр алдыннан ул миңа клиүнкедән букча тегеп бирде. Шул букчаны тоттырды да: «Бар, үскәнем, Яңа Әлемгә үзең генә кит», — диде.

Яңа Әлемдә детдом. Ул мине Яңа Әлемгә озата бармады. Рөхсәт итмәгәннәрдер инде. Ялгызым гына киттем. Кара язмышымны ияртеп, берүзем киттем.

— Сеңлең янына Такталачыкка түгелмени?

— Ю-ук! Такталачыкта кечкенәләр, анда аксак-туксак, сукыр балалар...

Жырчының тагын күңеле тулды.

Әлфия апа, ялгыз башы Актаныш тавының башына менеп, түбәнгә, Актанышка карап озак тора. Әнә аларның ятим өе, олы тутасы Закирә (Жыракай) дә капка төбендә аңа кул изи. Нәрсә көтә бичара хатынны төрмәдә? Исән кайтырмы ул аннан? Нәрсә көтә аны алда?

Агыйдел җәйрәп ята, әрәмәләр, анда-санда балыкчы көймәләре күренә. Кыр үрдәкләре канатларын сызгыртып очып китә.

Тау түбәсендә әрем исе килә. Әремнең әчесе сөттә булса да тәмсез, ипигә әрем эләксә дә тәмсез, әмма Актаныш тавы түбәсендәге әрем исеннән дә тәмле ис юктыр, валлаһи. Кечкенә Әлфия моңарчы әремнең дә хуш исле икәнен белми йөргән ләбаса.

— Актаныш әременең исен бүтән бер генә җирдә дә исни алганым булмады, — ди Әлфия апа. — Шуннан соң киттем бата-чума... Чабатамның төбе юк, сугыш вакыты бит ул... Өстемдә җизнидән калган бишмәт, кырык кына ямавы бардыр, җиңе кул очыннан бер метр асылынып тора... Әнә шулай Яңа Әлем детдомына карачкы кыяфәтендә барып кердем... Гөлсәйдә апа Фәттахова мине икенче каласста укыткан иде, үзенең дә минем чаклы малае бар, ире сугышта... Мине күрүгә, ул, баскычка йөгереп чыгып, кочаклап: «И бәбекәем, син дә килдеңме, әйдә, бәбекәем», — дип каршы алды.

Ашау юк. Детдомда да өшегән бәрәңгеләрне таяк белән чокып-чокып алабыз.

Шулай итеп, җиденче классны бетердем. Әйттеләр: «Олы малайлар, олы кызлар, барыгыз, авылларыгызга кайтыгыз... Без сезне монда тота алмыйбыз, — диделәр. — Кемнәрегез бар авылда?»

Әбием төрмәдә утыра әле, чыкмаган. «Күршебез бар», — дидем. Мөхәммәтвагыйз Ильясов, хатыны Саҗидә апа иде. Шул күршеләремә кайттым инде. Үзләрендә җиде бала. Алдылар. Тәгәрәшеп барыбыз бергә сәкедә йоклайбыз. Алар ни ашаса, мин дә шуны ашыйм. Ул игелекле кешеләргә ничек кенә рәхмәтләр әйтәсе икән?

Әби — төрмәгә, мин детдомга киткәч, безнең мескен өйне күрше-күлән коймалары-киртәләре белән өйалларын ягып бетергәннәр. «Кем яга, нигә ягасыз?» — дип кисәтүче юк. Мин дә бер сүз дә әйтмим. Ул өйдә торырлык түгел иде. Әбием төрмәдән кайтты. Аны совет төрмәсендә социалистик хезмәт белән тәрбияләп чыгарганнар. Торыр урыны юк, Мөхәммәтвагыйз абыйлар аны да үзләренә алдылар, бахыркайларым... Мөхәммәтвагыйз абый белән Саҗидә апаның миһербанлы, киң күңелле булуы турында аеруча әйтәсем килә. Закирә тутам белән унбер җан бер кечкенә өйдә. Шуларның икесе аларга чит-ят кеше, югыйсә сыйдырмасалар да була иде.

Шуннан соң мине МТСка избачка урнаштырдылар.

— Сезне кабул иткән гаиләнең, Ильясовларның йортлары исәнме әле?

— Иске йорт урынында яңасы салынган, ул исән. Чыршылары да үсеп утыра. Шул чыршыга менеп уйныйдыр идек. Ильясовлар мәрхүм инде.

— Такталачыктагы детдомның (исән булса), һич югында, урынын төшерергә кирәк, син басып торган тау башыннан Актанышны төшерергә кирәк.

— Төрмәгә кергәнче, әбием саклык кассасында төнге каравылчы булып эшләде, пистолеты да бар тегенең. Ике ботыннан тотып селкесәң, «а» хәрефе дә төшми, әби укымаган иде. Әби түгел әле ул чакта, матур хатын иде. Бер тапкыр әйтә бу: «Әйдә, кызым, сберкассаны бикләек тә утын урлап өйгә алып кайтаек», — ди. Сберкассаның утынын урларга исәбе. Җизнәйнең лапырдап торган бишмәте астына өчәр-дүртәр түмәр кыстырдым. Әби үзе дә итәк астына утын кыстыра, бәйли. Таң атканчы ике-өч мәртәбә юлладык. Әбинең билендә пистолет.

— Каракларны атарга!

Әлфия апа ихлас көлә, тыңлаучылар да аңа кушыла:

— Аталмый инде ул аны! Аталмый. Аның патроны да юк иде.

— Синең өстәге бишмәт кайсы җизнәңнеке? Шушы Закирә тутаңның ireме инде?

— Ие, Әмирҗан җизнәй бишмәте... Һи, Батуллакаем, җизнәйнең сугышка китүенә сөенүләремне күрсәң. Атам авылыннан Актанышка кайткач, ике ятимә кыз ишек төбендә мышкылдап торабыз. Керегез, узыгыз, балалар, диmi җизнәй кеше, акаеп карап утыра. Үз балалары юк. Шар күзле, сап-сары чәчле иде Закирә түтәебезнең ире — Әмирҗан җизнәй. Юлда саламга төреп алып килделәр бит безне Актанышка, өстә юк бит. Җизнәй ашап утыра, үзе ямьсез итеп карай безгә таба, минем күз идәндә. Флюра бәләкәй генә, бичара кыз, ул миңа таба елыша. Бала күңеле белән сизәмен, бу кеше безне яратмаячак. Закирә түти сәкегә утыртты безне. Жылына башладык. Сугыш чыкмаган ие әле без аларга кайтканда. Ашаган вакытта җизнәй гел мин ашаганны йотып утыра иде, усал караш җаныңны өшетә, белдеңме! Безгә рәт юк, сеңлем дә почмакка посып кына утыра. Мин дә җизнәй юлына туры килмәскә тырышам. Туры килсәң, бәреп тә җибәрер... Сугыш чыкты. Җизнәй киткәндә Закирә түти (мин аны «әби» дим инде) кычкырып жылый башлады... Сугыш чыккач, җизнине алалар икән, дигәч, теләк тели башладым. Шушының күзләрен кабат күрмәсәм ярар иде, кайтмасын ие бу сугыштан, дим.

Ике-өч айдан җизнәм Әмирҗанның үле хәбәре килде...

МТСка урнашканда миңа унбиш яшь, паспорт юк. Өч ел китапханәче булып эшләдем, паспорт алдым. Унсигез яшемдә мине Казанга алып киттеләр. Җырлыйм бит, минем җырлаганымны күрсәтергә дип алып киттеләр.

Язгы чәчү җитсә, агитбригадага алып китәләр. Агитбригадада тамагым туйды. Арыш бирсәләр, куырып ашыйбыз. Борчак бирсәләр, пешереп ашыйбыз. Колхоз ашата, өстән шулай куелган. Тамак хакына йөрибез, шөкер.

— Концертта ничә җыр башкара идең?

— Күп җырлый идем. Мәктәптә укыганда да укытучы берничә классны бергә җыя да: «Бүген җыр дәресе, сезгә Әлфия җырлый», — дип, кырык биш минут буе мине җырлата иде.

— Гармунчың кем иде?

— Гармун юк! Болай гына җырлыйм... Актанышта фотограф булып эшләүче Мәрзия апа Юнысова бар иде. Бераз үсә төшкәч, баянда миңа ул уйный башлады. Миңа «Кәккүк»не, «Гөлҗамал»ны җырларга шул Мәрзия апа өйрәтте. Казанга килгәч, Җыр һәм бию ансамбленә шушы җырларны җырлап кердем мин.

— Аңа чаклы әле син пароходта да йөрдең түгелме соң?

Әлфия апа шаркылдап көлә.

— Казанга барырга акчам юк, юл буе җырлап бардым... Гел агитбригадада йөрим бит мин... МТСның директоры сугыштан кайткан кеше. Шул әйтә: «Башка авылларда гел җырлап кына йөрмә әле син, гел агитбригада белән чыгып китәсең, клубны кем ачар, избачта кем эшләр? Мин сине эшеңнән алам! — ди. Шуннан мин тегенең каршысына килеп бастым да, күзенә карап: «Алып кына кара, Камалиев абыйга әйтеп...», — дидем.

Әлфия апа рәхәтләнеп көлә, аңа кушылып барыбыз да көләбез.

— Теле дә булган бит, малай, кара син аны, орчык кадәр кызчык нишли, ә! Актаныш ягында шушы көнгә чаклы шуны сөйлиләр. МТСта эшләгән чакта, клубны ачып, бичер эшләгән булабыз. Чабата кигән кызлар чаж-чож биегән була, тузан туза клубта. (Эче катып көлә.) Бер-береңне күрмисең, бер-bereңә килеп бәрелмәс өчен кармаланып биибез. Яшьләр таралды. Клуб җылы. Клубны бикләп, китапханәгә кердек. Рәсимә исемле тракторчы кыз белән шунда йокларга калдык. Ишекне эчтән бикләгәндә, «бисмиллаһ иррахмән-ир-рахим» дип кычкырдым. Бусы — җеннәр колагына. Йокларга яттык. Тышта кышкы салкын, электр чыбыклары, телефон баганалары чыжылдап тора. Клуб белән китапханә стена белән генә аерыла. Йокыга гына киткән идек, клуб эчендәге дөбер-шатыр тавышка уянып киттек, мең кеше бии иде клубта. Рәсимә дә курыкты: «Бу клуб җенле икән», — диде.

Клубны сүтелгән мәчет бүрәнәләреннән китереп салганнар икән. Клубта шахмат өстәле бар иде. Ул бик авыр, берничә ир кеше генә күчереп йөртерлек калын таштан эшләнгән иде ул. Сәхнәдә тора иде. Шул өстәлне дөбердәтеп тартып төшерәләр, идән буйлап сөйрәп йөриләр, малакаем. Рәсимә белән кочаклашып, бисмиллабызны укый башладык. Яндык-пештек, ага тир...

— Бәлки, авыл егетләре сезне шулай шаярткannardыр?

— Юк шул, апаем, юк. Анда берәү дә калмады. Клубны карап, эчтән дә, тыштан да бикләп куйдык. Бер кеше калалмый анда. Төнлә клуб суына, калган кеше катып үләр иде. Әй бииләр, кычкырган тавыш юк. Пич бар китапханәне җылыта торган, шул пичтән... (Әлфия апа ямьсез тавыш белән уларга тотынды, кич утыручы балалар әниләре янына елыша төште.) «У-у-у-у» дигән тавыш ишетелде. Шуннан соң, су сипкән кебек, бию дә бетте, тавышлар да тынды, улау да бетте. Бер-ике сәгать калтыранып утырдык да, таң ата башлагач, МТС каравылчысы Саимә апа янына йөгердек, шабыр тиргә баткан килеш чатнама суыкка чыгып киттек. Саимә апага килеп егылдык: «Клубта җеннәр...» — дип, хәлне сөйләп бирдек. «И-и, балалар, әйтергә онытканмын бит, чыннан да җенле клуб ул. Мосаллия исемле кыз егете белән шул клубта куна калганнар ие, — ди каравылчы Саимә апа, — төне буе пәри туен тыңлап, котлары очкан иде. Шуны сезгә әйтергә онытканмын, — ди. — Моннан ары, кояш баеганнан соң, анда ялгыз калмагыз».

Шуннан соң мин куркып калганмын, әбием — Җыракаем — мине атна буе өшкертергә йөртте.

# Аерылышу

— Казанга киттем, Җыракайны калдырып. «Кияүгә чыккач, Җыракаем, мин сине үз яныма, Казанга алдырырмын, — дим. — Хуш, Җыракаем! Хуш, сау бул, Актанышым!»

Матур була, ямьле була
Яз көннәрең, җәйләрең...
Исән булсам, бер кайтырмын,
Язлар кебек әйләнеп.

Хуш, авылым, сау бул,
Сәламнәр көт,
Таң җилләре искәндә.

Мин җырлармын сине сагынып,
Өзелеп искә төшкәндә.

Җыракаем үксеп җылый. Аңа кушылып мин җылыйм. Шулай җылашып аерылыштык. Пароходка акчам юк. Билетсыз утырып киттем. Койрыкта җырлыйм, бөтен халык минем янга җыела. Билет тикшерә башлагач, эскәмия астына кереп качтым. Тикшерүчеләр узып китте. Төн җитте, матрослар идән юа башладылар. Берсе күрде мине, тартып чыгардылар. Суга ташлыйбыз хәзер үзеңне, диләр. Котым очты, елый башладым. Кешеләр җыелды. Халык яклады, ул җырчы кыз, тимәгез аңа, барсын, дип, алып калдылар. Алайса, җырлап күрсәтсен, диләр матрослар. Шуннан җырладым инде. Шулай итеп, билетсыз Казанга киттем.

Казанга барып җиттем. Музыка училищесында җыелышып тыңладылар. Әүхәдиев иде анда директор. «Тавышың һәйбәт, — диләр. — Казанда кемнәрең бар?» — дип сорыйлар. «Беркемем дә юк, — мин әйтәм. — Әти дә юк, әни дә юк, — димен. — Берәрсенә квартирга кертсәләр, керләрен дә юар идем», — дим. Әүхәдиев: «Квартираң булмагач, син ансамбльгә бар», — дип, мине ансамбльгә алып китте.

Ансамбльдә мин «Кәккүк» белән «Гөлҗамал»ны җырлаган идем, бишкуллап алдылар. Квартир табып, мине шул квартирга урнаштырдылар. Фатир хуҗасы гүләщий хатын булып чыкты бит. Баласы да бар. Һәр көнне ирләр килә. Төрле ирләр. Алар барында мин почмакта утырып торам. Куркам инде... Ләкин миңа кагылучы булмады...

Шушы хатын төнлә бәби тапты. Шуны әллә нәрсәгә төрде дә, тере көйгә базга төшереп, шунда калдырып чыкты. Баздан баланың елаганы ишетелә. Шул тавыш әле дә колагымда тора. Шунда елап үлде бала. Икенче көнне Зөләйха апа янына баргач, елый-елый барысын да сөйләдем. Шуннан мине, теге хатыннан алып, Сул Болак урамында яши торган Һаҗәр апага керттеләр. Әшнә авылыннан мишәр хатыны иде ул. Менә шунда рәхәтләнеп яшәдем. Идәннәрен юам, керләрен юып үтүклим. Филармониядән акча ала башладым. Саручий базарына барып, тотылган күлмәкләр сатып алдым, тормыш итәргә исәп...

Разия апа Тимерханова үзенең өстендәге пәлтәсен салып бирде. Бик матур пәлтә иде, шуны киеп йөрдем. Кыш та шул, җәй дә шул. Ансамбль белән дөнья гизә башладым. Себергә, Урта Азияләргә барып кайттым. Өч ай йөреп кайттык. Җыр өйрәтәләр миңа, бөтен программаны өйрәнеп чыктым, малакаем.

## Беренче никах

— Һаҗәр апада торганда, бер солдат килеп керде. Зиннур исемле бу егет Һаҗәр апаның авылдашы икән. Зиннурның күзе миңа төшкән. Килеп йөри инде бу хәзер. Шуннан әйткән бу Һаҗәр апага: «Бу кыз миңа бик ошый», — дигән. Һаҗәр апа да мине мактаган: «Бик уңган кыз, бөтен эшне эшли белә, кулы кулга йокмый», — дигән. «Чык Зиннурга, ул — лейтенант!» — ди хуҗа апа.

Минем күз хәрбиләргә төшә башлаган иде инде. Йолдызлыларына инде, аркылы тасмалыларга борылып та карамыйм, түлке йолдыз булсын!

Мин яратуның ни икәнен белмим, ләкин иптәш кирәк икәнен чамалыйм.

«Әйдә, Зиннур, сал өсләреңне!» — дим.

Салмый бит теге. Фуражкасын гына салып куя. Чәй эчкәндә дә өстен салмый. Бервакыт тегенең шинеле кыегаеп китте, погонында тасма гына.

«Әлләй, — мин әйтәм. — Бу офицер түгел икән», — дим.

Егет киткәч, Һаҗәр апа керде. «Нигә мине, ул — лейтенант, дип алдадыгыз! — дим. — Лейтенант ул йолдызлы була, бу бит аркылыга сары мунчала таккан», — дим. «Хәзер инде аңа карамыйсыңмы?» — ди Һаҗәр апа. «Белмим әле», — дидем.

Кәеф китте. Алдадылар. Ул армиядән кайткан сержант булып чыкты. Шулай да ул мине үзе кодалады. «Торырга урының бармы, син мине кая алып кайтмакчы буласың?» — дип сорау юк.

Шуңа кияүгә чыктым да куйдым. Бу бер ялгыз апада квартирда тора икән. Ишек төбендә бер койка бар, шунда ак чаршау корган да шунда йоклый.

«Ни өчен син шулай тиз генә кияүгә чыгып куйдың?» — дип сорасаң, мин аңлата алмыйм, бәлки, мин ялгызлыктан туйганмындыр. Мин яратуны белмичә чыктым.

Разия Тимерханова әйтә: «Кияүгә чыгасың чыгуын, беренче төнне ир белән йоклавы, ай-һай, бик кыен бит», — ди.

Котым очты инде. Туй ясаган булдык инде шунда. Ишегалдындагы сарайда беренче төн узгарырга кердек. Бу мине кочакларга азаплана. Ләкин мин үземә тидертмәдем.

Аерым йокладык. Разия апа куркытканнан соң, өч ай якын китермәдем иремне. Сабыр кеше, сүземне тыңлады. Ярый әле өченче көнне озак гастрольләргә чыгып киттек. Котылдым бит мин тегеннән.

Гастрольдән кайттык. Башка кайгы төште, фатир эзлибез икәүләп, әйбәтрәк фатир булмасмы дибез. Бер бүлмәдә хуҗабикә, аның улы, без икәү — ничек яшәмәк кирәк? Безнең карават ишек төбендә, өстебез-

дән кеше йөреп тора. Башым эшләмәгән икән, дип уфатанам, квартирсыз кешегә ничек итеп кияүгә чыгарга кирәк, уйлап карале син. Бүгенге акылым булса, мин бары тик хәлле кешегә генә чыгар идем.

Бер квартир таптык, әле бала юк. Ягодный бистәсендәге Базарная урамыннан. Тар инде, ишектән керүгә такта белән бүленгән бер бүлмәчек. Шунда барып кердек ирем белән. Ирем заводта конструктор булып эшли. Белемле кеше. 1923 елгы кеше, миннән олы. Арада ун яшь.

— Нормально!

— Беркөнне, шул фатирдан чыгып, Декабристлар урамына таба барам, вокаль күнегүләре ясарга ансамбльгә. Сара апа Садыйкова биргән бәрхет башлык минем башта. Кулымда зәңгәр клиүнкедән теккән сумка. Өстемдә Разия Тимерханова пәлтәсе. Декабристлар урамына Химиклар сарае каршысыннан чыктым. Трамвай көтәм. Трамвай күренде. Мин уйланып торган арада каршыма бер абзый килеп басты. Карт та түгел, яшь тә түгел. Ямь-яшел чапан кигән. Башында кама бүрек, түгәрәк постаудан тегелгән. Кып-кызыл җирән чәчле иде ул абзый. Мыегы да җирән, матур җирән. Җирәнгеч җирәннәр була бит. Күрсәң, шаккатарсың, валлаһи. Бите алсу төстә. Гаҗәпсенеп карап торам.

«Кызым, бер генә тәңкә акча бирсәңче», — ди бу. Кесәмдә ике тәңкә акчам бар. Бер сумга бер атна торып була иде элек. Бер берлекне суздым да: «Мә, бабай», — дидем. Алды, рәхмәт әйтте.

— Татарча сөйләшәме?

— Татарча! «Рәхмәт кызым!» дип чатлатып әйтте. Карыйм, кайсы вагонга утырыр икән бу бабай, дим. Арттан машиналар выжлый, машина юлына чыкмады, артка чыга алмый ул, ләкин трамвайга да утырмады. Югалды бабай... Аптырадым. Остабикәләргә сөйләдем. «Хызыр галәйһи вәссәлам ул, — диделәр. — Хызыр Ильясны күргәнсең», — диделәр. Бабайларга да сөйләдем, алар да беравыздан: «Сиңа Хызыр Ильяс очраган, бәхетле булырсың», — диделәр.

Еллар буе күз алдымнан китмәде шул бабай. Гел шул турыда уйлыйм, бу — Аллаһы Тәгаләдән бер хәбәрдер, дим... Соңгы ике берлегемнең берсен бирдем.

— Ул сине сынап караган инде...

— Сынаган! Бирмәгән булсам, мин һаман хәерче булып кала идем... Аллага шөкер, алга таба мин интегеп тормадым... Уйламаган җирдән акчасы да килеп керә, шөкер. Балаларым, оныкларым мохтаҗлык күрмәде. Мин күргән дә бик җиткән, дигәндер Ходай. Фатирларым да бар, кызларым да урнашкан, зур хуҗаларыбыз да гел ярдәм итеп, акча эшләргә җай биреп кенә торалар. Мин хәер алмыйм бит, мин җырлап алам алар биргән акчаны, эшләп алам. Зәйлеләр, актанышлылар, Илбашы, чаллылар барысы да: «Әлфия апа, Әлфиябез», — дип кенә торалар.

Бервакыт Фәйзи абый Йосыпов белән Рәшит Ваһапов мине Актаныш ягына концерт куярга чакырды. «Барам, барам!» — дидем.

Ун көн Актаныш ягында йөрдек тә Казанга кайттык. Мин теге квартирга кайтам бит инде. Урамнар пычрак, таш-асфальт юк. Саз ерып китәсең, саз ерып кайтасың. Кайтып керсәм, өйдә «мырык-мырык» иткән тавыш ишетелә. Карасам, чучка йөри өй буйлап. «Әстәгъфирулла!» — дип кычкырдым. Хуҗа бу өйне урыска саткан. Абзарга чыксам — дуңгызлар, өйгә керсәм — чучкалар. Ирем шул чучка йөри торган якта өстәл янында китап укып утыра... Егылыплар китә яздым, малакаем... Бигрәкләр дә булдыксыз иргә чыкканмын икән, нүжәли ун көн эчендә башка бер фатир, башка бер почмак табып булмый, ә?! Исе дә китми, чучка белән яшәргә дә риза икән бу, дип, тагын киттем фатир эзләп. Гастрольдән арып кайткан, ял итмәгән, ашамаган-эчмәген килеш, саз ерып, фатир эзли чыктым. Киттем ансамбльгә.

«Гончаров урамында бер фатир бушый икән, син, Әлфия, шуны барып кара әле», — диделәр. Киттем. Хуҗаларга иремне мактыйм: «Эчми-тартмый, бик тәртипле, сүзсез, гамәлсез», — дим.

Шул апалар безне фатирга керттеләр. Икенче көнне иремне, чучкалар арасыннан йолып алып, шул фатирга алып килдем... Чучка белән бер почмакта утыра бит...

— Аның каравы укып утыра!

— Укып утыра! «Әстәгъфирулла-тәүбә, — дидем. — Мин чучка янында яши алмыйм, китәм мин синнән!..» —дидем, чыраена бәреп әйттем. Шул көнне мин чучкалы өйдә йокламадым. Ул шунда йоклап калды, мин Мәсрүрә түтәйләргә барып кундым.

Күчендек без чучкалы йорттан теге апаларга. Шунда мин беренче баламны, Гүзәлемне таптым... Балчыктан ябыштырып салган мунча кебек җир инде ул без тора торган урын. Дымлы... Гөлшат Зәйнашева килде. «Әстәгъфирулла, җырчы яңа туган баласы, ире белән шушы саманкада торамы?» — дип кычкырды.

Ансамбльгә, филармониягә кайтып, Гөлшат безнең хәлләрне сөйләгән. Шуннан соң директор Боголюбов белән берничә кеше килеп керде, безнең яшәү шартларын өйрәнергә. Өйрәнделәр. Боголюбов бер бүлмәле фатирда тора икән, ул яңага күчкән генә, әнә шул директор торган бер бүлмәле аерым фатирны миңа бирделәр. Аллага шөкер, аерым фатирга тиендек бит!.. Дуслар ярдәм итте, квартирны җиһазлап та җибәрдем.

«Кияүгә чыккач, мин сине Казанга алдырам», — дигән идем. Актаныштан Закирә-Җыракайны китерттем. Бер бүлмәдә без дүртәү булдык. Уйлана башладым: бу ир белән мин тора алмаячакмын, ярату да юк, бөтен йөкне мин берүзем тартып барачакмын икән, бала үстерү дә, әбине карау да, ирне көйләү дә, үземне көйләү дә минем өстә булачак, нигә миңа артык йөк, дип аерылдым да куйдым. Киттем дә бар-

дым, бер әйбер алмадым. Баламны, Җыракаемны иярттем дә теге юеш балчык мунчага әйләнеп кайттым. Шулай итеп, мин, иремне фатирлы итеп, үзем яңадан балчыкка кайттым. Аның каравы рәхәт иде, Җыракай бала карый, кызым сау-таза, вакытында ашатылган, киендерелгән, мин иҗат белән генә шөгыльләнәм. Хатын башымнан мин дөя кадәр иргә фатир алып бирдем.

— Ирең кыйный идеме?

— Юу-ук, нинди кыйнау ди! Тырнак белән дә чиртеп карамады. Бик ипле кеше иде ул, ата-анасы, туганнары да бик матур кешеләр иде...

— Ничәнче елны Казанга килдең?

— Илле беренче елның сентябрендә килдем... Ансамбльгә алдылар, ләкин мин, Актанышка кайтып, китапларымны, клубны тапшырырга тиеш идем, кайтып киттем дә илле икенче елны яңадан Казанга килдем.

— Актанышка кайткач озак тордыңмыни?

— Сагынылган иде бит, тордым инде...

## Икенче никах

— Ничәнче елда кияүгә чыктың?

— Кызым 1956 елда туды... 1955 елда чыкканмындыр дип уйлыйм... 1959 елда мин аерылганмындыр... Минем арттан Гомәр исемле бер өйләнмәгән егет йөри башлады бит... Артистларны, сәнгатьне бик ярата, үлеп ярата иде. Сәнгатькә гашыйк кеше. Минем арттан калмый, нык йөрде бу минем арттан. Теге балчык мунчага йортка шул егетне керттек бит Җыракай белән. Ул таксистларның хуҗасы иде. Булдыклы егет.

— Тагын фатирсыз иргә чыктыңмы?

— Чыктым инде, нишләтәсең, бик ярата иде бит...

— Сәнгатьне!

— Сәнгатьне дә, мине дә яратадыр иде. Яратмаса кыйнамас иде.

— Монысы кыйный идемени?

— Һу-у, малакаем, тукмак астыннан чыкмадым... Бик көнчел иде. Берәр ир, исәнмесез, дип сәлам бирсә яки кул биреп күрешсә, кайбер культурныйраклар бит әле синең кулыңның аркасын үпкән була... Мине бәреп торып кына җибәрә дә, малакай, шул кешеләр белән сугыша башлый.

— Шулай да куркып тормагансың, икенче бала тапкансың.

— Ул үзе теләде. Зөлфияне шунда, балчык мунчада таптым.

Атказанган артистка исеме дә биреп куйдылар. Шул тар мунчага бала бишеге асып, Зөлфиямне шул бишеккә салдык. Мин бала тирбәтәм, Җыракай аш әзерли. Ирем Гомәр бишеккә карап-карап торды да: «Миңа кыз бала кирәкми!» — диде. «Кирәкмәсә кит!» — дидем.

Боголюбовтан соң безгә директор итеп Хәят Әхмәдишинаны куйдылар. Гөлшат аңа минем хәлләрне кереп сөйләгән. Килде Әхмәдишина. Янында куштаннары да бар. Тикшерделәр, карадылар, яздылар. Шуннан Космонавтлар урамыннан өр-яңа йорттан җып-җылы ике бүлмәле, бар шартлары китерелгән фатир бирделәр. Күчереп тә куйдылар. Гомәрне алмадым. Ике балам, Җыракай белән дүртәү күчендек. Гөлшат Зәйнашева ишекне ачып җибәрде. «Җыракаем, — дим. — Кер әле, күр әле, без нинди өйгә тиендек!» — дип, иң алдан Җыракаемны кертеп җибәрдем. Кереп бүлмәләрне карап чыккач, сөенеченнән ауды бу. Җылы, якты, икенче кат... Урнаштык... Иркенлек, рәхәтлек. Бәхет басты гаиләмне, Аллага шөкер!.. Гомәрне кертмәдем яңа өебезгә. Бик холыксыз... (Әлфия апа чагыштырыр сүз табалмады, аннары кәгазьгә язарга ярамый торган сүз әйтте.) Пропискага, ордерга кертмәдем мин теге... Аның әнисенең йорты бар, ул шунда тора башлады. Кертмәдем.

Балалар йокларга ятты. Без тәнәфес ясадык. Тәнәфестә дә Әлфия апа сөйләүдән туктамый. Ничек итеп яңа фатирын җиһазлаулары турында сөйли. Чәй яңартып алганнан соң, тагын хатирәләр дәвам итә.

— Минем мәшһүрлек арта, минем үз бригадам бар, мине һәр шәһәрдә, һәр авылда, һәр республикада көтеп алалар. Уңыш хәттин ашкан. Шәп квартирым бар, ике балам сәламәт, Җыракай балаларны караша. Бар ягым җитеш. Ата ялкау ир белән дә, сугыш чукмары белән дә интекмим...

Минем бригадама яшь кенә бер музыкант егет килде... Йосыф бик ипле, мәһабәт егет, шәп музыкант, өйләнмәгән, ләкин миннән күпкә яшь. Гастрольләрдә гел бергә. Бик күнегеп киттек бер-беребезгә. Ул егет өемә дә килеп йөри башлады. Җыракаем да, балалар да аны якын итәләр... Гомәр бер-ике тапкыр мин югында да, мин барында да яңа өйгә килеп буза куптарып киткәләде. Җыракай әйтә: «Кызым, син бу бәйләнчектән котыла алмассың, берәр чарасын тап!» — ди.

Мин бу турыда Йосыфка сөйләдем. «Әбине дә, балаларны да куркытып бетергән», — дим. Йосыф аны-моны әйтмәде.

Беркөнне чәй эчеп утырабыз, исерек Гомәр килеп керде, исәбе сугышырга, кырырга... Мин Йосыфка шылтыраттым. Күп тә үтмәде, өйгә Йосыф белән бер кеше килеп керде. Йосыфка иярә килгән кешегә ка-

расаң, шундук егылып үләсең, валлаһи. Бу ике-өч тапкыр төрмәләрдә утырып чыккан, кыйналып, бер күзе чәршәмбегә, икенче күзе шимбәгә карый торган караңгы бер бәндә иде ул. Шуннан Йосыф Гомәр каршысына килеп басты, әлеге Газраил сымак ертык чырайлы шәүлә дә Гомәргә якын ук килде. Йосыф сабыр гына, ләкин бик үткәзерлек итеп Гомәргә әйтте: «Әгәр дә, — ди, — бу йортта аягыңның эзе генә күренсә дә яки җиле генә иссә дә, бер көндә юк итәбез, бөтен нәселеңне корытабыз!»

Әле генә ду килгән Гомәр бер сүз әйтмичә чыгып китте. Шуннан соң ник бер тапкыр килсен. Котылдым, Аллага шөкер!.. Котылдым... Гомәр эчеп юкка чыккан, дип ишеттем. Шуннан соң иргә бармадым. Булганнары да бәк җиткән иде... Акчаны артык бирмиләр, ике баламны, әбиемне туйдырасы-киендерәсе бар... Детдомнан соң күп балалы гаилә мине үзенә сыендырган иде бит әле, әбием төрмәдә утырган чакта... Мөхәммәтвагыйз Ильясов белән хатыны Саҗидә апаларда тордым бит, шуларның бер баласын, Нәзифә исемле кызны үз йортыма алдырдым, Актаныштан китерттем. Бишәү булдык. Дүрт җан минем сыртта. Туган бит инде ул миңа, мине ач үлемнән, салкыннан коткарып калган кешеләрнең газиз баласы бит ул Нәзифә. Минем сеңлем кебек. Шул Нәзифә минем балаларымны үстерешә. Рәхмәт яусын. Куркыныч юк инде хәзер...

Музыкант Йосыф минем арттан бик нык йөри бит. Миндә ир кайгысы юк, гаиләм зур, аларны карыйсым бар... Егет йөри, башкаларга карамый да. Югыйсә кияүгә чыкмаган кызлар, баласыз яшь хатыннар бетәсеме? Йосыф сөлек кебек егет, теләсә кайсы гүзәлне үзенә карата ала. Юк, бәйләп куйганнармыни. Акыллы, тәртипле егет, бик зур кеше баласы... Шуның белән егерме бер ел буе дус булып йөрдек. Аннан соң ул башкага өйләнде. Бер дигән итеп тормыш көтеп яталар. Аның белән танышканда, миңа утыз ике яшь иде. Аңа егерме дүрт кенә. Өйләнгәнчегә чаклы Йосыф машинасы белән мине гел Кырымга алып бара, алып кайта иде. Бик итагатьле булды ул миңа карата. Балаларны карап торучыларым бар, бик иркен яшәдем мин шул егерме бер ел буена... Мәҗлесләрдә Йосыфым миңа аракы түгел, пиво да эчертмәде, үзе дә эчми. Ул мине шулай саклады, тавышымны, сәламәтлегемне саклады.

Табын янында тынлык урнашты. Әлфия апа яхшы хатирәләр тәэсирендә иде, мин аның муенындагы җөйгә багам. Кайчандыр, җиде ел әүвәл: «Өч ай гомере калган», — дип куркытканнар иде. Аллага шөкер, әллә табиблар ялгышты, әллә табиблар аны алып калды, ни генә булса да, Әлфия апа әле һаман җырлый, әле һаман «ятимнәрен» туйдыра.

# Шөһрәткә таба

Данны иң өстендә тотып торыр өчен ныклы тез буыны кирәк.

*Әйтем*

— Эстрадада минем үз группам... Татар халык җырларын күп җырлыйм, уңыш казанам. Бу 1966 ел булса кирәк. Мәҗлестә мәдәният министры Рәхмәтуллин да утыра иде. Бер җырчыга пародия җырлап күрсәттем. Ул чакта ансамбльнең сәнгать эшләре җитәкчесе Рәйсә Волкова иде. Ул да шунда. Урыс җырчысына, башка бер халык җырчысына подражание башкардым... Мәҗлес кул чаба, тагын кабатлаталар... Рәхәтләнеп көлеп арыгач, министр әйтә: «Рәйсә ханым, әйдәгез, Әлфияне Мәскәүгә төрле халыкларның җырларын өйрәнергә җибәрәбез», — ди.

Юлын-торуын, ашавын-эчүен, укытучыларга түләүләрен сөйләштеләр дә мине бер айга Мәскәүгә озаттылар. Бер ай эчендә унөч телдә, унөч халык җырын менә дигән итеп өйрәнеп кайттым... Кайттым, программамны күрсәттем, «на ура» узды яңа эшем. Опера театрында беренче концерт куйдым. «Дөнья халыкларының җырларын Әлфия Авзалова башкара» дип, шәп игъланнар ябыштырып чыктылар Казан буйлатып. Үзбәкчә, кытайча, гарәпчә, урысча, башкортча, индонезиячә, татарча, казакъча, әрмәнчә, әзәрбайҗанча, еврейчә, һиндчә...

— Шул телләрдә көйләрне өйрәтүче остазың кем иде?

— Ирма Яунзем! Шул телләрнең язмалары буенча сүзләрне төгәл әйтергә, милизмнарны төгәл җырларга таяк белән кыйнап өйрәткәндәй өйрәтте, бик кырыс укытучы иде, мин аңа чиксез рәхмәтлемен.

— Операдагы концерт ничек узды?

— Һай, Батуллакаем, андый уңыш бик сирәк була. Һәр җырны кабатлаттылар... Беренче концерт... Зал, бельэтаж, балконнар, яруслар шыгрым тулы, патшалар урынында Табеевлар, Батыевлар, Вәлиевләр, Мусиннар, Рәхмәтуллиннар, тагын әллә кемнәр утыра. Шунда мин бер кытай җырын да башкарган идем... Мао Цзе-дун турында. Кытай телендәге җыр текстында урысча өч хәрефле сүзләр күбрәк иде. Кытайча җырлый башладым. (Иелә-иелә кычкырып көлә. Көлеп туктагач, кытайча җырлап җибәрде.)

...Әлфия апа тагын гыжгылдап, сызгырып көләргә тотынды. Үзе һаман сөйли:

— Бөтенесе егылды...

— Соңыннан кем ни әйтте? Кытай җыры турында...

— Һай, малакаем, аның сүзе күп булды. «Әлфия Авзалова хулиганить итә, сәхнәдән торып, халыкара олы коммунист җитәкчеләрне мыскыллый», — диеп яздылар, обкомга йөрделәр... Чакырдылар... Мин әйтәм, мин дөресен җырлыйм, кытайлар үзләре Мао Цзе-дунны мактап ничек җырласалар, мин нәкъ шулай җырлыйм, дидем. Кулымда менә ноталар, ноталар астында кытайча сүзләр, дидем. Кытайча әйтелеш транскрипциясе, дидем. Моны миңа атаклы педагог, кытай теле белгече Ирма Яунзем үзе өйрәтте, дидем. Пусть она отвечает, димен.

Әлфия апа тагын кытайча җырны кабатлады. Барчабыз егылып көләбез.

— Әлфия апа, соңыннан ни булды? Туктаттылармы кытай җырын?

— Программамнан үзем алдым, җуләр.

— Ни өчен? Тегеләр рөхсәт итмәдеме?

— Алар да рөхсәт итми... Үзем дә кабат җырламаган булыр идем. Концертны алып барып булмый, кытайча җырлаганнан соң. Кабатлаталар да кабатлаталар...

Әлфия апа тагын көлә.

— Ябрәйчә җырлыйм бит, малакаем, белдерүләрдә нинди телләрдә, кайсы халык җырын башкарачагым урысча язылган бит. Һәр шәһәрдә ябрәйләр килә, нимес ябрәйләре килә, апаем, кайсы шәһәргә барсам, анда ябрәй кереп тула залга, шул бер ябрәй җырын тыңлар өчен ике-өч рәтне ябрәйләр сатып ала, иң яхшы урыннарны гына. Сәхнә артына рәхмәт әйтергә керәләр концерттан соң, бүләкләр бирәләр. Тегеләрдән сорыйм: «Дөрес әйтәмме сүзләрен?» — дим. Баш бармакларын күрсәтеп: «Во!» — диләр. «Без акцента поете», — диләр. Кочаклап елыйлар. Сәхнә артына килеп керүгә, миңа ябрәйчә эндәшәләр. Аркамнан сөяләр, күзләрендә яшь. Баксаң, ул моңлы җыр түгел. Туй турында ул, күңелле җыр, күңелле җырны ишетеп, үкереп елап утыралар, малакаем.

Ул тагын тирән сулыш алып, күкрәк тавышы белән, олы бер гайрәт белән еврейларның туй җырын башлады.

Михи тоннам гейм (туй килә), а-а, михи тоннам гейм,
Михи тооннам гейм, а михи тоннам гейм, киндер.
Ой ломир зих фрайн шатнур шат,
Зидрәйт зих вей адрайдел ойш пил
Авиветтәт тарын хоффтен зат.

Менә шулай итеп тырышасың аны, булсын, булдырыйм, дигәннән килә. Юкса мин ул чит телле текстларны өйрәнеп тә маташмаган булыр идем. Башыңа төшкәч тырышасың... Филармония директоры итеп Марат Таҗетдиновны куйдылар. Мәскәүдә минем бригаданың дүрт концертын оештырдылар. Асаф Вәлиевне, Венера Ганиеваны, Гөлшат Зәйнашеваны алып бардым. Барысы да миңа рәхмәт укыйлар. Басып торырга урын юк. Әлфия Авзалова концерты, тегеләрне алмасам да була иде. Мин әйтәм, халыкка күренсеннәр, Мәскәү аларны танысын, дим. Хәзер барсам да, Мәскәү мине аягүрә каршы алачак.

## Бер чемодан оекбаш

— Ансамбльгә мин зур чумадан сөйрәп килдем.

— Ул чемоданны сиңа кем бирде?

— Актаныштан киткәндә, күрше әби бирде. Габдулла корткасы. Шул зу-ур чумаданда бер кием оекбаш иде. Разия Тимерханова, зур чумаданны күреп: «Кызым, синең бу сандыгыңда нәрсә бар соң?» — ди. «Оекбаш!» — дидем. «Ачып күрсәт әле», — ди Разия апа. Ачтым да күрсәттем, бер оекбаш ята чумадан төбендә. Кешеләр рәхәтләнеп көлә.

## Беренче ялгышу

Оятымнан җир тишегенә кереп китәрдәй булдым.
Җирнең тишеген генә табалмадым.

*Ә.Авзалова*

Кич утырабыз. Әлфия апа, Рузия ханым, балалар. Мәтрүшкәле чәй эчәбез.

— Әлфия апа, — диде Нурбәк. — Сәхнәгә чыккач, синең ялгышканың булдымы?

Әлфия ханым, тустаганын кире куеп, кыты-кыты көлә башлады. Көлү сызгыруга әверелде, көлеп туктагач:

— Булды! Булды, энем! Илһам һаман шул ялгышым турында көлеп сөйли. Әле сәхнәгә яңа аяк баскан чакларым. Декададан уңышлар белән кайттым 1957 елда. «Кәккүк»не җырлап. Правительственный концертка беренче мәртәбә керттеләр. Ансамбль күлмәген кидем. Миңа Рокыя Ибраһимова уйный. Чыктым да җырлыйм:

Безнең илнең егетләре
Сугышларда йөрделәр лә...

Сүзләрен оныттым. Рокыя апа әйтеп тә җибәрми бит шунда. Музыка үкчәгә баса. Тоттым да үз сүзләрем белән җырны бетердем:

Шул егетләр хөрмәтенә
Кояш килеп чыга да,
Җир тишегенә кереп югала.

Бөтен дөнья көлә. Чыгып киттем сәхнәдән. Оят, валлаһи, оят. Кызарындым-бүртендем. Шуннан соң мине өч ел сәхнәгә чыгармадылар. Шәһәрдә җырлатмадылар. «Әнә йөрсен авылларда, анда ялгышса да ярый», — дигәннәр.

— Кул чаптылармы соң?

— Чапмас сиңа! Үтергәнче чаптылар... Бар халык алкышлый бит, чыгып баш и, баш и, диләр. Төртеп чыгардылар, мин чыгып баш игән булдым. Илһам һаман шуны сөйли... Шунда җир ярылса, җир тишегенә кереп китә идем. Тишеген генә табалмадым.

— Кабат ялгышканың булдымы сәхнәдә? — диде Нурбәк.

— Юк! Текстларымны карап чыгам... Яшь чакта мин үземә артык нык ышанганмын, әнә шул артыклык мине ялгыштырган да... Бервакытта да сәхнәгә, менә мин сезне аяктан егам әле, дип чыкмаска кирәклеген мин шунда аңладым. Шуннан соң мин сәхнәгә чыгар алдыннан һәр сүзне барлыйм, кабатлыйм... Нурбәк балам, син артист буласы кеше, бу сиңа да гыйбрәт: беркайчан да, кичә уңыш казандым, дип, сәхнәгә әзерлексез чыкма! Үзеңә артык нык ышану куркудан да яманрак!

Чәй эчә-эчә тема үзгәрде. Әлфия апа үзенең ике баласын ничек киендергәне турында сөйли:

— Балаларга күлмәкне алам биш ел кияргә дип. Зөлфия үсте, җылыйдыр иде, мин генә бәхетсез, дип. Нигә озын күлмәк киясең, карчыклар шикелле, дип көләләр, ди. Әни шулай озын тектерә. Үсә-үсә кечерәя ул, дип әйт, димен... Мәскәүгә киттек концерт белән. Андый культурный шәһәрләргә кече кызымны — Зөлфиямне алып йөрим. Анасыннан бизмәсен, дип.

— Олы кызың кайда?

— Ул мәктәптә укый. Олы кыз минем белән йөрергә яратмады... Ул да атасы кебек, «сәнгать» дип исе китмәде. Зөлфия сәхнәгә тартыла иде. Ул театр училищесын тәмамлады, эстрадада эшләде. Уңышлы гына башлаган иде, үзе чибәр, үзе җырлый, үзе сөйли иде. Кияүгә чыккач, сәхнәне ташлады. Берзаманны, ул вакытта Илһам да, мин дә танылып өлгермәгән әле, Уфага киттек Илһам белән. Билетлар сатылмаган, Петров бакчасында беренче концертны буш залга куйдык. Утызлап кеше бар иде шунда. Икенче көнне кеше күбрәк килде, аннан соң билет өчен сугыш башланды. Халык күбәйгәч кенә безнең гастроль бетте. Икенче юлы Уфага килгәндә, бер ай алдан билетлар сатылып беткән иде. Илһам белән өч ел бер группада йөрдек тә аерылыштык. Икебезгә ике аерым бригада кордык. Ярыш китте ике бригада арасында, көнгә икешәр, кайчакларда хәтта өчәр концерт куябыз. Шулай ике-өч концерт куйгач, иртәрәк кайтабыз, планны үтәп, балаларым янына ашыгам... Шуңа күрә көнгә өч план үтибез.

— Репертуарны ничек әзерли идең?

— Рокыя Ибраһимова миңа әллә нинди борынгы җырлар өйрәтә иде, башка артистларда ул җыр юк, миндә генә. Композиторлар үзләре килә минем янга: «Әлфия, менә яңа җыр чыгардым, шуны башкармассыңмы?» — диләр.

Илһам репертуарын үзе әзерли, аның баш бар, кирәксә, ул җыр да чыгара ала, миндә анысы булмады... Һәвәскәр җырчыларны еш тыңлыйм, аларның репертуарында матур җырлар була. Алар халык арасыннан алып чыга ул җырларны, шулардан өйрәнә идем... Уфада егерме сигез концерт куйдым. «Юбилейный» дигән «патша сараенда» туп-тулы заллар, малакаем.

— Син үз яныңа кайсы җырчыларны, нинди тәртиптә ала идең? Син хатын-кыз, синең партнерың ир тавышлы булырга тиеш бит инде.

— Ие, ие, Хәнәвине ала идем. Аның белән юл йөрүе рәхәт, талымсыз, матур җырлый, үзе минем якташ, Актанышныкы... Мәскәүдән Шәймәрданов атлы мишәр егете, консерватория бетергән иде ул, аның белән йөрдем. Биючеләрем бар иде, Римма исемле марҗа кызы, бик матур бии иде. Балеттан килде. Сөйләүчем Фәйзи абый Йосыпов... Нәҗия Минкина белән утыз биш ел эшләдем, бердәнбер хатын-кыз — сүз остасы. Аның ире Латыйпов бии иде минем бригадада. Фәйзи абый иң танылган сөйләүче иде, кыяфәт, та-

выш! Аны Башкортстанда бик яраталар иде, шуңа күрә Фәйзи абый Башкортстанга бик еш оештыра иде концертларымны.

— Сарман ягында да күп булдың бит әле...

— Булмаган җир калмады, икешәр, бишәр тапкыр барып чыккан чаклар да булгалады...

— Сарман ягындагы Күтәмәле дигән авылда Әлфия Авзалова әрмәннәрне клубтан куып чыгарган, дип сөйлиләр, шул сүз хакмы? Имеш, абзар салырга килгән әрмәннәр, клубка салган баштан килеп, халыкка концерт карарга комачаулап йөриләр икән.

Сорауга җавап та бирмәстән, Әлфия апа әрмәнчә кычкыра да башлады:

— Ере теткелор дирых, тикын зор! Һей, ере теткелор дирых, тикын зор! «Барыгыз, чыгып олагыгыз моннан, йолкышлар!» дигән сүз. Мин моны каты тавыш белән әрмәнчә әйттем, тегеләр башларын томалап чыгып йөгерделәр.

— Балаларың үсте, аларның балалары үсте, оныкларың бар инде... Барысы да урнашкан, тормышлары көйләнгән. Синең нинди кайгың, нинди хыялың, теләгең бар?

— Кайгы юк, Аллага шөкер... Минә җитмеш яшеңә йорт салып бирәбез, диделәр... Актаныштан Фәттахов салышты... Нигезен ул салды, Рәшит Сәетович корып бирәм, кулыңа ачкыч тоттырам, Әлфия апа, диде... Ачкыч бирәм дигәндә үлде дә китте Рәшитем, кызганыч.

# Рәшиткәем минем

Эзәй буйларына ла без төшәрбез,
Колачларны җәеп лә ай-һай ла җөзәрбез;
Кычкырыр ла күке лә, сайрар былбыл,
Шул чагында ничекләр ай-һай ла түзәрбез.

*Рәшит Хәмәдиевнең*
*яраткан керәшен җыры*

Әлфия Авзалова белән Чаллы каласының элеккеге администрация башлыгы мәрхүм Рәшит Хәмәдиев турында сөйләшү.

— Әлфия апа, Рәшит әфәнде артистларга игътибарлы була килде. Сиңа аеруча дикъкатьле иде ул. Якташ дияр идең, сез якташлар түгел, Рәшит — Аксубайдан, син — Актаныштан. Сез кайчан һәм ничек таныштыгыз?

— Рәшит Сәет улы Хәмәдиев белән мин ул ветеринария институтында мал духтыры булырга укыган чагында таныштым. Без, бер төркем артистлар, шул институтта концерт куйдык. Соңыннан институтта укучы яшьләрнең тамашасын карадык. Шул программада озын буйлы, итләч иренле, зур авызлы егет ут яндырып татар егете биюен башкарды. Шул ук егет өздереп татар халык җырларын җырлады. Ул мәһабәт егет Аксубай ягында туып үскән Рәшит Хәмәдиев булып чыкты. Шул көннән соң без якын дуслар булып киттек. Гомерем буе мин аның игътибарын тоеп яшәдем. Була бит яхшы кешеләр...

Рәшитнең атасы Сәет абзый улының артист-җырчы булырга теләгәнен белеп алгач, мәсьәләне бик каты куя:

— Ике аягыңның берсен дә атлыйсы булма артистлыкка! Әнә чын эшкә тотын, агрономлыкка, зоотехниклыкка укы! — дигән.

Рәшит, атасы сүзеннән чыкмастан, ветеринария институтына барып кергән. Ул шәп ветеринар иде, шәп бакчачы иде. Ләкин барыбер ул сәнгатькә омтылуын ташлый алмады, бахыр. Гел җырлады, гел биеде, гел сәнгать кешеләре янында булды. Үзе эшләгән якларда гел һәвәскәр артистларга игътибарлы булды. Ансамбльләр оештырды, шул яктан чыккан сәнгать кешеләренә матди ярдәм итеп, күңелләрен үстереп торды.

Бик тә шәфкатьле кеше иде, мәрхүм. Авыр туфрагы җиңел булсын!

— Институтта башланган танышлык алга таба ничек дәвам итте?

— Рәшит институтны бетергәч, юллама белән Зәйгә китте бит.

Мал духтыры булып бик нәтиҗәле эшләгәч тә аны иң артта калган колхозга җитәкче итеп куйдылар. Колхозны алга чыгаргач, аны Зәй каласының башкарма комитетына күчерделәр. Шул вазифаларны башкарган чагында Рәшитем белән тагын очраштык. «Әлфия апа, — диде бу миңа килеп төшкәч тә. — Әлфия апа, зур колхозларда артистлар еш була, безнең төбәктә кечкенә керәшен авыллары бар, алар, бичаралар, концерт карый алмый, театрлар анда кереп тормыйлар. Йөреп чык әле син шул авылларда, акчасын олы авыллар кебек итеп түләрбез!» — ди.

Киттек чыгып егерме өйлек, утыз өйлек керәшен авылларына. Малакаем, аларның шатланганын күрсәң, аларның кунакчыллыгын күрсәң. Авыл саен куна-төнә 28 концерт куйдык. Ел саен шулай чакыртып, шул авылларда яңа программа белән йөретте ул Рәшиткәем безне. Кайсы җитәкченең кечкенә авылларның хаҗәте турында уйлап караганы бар?

Шуннан Минзәләгә күчерделәр бахыркаемны. Минзәләдә дә ул яхшы җитәкче булды. Минзәләгә урнашуга ук, Рәшитем минем группаны чакыртты. Минзәләгә килеп төштек. Олылап каршы алдылар. Гастрольләрдә йөрибез. Китәр алдыннан Рәшитем миңа пышылдый: «Әлфия апа, сәхнәгә киеп чыккан күлмәгең бик әллә кем түгел. Синең өс-башыңны карарга кирәк. Әнә, — дие, — безнең складта яхшы материаллар бар, сайла, теләгәнчә концерт күлмәкләре тектер, болай йөрмә, син олы артистка бит», — дие. Акчаның кысан чагы иде. Шулай итеп, ул мине киендерде, Аллага шөкер. Ул мине, гаиләмне ташламады. Гел әнә шулай ярдәм итеп торды. Рәшит эшләгән төбәкләрнең сукмакларына эзләр суынмый иде.

## Иҗат берләшмәсе

Сәхнә уртасында үлсәм иде.

*Ә.Авзалова*

— Минем дус хатыннарым күп булмады. Казанда алар икәү. Берсе Гөлшат Зәйнашева, икенчесе Зөләйха Садыйкова.

— Гөлшат апа белән сез күп эшләдегез бит... Зиннур Гыйбадуллин белән дә...

— Әйе, мин алар аркасында үстем. Мин гел аларда куна кала идем. Төне буе җыр чыгарабыз. Гөлшат сүзләрен яза, Зиннур шул сүзләргә көй әзерли, мин шундук өйрәнә башлыйм. Мин танылган замандагы җырларның барысы да аларныкы — Гөлшат Зәйнашева белән Зиннур Гыйбадуллинныкы.

— Сез бер-берегезне үстердегез. Шәп өчлек иде ул.

— Җыр булуга, мин пластинкага язылырга чабам. «Күл буена килсәң иде»... «Идел буе» — бик һәйбәт җыр. Гөлшат сүзләренә Ключарев көен язды. Бу җыр миңа багышланган иде.

Ватанымның гади бер кызы мин,
Туып үстем Идел буенда;
Чәчәк җыйдым хәтфә болыннарда,
Җыр өйрәндем сабан туенда.

Дулкын-дулкын арыш тибрәнгәндә,
Иңләп үттем иген кырларын;
Эш сөюче якташларым җырлап
Нечкәрттеләр күңлем кылларын.

Иң беренче җырланган уртак җырыбыз шул, оркестр белән башкарылды.

— Ключарев ул урыс кешесе иде бугай.

— Белмим, урыс булдымы икән ул, әмма татарча яхшы белә иде. Моңнары татарныкы иде... «Кәккүк»-не Александр Сергеевич ансамбль өчен җайга салды, «Кәккүк» җырын бер кеше дә белми иде. Гөлсем Сөләйманова җырлый иде аны. Актаныштагы баганага сөялеп, орчык буе кыз бала чакта Гөлсем апаның «Кәккүк» һәм башка җырларын тыңлый идем. Мин моңны әнә шул багана башындагы тәлинкәдән «эчә» идем. Радио дикторы Фәйрүзә Исхакова бармы, шуның атасы Мәсгут абый белән фотограф-баянчы Мәрзия Юнысова минем белән бик нык шөгыльләнде. Шуларның хезмәте аркасында мин инде сулыш ала беләм, тавыш белән эшли белә идем. Шәп остазлар булган алар, авыр туфраклары җиңел булсын! Аларга чиксез рәхмәтлемен. Гөлшат, Зиннур белән мин күп эшләдем.

Яшь гомер бер узгач,
Кайтмый ул яңадан;
Тик минем яшьлегем
Никтер кайтыр кебек.

Яшьлектә сөйгән яр,
Сагындым килеп ал;
Сине көтәм һаман,
Дип әйтер кебек.

Бу җыр да минем өчен язылды.

«Күңелле ял итегез»не дә минем өчен яздылар.

Очып әйләнәсе килә,
Яшьлекне канат итеп,
Таңны каршылыйсы килә,
Йолдызга барып җитеп.

Менә шундый җырлар өйрәттеләр алар миңа.

— Сине репертуар белән тәэмин итүдә Гөлшат апа белән Зиннур бик зур эш эшләделәр. Бу иҗади берләшмә, иҗади өчлек булган инде.

— Әлбәттә, җитди берләшмә иде!

— Шул өчлек тарихыннан бер вакыйга!

— Яшь чакта кызыклар булды инде ул... Гөлшатка җыелабыз инде. Начар гына йортта торалар, бичаралар. Бер кызы бар Гөлшатның беренче иреннән. Шул бер бүлмәгә мин дә сыя идем. Кайчакта Ключарев та куна кала иде. Гөлшат белән Зиннур аерылдылар. Безнең өчлек таркалды. Гөлшаттан аерылгач, Зиннур иҗатта тукталыбрак калды. Башкага өйләнде, ләкин иҗат артта калды.

— Әйе, соңгы елларда кыерсытылган кыяфәттә иде Зиннур.

— Гөлшат белән Зиннурның судына мин дә шаһит булып бардым, әнә мәзәк итеп сөйләп йөриләр хәзер.

Судта Зиннур:

«Без ир белән хатын түгел идек, мин анда квартирант кына булып тордым», — ди.

Судья сорый: «Әлфия ханым, алар ир белән хатын идеме, әллә квартирант белән хуҗабикә генәме? Ир белән хатын булып, алар бергә тордымы?» — ди.

«Кәк тормасын, — мин әйтәм, — кәк тормасын, алар бергә тордылар ир белән хатын булып, — димен. — Мин аларда гел йоклап кала идем».

«Сез ничек исбат итәсез аларның ир белән хатын булганын?» — ди судья.

«Иптәш судья! Әллә ничә мәртәбә күрдем. Алар гел бергә йоклыйлар иде, — димен. — Бер караватка... яталар иде», — дим.

Судтагылар көлә, шуннан аердылар. Ләкин Гөлшат, кыз баласын алып, шул үзенә бирелгән бүлмәне Зиннурга калдырып чыгып китте. Гөлшатка обком артындагы йорттан ике бүлмәле квартир бирделәр. Шунда рәхәтләнеп торды ул кызы белән...

Һәй күрде инде безнең башлар... Таладылар, кыстылар, кыерсыттылар. Барыбер бирешмәдек... Менә, Алланың рәхмәте киң, безнең бәхеткә Минтимер Шәймиев килде.

Рузия. Күп кешегә... бик күп кешегә, сәнгать кешеләренә Минтимер Шәрипович юл ачты... Морально, материально ярдәм итте... Квартирлы итте күп кешене. Рәхмәт!

Әлфия. Академия театры безнең яннан ундүрт квартира алды, барысы да Минтимер якташ эше бит.

— Син үзеңә нинди үлем телисең?

— Сәхнә уртасында үлсәм иде, димен.

— Җитмеш биш яшеңне Академия театрында үткәрергә кирәк.

— Ие, филармония залына мин риза түгел. Концертлар залында җылылык юк, нур юк. Үзебезнең Шәймиевебез булганда, Камал театрында узар, Алла боерса. Шамил Зиннурович каршы килмәс. Шамил кебек олы җанлы кешеләр сирәк. Йомыш белән керәсең икән: «Була ул, Әлфия апа», — ди һәм йомышыңны җиренә җиткезеп үти. Сәнгать өчен җанын бирергә әзер кеше ул Шамил. Ул яшәсен! Рәшит Сәетович Хәмәдиев кебекләр яшәсен!

Актаныштa Зәйнәп апа бар иде, аның ире райфода эшләде бухгалтер булып. Хатыны: «Әйдә, кызым, әйдә, керләрне чайка, бәкедә чайка», — дип, иске бияләй бирде. Идәннәрен җуып чыгарам, ашаганнан калган ипи сыныклары, бәрәңге калдыкларын казларга чыгарып салырга кушалар. Казларга салудан битәр үзем ашыйм, кесәмә тутырам каткан ипи кисәкләрен. Казлар, как-ка-ка, ашама безнең өлешне, дигән кебек какылдыйлар, тегеләргә бер кисәк ыргытам, икене үземә алам, уртаклашабыз. Казкайларның өлешенә керергә туры килде, бичаракайлар. Бер-ике көн алар да ач калды. Нишлим соң, ачтан үлиммени? Сугыш вакыты... Җыракай белән утын урлап кайтып барабыз, боз өстенә килеп кергән идек, ялт итеп күк капусы ачылды. Җыракаем утыннарын төшереп җибәрде дә теләк теләргә тотынды, мин дә телим: «И Ходаем, тәүфыйклар, бәхет бир. Ходаем, исәнлек бир», — дип, икебез дә кабатлыйбыз... Мич башыннан төшеп киләм, тагын өй яп-якты булып балкый башлады, тагын күк капусы ачылды. Ике тапкыр күк кабагы ачылганын күрдем. Тагын Җыракай белән теләкләр телибез...

Җыракай, төрмәгә кергәнче, төнге каравылда тора, көндез ындыр табагында эшли, мине үзе белән алып бара. Олы капчыктан ыштан тегеп бирде, шул капчыклы ыштанны кидем, арыш урларга. Киттек ындыр табагына, Җыракай шул ыштанга арыш тутыра, билдән бәйли, олы ыштанның ике балагын да бәйли, бот юаная, атлап булмай. Олы хатын-кызларны каравылчылар тикшерә. Бала-чаганы тикшерми. Юан ботларым белән әкрен генә кайтып бара идем, чокырга чумдым. Көчкә чыктым ул чокырдан. Шунда чокыр төбенә ятып ял иттем. Арышны алып кайтып куырып ашадык, беразын бүрттереп ашадык. Күбесен киптереп, кул тегермәнен базга алып төшеп, ярма ярабыз. Исе урамга чыкмасын, тавышы ишетелмәсен... Сиңа гына сөйлим, мин бераз хәер сорашып та йөрдем бит, ачтан үлмәс өчен...

Үз гомеремдә бер урлаштым, Җыракайның сандыгы бар бит, шул сандыкта сәхәр өчен куелган шакмаклы шикәр бар, сандык йозак белән бикле, капкачы бераз ачыла, шул ярыктан кулымны тыгам, калайлары тырный, шакмаклы шикәр күренә. Шикәрне ике бармак белән каптырдым, ярыктан чыгарып булмай, сандык калае кулны кисә. Тәки чыгардым тегене, кулым кара канга баткан; абзар түбәсенә саламга мендем, Җыракай өйдә юк, салам астына күмелеп кытыр-кытыр шикәр кимерәм. Бер атнага җиткездем, шун-

нан да тәмле шикәрне башка ашаганым булмады... Муллык хәзер, шөкер... Мин өстемә яхшы кием кия алмадым, акчамны гаиләгә тоттым, башка артистлардан калганны киеп йөрдем. Разия апа Тимерханова минем өс-башыма карап-карап тора да кычкырып көлә, аннан күңеле тула, аннан соң үзенең берәр пәлтәсен, күлмәген бирә иде. Урыны җәннәттә булсын! Мине үз өенә алып кайта торган иде, тамагы туйсын диптер инде, аның ике малае бар, барып керсәм, малакаем, идәндә алмалар аунап, тәгәрәшеп ята. Разия апа белән малайлары юкта һап бер алманы эләктереп алдым. Шуны ашадым.

## Гөлҗамал

Авыр җан сөйгәннәрнең булмавы.

*Халык җыры*

— Яшь вакытым, Усман абый Әлмиев мине Ташкентка алып китте. Ул ир тавышы, мин хатын-кыз тавышы. Усман абый һәр кичне «Гөлҗамал»ны җырлый.

Әлфия ханым Әлмиев булып «Гөлҗамал»ны җырлый башлады. Нәкъ Усман абый, ләкин бу башкаруда пародия элементы күбрәк иде. Өй эчебез белән рәхәтләнеп көләбез.

— «Усман абыкаем, — дим, — зинһар, мин җырлыйм әле «Гөлҗамал»ны, син тарта алмыйсың бит», — дим. Әй кызып китте Усман абый: «Соплячка! Син әле мине өйрәтәсеңме ничек җырларга!» — дип, бик каты ачуланды, кайтарып җибәрә язды. Ләкин... бераздан йомшады... «Гөлҗамал»ны миңа бирде. Үзе җырламый, концерт вакытында мин «Гөлҗамал»ны җырлаганны кырыйдан, ян пәрдәдән гел-гел карап-тыңлап тора иде.

Шәмдәлләрдә генәй утлар яна, Гөлҗамал,
Җиткән кызлар киндер җеп эрлиләр.
Энҗе дә мәрҗән кызларның кулбавы,
Авыр җан сөйгәннәрнең булмавы...

Борынгы матур җыр, тирән мәгънәле җыр. Кызлар кич утыра. Киндер җеп эрлиләр, шушы җеп эрли торган кызларның беләгендә, кул чугында энҗе дә мәрҗән. Юкса ялган әдәбиятта татар халкы мәдәниятсез, мескен халык буларак тәкъдир ителә килде. Авыр эш, кара эш башкара торган татар кызларының беләгендә энҗе дә мәрҗән. Бай кызларымы соң бу? Бай кызлары булса, нигә алар җеп эрләп утыра интегеп? Фәкыйрә кызлармы соң болар? Алайса, нигә аларның кулыннан эш вакытында да энҗе-мәрҗән төшми? Бар ягы җитеш шушы кызлар ни өчен моңлы озын көй җырлый? Өлгергән кызларның кияүгә чыгар вакыты җиткән, әлегә сөйгәннәре дә, ярәшелгәннәре дә юк. Иң олы хәсрәт — сөйгән ярыңның булмавы. Менә шушы мәңгелек мәүзугъ — мәхәббәт — җырның моңы, хәсрәте булып уртага яткан.

Әлфиянең үзенең дә әле мәхәббәт хисләре татымаган вакыты. Мәхәббәт хисе татымаган хатын-кыздан да бәхетсезрәк башка берәү булырмы икән? Борынгы кызларның хәсрәте белән яшь җырчы Әлфиянең хәсрәте бергә кушылып, «Гөлҗамал» җыры тагын да куәтләнә, читлектә ятучы хисләр тышка ургыла. Тыелган мәхәббәт упкынга ыргый. Илһам кебек «Кара урман»ны башка берәү дә әлегә кадәр җиренә җиткереп башкара алмаганы кебек, Әлфия башкаруында «Гөлҗамал»ны да берәр камил башкаручы табылырмы икән?

## Бер рәхмәт йөз бәладән коткарыр

— Башкалар гастроль вакытында суточный алгач, ресторанга кереп китә, мин кермим, кызларыма саклыйм акчамны. Тиенләп, бөртекләп җыйдым мин балаларыма, әбиемә, ятимә сеңлемә акчаны. Авызымнан өзеп җыйдым. Акча юк чак, барлы-юклы акчама берәр ризык алырга дип, базарга кердем. Буе-буе белән сыер теле сузылып-сузылып ята, акчамны актарам, ун сум җитми. Бер санадым да читкә киттем, тагын әйләнеп килдем. Шунда бер ир кеше эндәшә: «Әлфия ханым, акчагыз җитми бугай!» — ди. Борылып карасам, гөрнәдирдәй бер ир. «Ие шул, акчамны икенче пәлтәм кесәсендә калдырганмын, өйгә кайтып йөрергә ерак», — дигән булам.

Бу кеше Вил Усмановның абыйсы булып чыкты. Ул миңа шунда ит, тагын әллә нәрсәләр алып, машинасына утыртып өемә китереп куйды. Гел онытмыйм шуның яхшылыгын, эше уңышлы барсын, дип, гел аның исемен атап дога укыйм.

## Йосыф

Мәхәббәт ул үзе иске нәрсә...

— Бригадамны баеттым мин, музыкантлар алты кеше, саксофон, ике баян, гитара — барысы да бар, шөкер. Кәрим дә шунда. Тынычланып эшләп киттем. Шәһәрләр буйлап гастрольләргә алып чыгып киттем бригадамны... Яшь музыкантка мин ошыйм... Бер ел әйтә килдем, зинһар, минем башымны әйләндермә, теге җүнсездән коткардың, рәхмәт, ләкин мин ике балалы хатын, миңа өмет тотма, димен. Гаиләмә әле бу кирәк, әле теге кирәк. Актанышка кайттым, Мөхәммәтвагыйз абый белән Саҗидә апаның кызы Нәзифәне Казанга алып килдем, балаларымны карашырга. Ун класс бетергән ие, эшкә урнаштырмый тордык, кер уа. Закирә апа белән алар миңа ярдәм итте. Нәзифәне кияүгә бирдек. Матур гаилә кордылар. Ике баласы бар. Балалары зур кешеләр булдылар.

Гүзәлем белән Зөлфиямне Җыракайга калдырып, Нәзифә белән Опера театрына киттек. Ике очучы, матур хәрби егетләр, артымнан калмый йөриләр бит. Теге, минем бригадада эшли башлаган Йосыф, минем теге очучылар белән сөйләшкәнемне күреп алган... Мин инде әллә кем түгел, мине чибәр дип әйтеп булмый бит инде, ләкин мин киенә белә идем, иске-москыны үзгәртеп, яңа күлмәк ясый белә идем мин. Миндә егет кайгысы юк, Нәзифә белән кайтып киттек. Квартирага кайтып җиттек. Тимер чүплек савыты бар өй янында. Йосыф килеп чыкты, мине сагалап торган. Курыктык, кара шәүлә килеп чыкты бит чүп савыты артыннан... Теге ике очучы мине озата кайтырмы икән дип, алдан кайтып сагалап торган. Шуннан йөреп киттек Йосыф белән, ияләндек... Дуслык китте безнең. Әти-әниләре ишеткәннәр, өч ел бергә эшләгәч, ике балалы Әлфиягә өйләнә күрмәсен дип, минем бригададан алып, Чаллыга җибәрделәр егетне.

— Сөргенгә?

— Сөрген түгел, Чаллыга концертлар оештыру буенча баш администратор булып китте... Мин эшлим... Безне аера алмадылар, ул минутында очып кайта, мин Чаллыга барсам, бергә булабыз... Ике бүлмәле квартирымнан Галиев урамына, өч бүлмәлегә күчендем. Мәйдан киңәйде, гаиләм ишле бит. Йосыф көнләшә иде, минем кырда берәр ир уралса, нык көнләшә иде, яратты ул мине, мин дә яраттым. Аның белән егерме ел яратыштык. Минем беренче һәм соңгы мәхәббәтем шул булды — Йосыф!

— Гражданский брак дип атала бугай инде ул хәзер.

— Ие... Гастроль вакытында гына без бергә. Казанга кайткач, ул үз өендә тора иде... Ул аракы эчми, миңа аракы эчерми, тәртипле егет. Без аерылгач, бер балалы хатынга өйләнде ул...

Никадәр кунакларда булдык, бригадамны күп җирләрдә сыйладылар. Бервакытта да, егерме ел буе бер тапкыр да чәркә куйдырмады минем алга, үзе дә эчмәде. Өемдә дә аракы тотмадым. Бәйрәмнәрдә балаларымны ашатам-эчертәм дә, Йосыф килеп җитә минем арттан. «Әйдә, әни янына», — ди. Әнисе мине яратып бетерми. Минем барасым килми. Әнисе янында бәйрәм үткәрәбез. Аннан ул мине өемә китереп куя да кайтып китә.

— Акыллы нәсел!

— Акыллы, бик акыллы, тәрбияле нәсел... Мин аңа рәхмәтле... Озак йөрибез бит инде, ул яшь, бәлки, миннән туйгандыр да инде. Ишеткәлимен дә... Башка хатыннар белән дә очраштыргалый бу... Бер тапкыр өйгә кайтып барабыз, сүзләре төртмә моның, сизәм, икенче хатынга ияләнгән бу.

«Мин дә туйдым синнән, — дидем. — Тупасландың, — дим. — Синнән башка да табылыр әле», — дидем. «Ты что, кому ты нужна?» — димәсенме тәрбияле Йосыфым. «Нужна! — дидем. — Кому-то я еще нужна, — димен. — Миңа чит илдән бер полковник кайта! — дидем. — Миңа хат яза бу: «Саумы, Актаныш кызы...» — дип башлана хаты. Мин шундый-шундый хәрби кеше, полковник, өйләнмәгән, дип, фотосын да салган... Нужна шул, Йосыф, әле генә хат алдым, — мин әйтәм. — Миңа предложение ясарга кайта», — дим.

Йосыф мине илтеп куйды да кайтып китте. Без шулай аерылыштык. Самарадан гастрольдән кайтып төшәм, телеграмма: «Каршы ал, полковник Фәррахов», диелгән... Гөлсинәне алып, каршы алырга аэропортка киттек. Самолеттан төшә, малакай, ике метрлы полковник, мәһабәт, чибәр, горур. Ике чемодан, ялга кайта. Элек күрешкәнебез юк бит. Бер-беребезне таныдык. «Актаныш кызы!» — дип елмая.

Киттек безгә такси белән. Килеп җиттек. Әйтергә кирәк иде, минем егетем бар, дип. Мин әйтмәдем. Аннан соң без Йосыф белән араны өздек бит. Балалар белән Җыракай Актанышта кунакта. Ялгызым гына югыйсә. Мин военныйларны яратам, беренче иремә дә офицер дип барган идем. Ул сержант кына булып чыкты. Ә бу полковник бит. Гөлсинә белән бер бүлмәдә өчәү йоклыйбыз. Гөлсинә раскладушкага ятты, мин караватка. Минем янга тагын бер раскладушка куеп полковник ятты. Минем кулны тотып ята. Хәзер нишләргә? Төн шулай кул капшашып кына узды.

«Әйдә, киттек безнең авылга! — ди полковник. — Хәзер билет алырга бергә барабыз», — диде бу. «Әйдә!» — дим. Киенеп подъезддан чыгып барабыз җитәкләшеп. Каршыга «41-51» номерлы машина килә. Йосыф машинасы. Машина туктады. Йосыф төште. Без, Йосыф килеп җиткәнче, такси тотып, пристаньга «очтык». Йосыф калды машинасына сөялеп. Авылга кайтып төштек, шулкадәр күп туганнары. Апалары, сеңелләре, абыйлары, энеләре... Унбиш көн тордым. Ләкин безнең арада берни дә булмады, була да алмый иде... Ул радиацияле җирдә хезмәт иткән... Шул турыда сөйләде миңа. Мин аны бик кызгандым. Шулкадәр мәһабәт ир...

Казанга кайтып төшсәк, Җыракай белән ике балам да кайткан... Полковник белән кайтып кердек. Җыракай мине бүлмәмә алып керде дә җылый башлады: «Балакаем, кеше баласын үтерәсең бит», — ди. «Ни булды, Җыракаем, кемне үтерәм?» — дип аптырыйм. «Йосыф шаша, сине эзләтә, балаларны алып чыгып китеп, сине эзләтә», — ди Җыракай. «Тавышланма, Җыракай, бу кеше ике көннән китә», — димен.

Полковник ваннага кереп кырына башлады.

Теге кырына, мин өйдә, кызым Зөлфия ишегалдында бәләкәйләр белән уйный иде. Бераздан йөгереп керде дә: «Әни, әни, сине дядя Йосыф чакыра», — ди.

Йосыф урамда мине көтә, мин урамга чыкмыйм инде. Өченче катта торабыз. Урамга карыйм. Йосыф ябыккан, куллары нечкәреп, салынып тора. Мине күрде бу. «Чык бер генә минутка», — дип кул изи.

Чыкмадым. «Ике көннән китә ул, бөтенесен ачыктан-ачык сөйләрмен», — дим. Мин дә ялындырам. Йосыф шунда ишегалдында төн уздырды. Аның белән бөтенләйгә аерылышкан идек бит, аның белән аерылышмаган булсам, мин полковник белән авылына да кайтмый идем. Ике көннән китте бу. Киткәндә, сабыр-сагышлы полковник: «Исән-сау бул, Актаныш кызы!» — диде.

Полковник китте. Икенче көнне Йосыф, әнисе, үзенең дусты белән өйгә килеп керделәр. Әнисе әйтә: «Нишләттең син минем улымны?» — ди. Мин әйтәм: «Без дус булдык сезнең улыгыз белән, ул бик ярдәм итте, морально, минем балаларым да аны яратты, ләкин без аерылыштык. Сез моны үзегез дә тели идегез», — дидем.

Йосыфның күзеннән мөлдерәмә яшь агып тора.

Йосыфка барысын да сөйләдем. Шуннан соң тагын кушылдык. Әллә ни кайнарлык юк иде арада. Просто дусларча очрашабыз.

Әлфия апа моңсулыкка уралды. Хатирәләргә кереп китте.

Әлфия ханымның гыйшкы, аның мәхәббәте хакында язганда, гайбәт кануннарын читкә куярга кирәктер, мөгаен. Ике тапкыр уңышсыз никахта булган, мәхәббәт белән романтик гыйшык күрмәгән, ике ирдән ике кыз баласы калган, ике иреннән дә үзе башлап аерылган яшь, дәртле хатынның алдагы тормышы ни белән бетәсе байтакларга мәгълүм. Балалар ташлана, аларны йә детдом ала, йә алар әби-бабасы тәрбиясендә үсә. Шулай яши торгач, ул хатынның беркемгә дә кирәге калмый. Ахыры фаҗига белән тәмамлана.

Безнең Әлфия Авзалова алар белән рәттән тора алмый.

Аның бердәнбер романтик мәхәббәте Йосыф иде. Йосыф аннан яшь булса да, ул Әлфия апаның тәрбиячесе, аның акыл бирүчесе, бозык юлга бастырмаучысы да! Егерме елдан артык алар бер-берсен сөешеп яшәделәр, ләкин Йосыф тарафыннан: «Балаларыңны ташла, мин сиңа өйләнәм», — дигән сүз чыкмый.

— Әлфия апа, Йосыф сиңа шундый тәкъдим ясаса, син ни кылыр идең? Балаларыңны ташлап аңа кияүгә чыгар идеңме?

Әлфия ханым бу сорауны яратмады, ахрысы, ул усал карап алды, ризасызлык галәмәте буларак:

— Ни сөйлисең син? — диде. — Минем башыма тай типкәнме?

Сүзсез дә аңлашыла. Әлфия апа Ана бурычын, Ана вазифаларын шәхси мәхәббәтеннән өстен куя. Үзе дә ятим үскән кыз бала үз сабыйларын ятимлеккә ташласа, ул Әлфия Авзалова булмас иде, башка бер хатын булыр иде.

Алда аны балаларының, оныкларының хөрмәте, мәхәббәте көтә.

## Миһербан ияләре

Минем сөйгәннәрем ике генә,
Берсе — җаным, берсе лә син генә.

*Керәшен җыры*

— Без бүген зарланышмыйбыз, Әлфия апа. Без бүгенге утырышны тормыш юлыгызда очраган миһербанлы кешеләргә багышлыйк.

Әлфиябез уйга калды. Чыннан да, ул узганындагы остазлары, тәрбиячеләре, туңган чакта җылы, ачыкканда ризык биргән кешеләр турында уйлый иде, ахрысы.

— Күршекәем, уйлап-уйлап утырам да тагын бер уйлап куям... Юлымдагы яхшы кешеләр күбрәк булган бит, яманнарына караганда... Үземнең Актанышымнан башлана бит минем тормыш-иҗат юлым. Актанышымда мин ятим булмаганмын дип утырам. Актанышым халкы арасыннан чыккан атаклы җырчы ятим була аламыни? Саҗидә апа, Мөхәмммәтвагыйз абый, Бибинур апа, Җәннәт апалар — бахыркайларым, урыннары җәннәттә булсын! Җыр остазым Мәрзия апа... Нәсимә апа Авзалова үз өстеннән салып кофта кигезде. Син сәхнәгә чыгасы кыз бала, матур киен, диде. Казанга килгәч тә мин кара ятим булмадым, Аллага шөкер. Зөләйха Әхмәтовага, гүзәл биюче Фәйтүнә Абдуллинага, җырчы Разия Тимерхановага мин рәхмәтле, композитор Александр Ключаревка рәхмәтле... Гөлшат Зәйнашева кебек миңа ярдәм иткән кешеләр бик сирәктер. Җырлары белән генә түгел, ул мине ике тапкыр квартиралы итте. Шау-шу куптарып, Әлфия Авзалова кебек җырчыны имчәк баласы белән нигә дымлы балчыкта яшәтәсез, дип, комиссия алып

килеп, фатир бирдертте... Фәйтүнә Абдуллина белән Разия Тимерханова аеруча якын булдылар миңа. Зифа апа Басыйрованы бик яраттым мин.

Композиторлар, музыкантларым яхшы булды минем. Район җитәкчеләре — Рәшит Хәмәдиев, Энгель Фәттаховлар... Барысы да миңа ярдәмчел булды. Инде менә бәхетнең иң олысыдыр, мөгаен, Президентыбызның килүе миңа гына түгел, бөтен сәнгать кешеләренә дә күз ачарга ирек бирде. Барысына да чиксез рәхмәтләр әйтәмен, исәннәрнең барысына да сәламәтлек, озын гомер, мәрхүмнәрнең урыны җәннәттә булсын, дип, изге теләкләр телим.

# Гүзәллекнең сере

Сөйкемле сөяге бар аның,
Шуңа күрә аны яраталар.

*Әйтем*

Әлфия Авзалова — үзенә тәнкыйди карый белүче шәхес. Ул үзенең иҗат мөмкинлекләренә аек акыл белән карый белә. Төс-кыяфәт турында сүз чыкса да, ул үзенең гүзәлләр гүзәле түгел икәнен яхшы аңлый. Үзенең шундый кыяфәтенә ул шаяру аша бага.

Бервакыт Әлфия Авзалова курортка китә. Кичләрен биюләр була. Бөтен чибәр-чибәр хатыннарны биергә чакыралар, Әлфияне чакыручы юк. Шулай ялгыз гына басып торганда, моның янына олы гәүдәле, Алып батырдай бер урыс кешесе килеп, танцыга чакыра.

— Какая хорошенькая обезьяночка! Пошли танцевать!

— Пошли, хорошенький медведь! — ди Әлфия.

Ир кеше рәхәтләнеп көлә башлый. Биегәндә сөйләшәләр болар.

— Вы чукча? — дип сорый ир кеше.

— Нет! — ди Әлфия.

— Тогда вы якутка?!

— Нет!

— Кто же вы, скажите, пожалуйста! — ди бу.

— Японка! — ди Әлфия ханым.

— О-о, хорошенькая японка! — ди ир кеше. — Тогда скажите что-нибудь по-японски!

— Һи-и, карт алаша! — ди Әлфия.

— О!.. Какие красивые слова по-японски! — дип шатлана ир кеше.

«Шулай япун маймылы булып йөрдем мин курортта», — дип сөйли Әлфия апа.

Әлфия ханым боларны көлә-көлә, кешеләрне дә көлдерә-көлдерә рәхәтләнеп сөйли.

Ләкин Әлфия Авзалова, сәхнәгә чыккач, гүзәлләр гүзәленә әверелә дә куя. Әлфия ханымны бик якыннан белгәннәр дә, ерактан белгәннәр дә аның, сәхнәгә чыккач, чибәр хатынга әверелүе турында еш сөйләшәләр.

Чыннан да, сәхнә артында хәлсез кебек кенә басып торучы 70 яшьлек Әлфия Авзалова, сәхнәгә чыгуга ук, гүзәлгә әверелә.

Бу чыннан да могҗиза! Сәхнәнең могҗизасымы, җырның могҗизасымы, Әлфиянең могҗизасымы? Аның башкалар белми торган сихере, әллә берәр сере бармы?

Бу сорауга җавап эзләүчеләр әле һаман да нәтиҗәләргә ирешә алганы юк. Ләкин шагыйрь Хәсән Туфан аның серен күптән аңлаган. Сөйкемлелектә икән хикмәт. Бар искиткеч чибәр кешеләр, ләкин ярты сәгать сөйләшеп торгач, аның матурлыгы югала бара, ул ямьсез булып күренә башлый, кешенең эчке дөньясы гүзәллек белән тулмаса, аның тышкы матурлыгы юкка чыга. Тыштан әллә ни матур күренмәгән кешеләрнең гамәлләрен белә башлагач, алар күзгә күренеп матурая баралар, син андыйларны хөрмәт итә, ярата башлыйсың.

Талант матурлый кешеләрне. Җыр сәнгатендә бу аеруча күренә. Кешенең эчке моңы аның йөзен матурлый. Әлфия Авзалованың эче тулы моң. Шул моң балкый аның йөзендә, шул моң аны гүзәлләр рәтенә куя!

Әлфия Авзалованың иҗат серләре күп аның. Матур була белү, гүзәл булып күренү осталыгы теләсә кайсы хатын-кызга да бирелми. Киенә белү дә монда зур роль уйный. Әлфия апа үзенә кием сайлый белә. Ул үзен сәхнәгә чыгарга әзерли белә. Яхшы җырлау бер хәл, шул җырны нинди матурлыкка төреп бирәсең бит әле?! Аңа бу серләр яхшы таныш.

Әлфия апа, яңа күлмәк тектерсә, тектерүгә үк сәхнәгә киеп чыкмый. Яңа кием кигән кеше киемгә күнегеп бетәргә тиеш, яңа кием кешенең хәрәкәтләрен тоткарлый, ул табигый булмаган киеренкелек белән йөри. Әлфия апа боларны да яхшы аңлый һәм, яңа күлмәге аның үзенә сеңеп, ятышып беткәнче, ул аны өендә киеп йөри, сәхнәгә чыккач, кием ят булмасын, үз булсын.

Иннек, кершән, сөрмә кебек бизәнү әйберләрен Әлфия Авзалова чамалап кына куллана, аның бизәнгәне артык кычкырып тормый.

Җырчы сәхнәгә чыгарга үзен алдан әзерли, һәм рухи яктан, һәм физик яктан әзерли. Гыйбадәт кылучылар ничек итеп изге дога кылырга, медитация үткәрергә әзерләнә, Әлфия Авзалова да шулай, тәфсилле, серле әзерлек белән концертка килә.

Яше олыгаеп барса да, җырчыбыз Әлфия Авзалова һаман сәхнәдә, һаман җырлый, аның тыгыз гәүдәсе, җыерчыксыз шома бите, җитез хәрәкәтләре күп кенә яшь җырчыларга үрнәк булып тора.

Аңа драматик талант бирелгән. Әлфия ханым җырны образга кереп, уйнап җырлый, бер кешелек театр барлыкка килә. Аның һәр җыры аерым спектакль.

Әлфия Авзалованы гүзәл итеп күрүче, гүзәл итеп күрсәтүче тагын бер компонент бар — халык, тамашачы! Тамашачы аның кайчак артыграк сөйләгәнен өнәп тә бетермидер, әмма җыр башлангач, барысы да онытыла. Әлфиянең җыр-моң могҗизасы башлана. Моңлы җыр башкарса, Әлфия залны, күңелләрне моң белән тутыра, шаян җыр башласа, залны дәртләндереп, күңелне ачып җибәрә. Биргән бит Аллаһы Тәгалә аңа барысын да.

Әлфия Авзалова җырны халык алдында иҗат итә. Тамашачы булмаса, ялгызлыкта ул җырлый алмый. Аңа туры элемтә кирәк, ул тамашачының күз карашын күрергә, сулышын тоярга тиеш.

«Мин буш стеналарга карап җырлый алмыймын, тимер-томыр арасында моң кача! — ди җырчы. — Залдан утны алып, күзгә ут көлтәсе җибәрсәләр дә, иркен җырлый алмыймын. Мин җырлаганда, зал яп-якты булсын, мин бар кешеләрне дә күреп, аларга карап җырларга тиеш. Юкса ике яклы элемтә була алмас иде. Алдан язылган тасмага ияреп авыз ачып тору ул җырны иҗат итү түгел, җырны механик рәвештә тапшыру гына».

Әлфия ханым холкы белән шаян кеше, көлке чыганагы, ләкин ялгызы калгач, ул гаять җитди, хәтта артык җитди кыяфәт ала, уйлана, көрсенә; аеруча якын кешесе белән бергә-бер калса, тормышыннан, кыенлыклардан зарлана, ләкин чит-ят кешеләр алдында ул һәрвакыт дәртле, үткен телле, мәзәк сөйләүче оста, әйтерсең лә Әлфия Авзалова ятимлек тә, юксыллык та, кыйналу-сугылуларны да күрмәгән. Бу — аның яшәү рәвеше: еламаска, сер бирмәскә, кыен булса да түзәргә, көрәшергә, ике баланы, апасының ятим калган балаларын аякка бастырырга, кеше итәргә, шулар белән беррәттән иҗаттагы омтылышны да онытмаска, эшләргә, тавыш күнегүләре ясарга, халыкка хезмәт итәргә, җыр мәйданында иң алдынгылардан булырга! Әлфия Авзаловага 74 яшь! Ул әле һаман сәхнәдә. Изге бурычын — Ана вазифасын, халкы алдындагы вәгъдәсен намус белән үтәгән, халкы тарафыннан тиешле бәясен алган Бөек Җырчы ул Әлфия Авзалова!

Ул бәхетле ана, бәхетле дәү әни, бәхетле җырчы!

**ӘХМӘТ РӘШИТ**

# Нурлы җырлар белән

*Мәшһүр җырчы Әлфия Авзаловага*

Күптән инде, күптән көткән иде,
Чү, офыкта ул ич — аһ, таныш;
Ерак юлдан кайткан газиз кызын
Сагынып каршы ала Актаныш.

Әй сибәли яңгыр, әй сибәли,
Юып күздән авыр яшьләрне;
Өмет кенә иде озатканда —
Биргән Ходай озак яшәүне.

Ак пароход алып киткән иде,
Күрсен диеп ерак илләрне;
Җырчы Әлфиясен Актанышның
Аяган ич язмыш җилләре.

Бер кыйтгадан йөртеп бер кыйтгага,
Яңгыратты илнең киң күген —
Өч октава артык тавыш белән
Габәшинең мәшһүр «Кәккүге».

Кем икәнен белсен татарның дип,
Ерак-ерак казакъ җирендә,
Курмангазый моңы сеңгән җырлар
Ташып чыкты күкрәк түреннән.

Ташты җырлар һинд сылуы булып,
Һәм гүзәле булып Мисырның;
Бер йөрәктән күчсә бер йөрәккә,
Туктап калыр җае юк җырның.

Ул агыла... Агыла шатлык булып,
Ул агыла сагыш булып та,
Сөю булып бөреләнгәч туган
Ашкынулы хискә тулып та.

Еллар кичә. Еллар кичкән саен
Гел көчәя бара бу тавыш —
Табигатьнең бу зур хәзинәсен
Бүләк иткән аңа Актаныш.

Яңгыр ява, диеп еламасын, —
Актанышын гел дә ул сөя;
Кояш нурына тиң җырлар төяп,
Илгә кайтып бара Әлфия!

**РӘНИФ ШӘРИПОВ**

# Әлфия Авзалова

Җан сулышы кирәк сулар өчен
Ерактагы җырлар һавасын.
Җырны башлап була,
Тының җитсә әгәр
Кабатларга чорлар авазын.

Аңа язмыш кирәк,
Бераз сагыш кирәк,
Күңеленә уеп моң салган.
Чор сулышы түгел,
Күр, сәхнәдә тагын кем калган?!

Көчәнмәгез юкка, гамьсез җаннар,
Изге җырда ялган булмасын!
Чорны аңлап була,
Җырны алдап булмый,
Җыр ул үзе сайлый юлдашын.

Әнә килә алар еллар ерып —
Тынчу булса да чор һавасы.
Моңлы күңел язы,
Ерак җыр авазы,
Җылы яңгыр булып явасы...

**ГАРИФ АХУНОВ**

**ИЛДУС АХУНҖАНОВ**

# Филармониянең бер концертында

...Сәхнәгә бер-бер артлы яшьләр чыга.

Менә филармония артистлары Р.Ибраһимова белән М.Әхмәдиев беренче тапкыр ике баянда композитор С.Сәйдәшевнең «Совет Армиясе маршы»н башкаралар. Баян моңнарына яшьлек кайнарлыгы үрелеп бара төсле. Күптән түгел генә Казан дәүләт консерваториясен тәмамлаган В.Вәлиев калын «бәрхет» тавышы белән «Эшче» операсыннан Нигъмәт ариясен җырлый. Менә филармониянең яшь артисткасы Ә.Авзалова татар халык җырларын башкара: якты сәхнәдән залга барыбызга да бик таныш җыр — «Кәккүк» җыры агыла. Иркен, сабыр, бераз моңсу мелодия, залны сәхнә белән тоташтырып, безне җәйге урман эченә алып кереп китә кебек... ТАССРның атказанган артисткасы Г.Сөләймәнованың искиткеч башкаруында бу җырны күп тапкырлар ишеткән тамашачы яшь артистканың чыгышында аның укытучысына иярүен беркадәр сизде сизүен. Булса соң! Килер бер вакыт, яшь җырчы үз тавышын, үз аһәңен табар. Сәнгать осталарының йогынтысы бервакытта да яшьләрне бер урынга «кадаклап» куймый, киресенчә, аларга үз тавышларын, кабатланмас үз матурлыкларын табарга ярдәм итә.

Ә.Авзалова «Әгерҗе», «Көймә килә», «Сәрия» кебек популяр җырларны шулай ук бик матур башкарды.

— Үзешчәннәндер бу кызый, филармониягә клубтан килгәндер, клуб уеннарын иллә матур башкара, — дип куйды безнең күршебез, күмәк хуплауга кушылып.

Чыннан да, үзешчән түгәрәкләрдән берегә — зур сәхнәгә килгән Ә.Авзалова үзен бу концертта үсеп баручы сәләтле яшь җырчы итеп күрсәтә алды.

*«Совет Татарстаны»*
*9 июнь, 1954*

**ХӘЛИМ ГАЙНУЛЛИН**

# Рухи бергәлек

*Казан артистларының Ленинградтагы гастрольләре уңаеннан*

...Һич бетәрме тарихи бу бергәлек? —
Без туган бер җепкә бергә теркәлеп.

Сөекле шагыйребез Г.Тукайның җиде дистә ел элек әйткән шушы сүзләре безнең көннәрдә яңа эчтәлек белән баеды. Халыкларыбыз хәзер чын мәгънәсендә «тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып» яшиләр, казанышларыбызны ишәйтүгә үзләреннән лаеклы өлеш кертәләр. Бу — мәдәният өлкәсендә аеруча калку күренә. Казанда, әйтик, ел әйләнәсендә нинди генә театр коллективлары, төрле республикалардан килгән әдәбият-сәнгать әһелләре булмый?! Руслар, украиннар, казах, үзбәк, башкорт дуслар... Ә безнең сәнгать осталарыбыз Себердә, Урта Азиядә, Ерак Көнчыгышта һәм башка җирләрдә уңышлы чыгыш ясыйлар.

Мисалга Нева буендагы гүзәл Ленинград шәһәрен алыйк. Урамнардагы афишаларга күз салсаң, шатланып, горурланып куясың. Исеме бөтен дөньяга мәгълүм театр — Ленинградның С.М.Киров исемендәге Дәүләт академия опера һәм балет театры тамашачыларны татар композиторы Фәрит Яруллинның Тукаебыз әсәренә нигезләнеп язылган «Шүрәле» балетын карарга чакыра. Культура сарайларында РСФСРның халык артисты Ренат Ибраһимов җырлый. Нур өстенә нур дигәндәй, күптән түгел Ленконцерт РСФСРның атказанган, Татарстанның халык артисткасы Әлфия Авзалова чыгышларын оештырды. Әлеге концертлар биш миллион кешеле шәһәрнең музыкаль тормышына яңа бер бизәк өстәде, аны тагын да баетып җибәрде.

...Ленинград концертлар залы. Атна буе җыр-музыка сөючеләрне үзенә тарткан урын шул булды. Концертларга билетлар шактый алдан сатылып беткән иде. Әгәр Ә.Авзалованың биредә узган ел башында гына булып китүен искә алсак, бу факт халыкның танылган җырчыбыз иҗатына соклануы турында сөйли түгелме?!

Концерт — һәрчак зур бәйрәм. Ул һәр көнне өч сәгатьтән артык дәвам итте, әмма берәүне дә ялыктырмады. Программаның бүгенге тамашачы таләпләрен күз уңында тотып төзелүе, зал белән сәхнә арасында баштан ук җанлы элемтә урнашу, нәфис сүз, юмор — болар барысы да бер максатка — концертның эмоциональ тәэсир итү көчен арттыруга хезмәт итте.

Әлфия Авзаловага һәр җырның рухын сизгер тоемлау, югары профессиональ осталык хас. «Сәхнә законнары ясалмалылык белән сыеша алмый, — диде ул тәнәфес вакытындагы очрашуда. — Монда җыр текстына тәңгәл килә торган хәрәкәт, йөрәгеңдә җылытылган, бөтен җаныңны биләп ала торган моң гына матур аһәңле яңгырый һәм тамашачы күңеленә шатлык булып барып җитә, аны уйланырга, фикер йөртергә мәҗбүр итә...»

Нәкъ менә шуңадыр, популяр җырчыбызның чыгышлары тамашачылар тарафыннан җылы кабул ителде. Сәхнәдә көчле яктырткычлар хасил иткән төсләр балкышы, урынлы мимика, хәрәкәтләр җырларның тәэсир көчен тагын да көчәйтеп җибәрде.

Җырчының репертуары гаять бай, тематикасы төрле. Нәкъ менә шуңа күрә җырларның берсе дә тамашачыны битараф калдырмады. Концертта яңгыраган «Күбәләгем», «Их, җаныем, суларда» кебек халык көйләре, «Сәлам дусларга» (Р.Сафиуллин музыкасы), «Кайт, әтием» (И.Мәҗитов), «Актанышым» (И.Закиров) кебек соңгы вакытта гына иҗат ителгән җырлар зур осталык белән башкарылды. Күз алдында — гүзәл Татарстаныбыз, анда КамАЗ кебек гигантлар коручы, мул иген үстерүче замандашларыбыз килеп баскандай булды. Казан, республикабыз белән элемтәләрен өзмәүче ленинградлылар бу минутларда олы горурлык, сагыну хисе кичерделәр.

*«Социалистик Татарстан»*
*1982*

# Сөем — ...

РСФСРның атказанган, Татарстанның халык артисткасы Әлфия Авзалованың тавышын телефоннан «Сөембикә» сүзен әйтүгә үк танып алдык. «Хөрмәтле «Сөембикә» журналына җиткерәсе килгән фикерләрем бар иде», — дип, ул безне үзенә кунакка чакырды. Шуңа да сөекле җырчыбызның журналыбызга кагылышлы фикерләре булуы безне аеруча кызыксындырды.

— Гомеремә яратып укыдым «Азат хатын» журналын. «Сөембикә» булып исеме үзгәргәч, әллә исеме бик килеште инде үзенә, бөтенләй «үсте» бит журналыбыз! Әле күптән түгел генә Омск һәм Томск өлкәләрендә гастрольдә булып кайттым. Поездга кереп утыргач та, җиргә бөкрәя төшкән гәүдәле ягымлы татар карчыгы таң калдырды үземне: «Кызым, син әйбәт җырлаучы Әлфия түгелме соң? «Азат хатын» журналыннан сурәтеңне күреп, синең турыда язылган сүз укып, якыннан танышкан идем үзең белән. Кем белгән тереләй дә күрергә насыйп булыр сине дип».

Казакъстан якларындагы ягымлы татар карчыгына кадәр минем белән «Азат хатын» — «Сөембикә» аша танышкан икән — бу инде халкыбызның милли җәүһәрләрен данлау һәм тоткан кыйблабызның изге нияттә булуына ишарә ләбаса?! Сәхнәгә чыгып, үзең турында күп белешмә биреп булмый. Ә менә журнал битендә сине күреп, барлап, сурәтең белән синең турыда язма басылгач, кабат-кабат рухланып, журналист каләменә сокланып укыйсың-укыйсың да үзеңне тагын бер тапкыр яратып куясың. Дөрес сөйлимме мин? — Әлфия апа безнең якка ягымлы күз карашын ташлап алды. — Инде Казан шәһәрендә октябрь аенда саубуллашу концертын үткәрергә җыенам. Сәхнәгә чыгып басуыма, Батулла кичәсендә халык гөр килеп кул чаба башлаган иде. Аптырап киттем: «Нигә алкышлыйсыз, җырламадым бит әле!» — дим. Бик борчылган халык. Авыртып, тамагыма операция ясатуымны да ишетеп өлгергән. «Ике җирдә мин пропискада, — дидем. — Берсе Ямашев урамында булса, икенчесе — хастаханәдә». Шуңа да, күрәсең, халык күңеле йомшап елагандыр ул көнне.

Хастаханәдә ятканда, Чаллыдан бертуган Кашаповлар яныма килеп, хәлемне белешеп тордылар. Булса да булыр икән кешедә изгелек дип сокландым мин бу бәндәләргә. Бу сүзне сезнең өчен генә сөйлим. Минем аларга булган рәхмәтемне дә «Сөембикә» журналыннан укып белсеннәр әле, дим.

Халык мине җырлаганчы ук алкышлаган кебек, «Сөембикә» журналының һәр санын да ул зарыгып көтеп ала. Бүгенгесе көндә журнал — аның сердәшчесе дә, киңәшчесе дә, ярдәмчесе дә. Иҗат чишмәгез саекмасын, сезне укучылар саны тагын да артсын, дигән теләктә җырлыйм җырларымны.

*«Сөембикә»*
*Май, 1998*

**РӘЙСӘ ЮСУПОВА**

# Күктә йолдызлар атыла

*Нәсер*

Аны тагын тау башындагы йортка чакырдылар. Бу юлы чакыру, гәрчә рәсми төстә булса да, серлешикле түгел иде. Чөнки әлеге чакыруны көтеп яшәде ул — аны, Авзал кызы Әлфияне, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләү турында газеталар алдан хәбәр иттеләр бит. Шушы олы бүләкне алырга җыенуы Әлфиянең. Ашыкмыйча гына көрән төстәге костюмын киде, аңа орден, медаль, башка мактау билгеләрен такты һәм, кулларын кесәсенә тыгып, җырлый-җырлый көзге янына килеп басты. Чү! Бармаклары ниндидер кәгазьгә тиде. Тәне буйлап кинәт салкын дулкын йөгерде, җыр өзелде, аякларын көчкә өстерәп, креслога атлады: җанны шушылай суырган бу бәләкәй ак биттә теге чакта... Әйе, теге чакта шул тау башындагы йортта бирелгән телефон номеры иде.

Теге чакта да шулай телефон шалтырады: секретарь кызның җитди тавышы аңа, Әлфия Авзалова, Татарстан Югары Советына Фәлән Фәләновичның үзе янына сәгать 10 га килеп җитәргә кушты.

Шушы көрән костюмын киеп барган иде Әлфия ул чакта да. Түрдә, имән өстәл артында утыручы Фәлән Фәләнович күз кабакларын көчкә күтәреп, сүз башлаган иде:

— Менә бит, иптәш Авзалова, сине эчә диләр бит. Хат бар. Авылга килеп төшкәч тә аракы кибетенә йөгерәсең икән. Аннары, эчеп исергәч, клуб янында егыласың икән дә, сине күтәреп кереп, сәхнәгә бастырып куялар икән. Менә почта печате дә бар, авылдан язганнар.

Юк, боларны ишетеп һушыннан язмады Әлфия, һушыннан язмас өчен өстәл астындагы тезләренә тырнакларын батырды. «И-х, Кешем, — дип кысылды йөрәк, — мин бит сиңа хезмәт итәм, җырларым белән йөрәк яраларыңны дәвалыйм. Ә син... Шушы пычраклыкны язарга ничек кодрәтеңнән килә?!»

— Нигә эндәшмисең? Әллә ялган язалармы, иптәш Авзалова?

— И абзыкаем, — диде дә Әлфия елап җибәрде. — Мин... мин... мин... исерек хатынга охшаганмыни мин? — Гарьләнеп үкседе дә үкседе. Яшь пәрдәсе каплаган күзләре алдына куелган сулы стаканны да күрми иде. — Ятимнәр карыйм бит мин. Сеңлем үлде — аның алты сабыен туендырам. Үземнең ике кызым бар. Бөтенесе дә Авзалованыкылар! Аларны ашату, киендерү — минем өстә. Мин гастрольләргә дә, сумкаларга тутырып, ризык алып чыгам. Үзем пешереп ашыйм. Ашханәләргә йөрергә минем акчам булмый... Балачагым булмады минем. Туган көнемне белмим мин. Бәйрәмнәрне яратмыйм...

Куллары белән битен каплап, Әлфия ишеккә йөгерде. Баскычта аны кемдер куып җитте, кемдер кесәсенә кәгазь кисәге салды, ә аңына кемнеңдер авазы барып орынды:

— Кыерсытучылар булса, турыдан-туры Фәлән Фәләновичка шалтырат. Бу — аның телефоны!

...Фәлән Фәләнович хәзер анда юк инде.

Иртәгесе көнне республика газеталары Авзал кызы Әлфиягә Татарстанның халык артисткасы исеме бирелү турында хәбәр иттеләр. Димәк, Зур йортта әлеге пычрак шикаятькә ышанмаганнар. Бу — иртәгесе көнне. Ә аңа хәтле Әлфиянең әрнүле көне, йокысыз бер төне бар иде. Бу төнне ул газаплана-газаплана мең мәртәбә бала чагына кайтты, үтелгән юлларын айкады.

И гөнаһсыз балачак!..

Әнә ич, җигүле ат өйгә якынлашып килә. Әтисе ат башыннан тоткан. Нигә бу арбага әнисен сузып салганнар соң? Өстенә җәймә дә япканнар, җитмәсә. Әй-лә, үлгән диләр бит...

Өйгә җыелган кешеләр исә, күз яшьләрен сөртә-сөртә, Әлфиянең башыннан сыйпыйлар. И рәхәт! Акча да бирәләр. Күр инде, күр! Сеңлесе Флюрага күбрәк бирәләр түгелме соң? Әлфия кычкырып елап җибәрә...

Әтисе... Кешеләр аны зимагур диләр, зимагурлыкта йөри диләр. Ачлыктан, суыктан елап арыган сеңлесен кочаклап, Әлфия мич башында яши. Морҗада усал җил сызгыра, кирпечләрнең салкыны эчкә үк үтә, түшәмгә карлы боз каткан.

Иң салкын көндә, әйе, иң-иң салкын көндә, Җыракае (әнисенең бертуган Закирә апасы) аларны алырга килә. Ат җигеп.

Саламга төреп салынган ике сабыйны әнә ич бахбай Актанышка, юк, юк, гади Актанышка түгел, туган йортка, парлары чыгып торган җылы өйле Актанышка алып кайта.

Ишеккә төбәлгән ике күз сабыйларны бусагага «кадаклый». Бу — җизни күзләре. Нинди мәрхәмәтсезләр алар. Бу күзләрне күрмәс өчен ул чыгып йөгерергә, кабат карлы-бозлы кирпечләрне кочаклап ятарга да әзер. Тик аяклар бусагага «кадакланган», тән куырылган, кыймшанып та булмый...

— Бар, — ди Җыракае, Актаныш базарына килүчеләргә ишарәләп, — ияр дә әнә зимагур атаң янына кайт, аны авылда диделәр, күзем күрмәс беразга, колак иткәйләремне чәйнәмәсләр, ичмасам...

Әле яңа гына кар сулары аккан сукмактан, «чебиле» тәпиләрен җәт-җәт басып, Әлфия атлый. Юк, атламый, базарчылардан калышмаска тырышып, язга куанучы кошлар төркеменә карый-карый йөгерә сабый.

Базар «уңышлары» турында бик җанлы сөйләшеп кайтучы апайлар кинәт җыру ишетеп хәйран калалар. Җыруны, кошларга кул изи-изи, шушы сабый суза:

Түгәрәк күл матур була
Су белән тулса гына.
Тусын кыз бала анадан
Бәхете булса гына...

Сугыш... Бу сүзнең мәгънәсен төшенми Әлфия. Сугыш сүзен кушып урамда елаучы әби-апаларга карап аптырый бала. Урам малайлары сугыша ич — аның нәрсәсенә елыйсың ди инде. Ә бу сугышта Актаныш кешеләре немец дигәннәр белән сугышачак икән. Сугышсыннар, кызык ич.

Әнә такмаклый-такмаклый Җыракае елый.

— Исән-сау гына әйләнеп кайтырга язсын, — ди җизнәсенә, — үлемкәйләр урап узсын, Ходаем.

Әһә, дип куана Әлфия, бу сугыш кешеләрне үтерәчәк икән: җизнәсен үтерсен ул, җизнәсен! Кыз, өй түбәсенә менеп, елый-елый дога кыла: «И Раббым, сугышка ал син бу җизни дигән бәндәңне, беркайчан да кайтарма син аны бу өйгә, кайтарма, Раббым».

Аннан соң сугышның башка сурәтләре барлыкка килде.

Тәүге сурәт серле иде. Әйе, сугышны ул унөч-унҗиде яшьлек егет-кызларның аулак өй уеннары аша күрде. Әнә ич, эти-абыйлары сугышка киткән үсмерләр, басу-фермаларда көне буе эшләп аруларына да карамастан, «Йөзек салыш» уены уйныйлар. Кемдә йөзек, шул җыру суза йә биеп күрсәтә. Ә Әлфия кебек балалар мич башына тезелешкән. Көнләшә-көнләшә «өлкәннәр»не күзәтәләр.

Аннары сугыш усал абыйлар кыяфәтенә керде. Әнә Җыракаен ике кесә борчак өчен төрмәгә утырттылар.

— Сабыйларым өчен бит! Ятим сабыйларым ачтан үлмәсен өчен алдым, — дип тә караган иде Җыракай...

Ятимлек сурәтендә дә икән әле ул сугыш. Җыракаен алып киткәч, Әлфия, бердәнбер сеңлесеннән аерылып, Яңа Әлем балалар йортына китте. Шушында, балалар йортында, этисе-әнисе сугышта үлгән чын сугыш ятимнәрен дә күрде Әлфия.

Күрде дә сугышның олы бер куркыныч нәрсә икәнлеген аңлады.

Үсмер чакның хатирәсеме? Моңлы кыз баланың «Гөлҗамал», «Кәккүк» җыруларына уралган матур сарафан сурәтендә ул. Егетләрнең һушын алган, кызларның күзен кызыктырган бу сарафан фашист Германиясен җиңгәч, союздашларыбыз америкалылардан мәктәпкә адресланган посылка эчендә килгән иде. Аны мәктәпнең горурлыгына әйләнгән Әлфия Авзаловага бирделәр. Үсмер кыз бала үз гомерендә әле беренче тапкыр, Җыракаеның капчыктан теккән күлмәген салып, яңа кием кия.

И гүзәл дөнья, кояшлы икәнсең ич син, кояшлы! Әнә ич аның беренче укытучысы — Нәфисә апасы Акмалова йөзендә дә кояш балкый, Мәрзия апасы Юнисованың баяны телләрендә дә нурлар уйный. Кояш нурлары. Сарафанлы кыз йөзендәге кояш әнә ич ашлык көшеленә дә төшкән, юк-юк, алай гына да түгел — бөтен ындыр табагына җәелгән! Үсмер кыз кергән клуб эчләре дә яктыра сыман. «...шомыртым» җыры да шомырт чәчкәседәй ак нур тарата икән ич, гүя зәңгәр күктән йолдызлар атыла. Хәер, аның йолдызы, җыр, моң йолдызы менә шушы тәүге җырларында кабынды да инде.

Агитбригада составында район авылларын «мең» кат әйләнгән сарафанлы кызны укытучылары — Гаффаров абыйсы белән Марселиза апасы Газетдинова — олы юлга алып чыгалар.

Шулай итеп, агач чемодан күтәргән Әлфия Авзалова Казан каласына, Татарстан комсомолының өлкә комитеты бинасына аяк баса.

И Казан! Нурлы Казан! Серле Казан! Җырлы Казан!.. Шушы «дога» белән Әлфия йокыга китә. Шушы «дога» белән таңны каршылый. Юыла-юыла котны алып туза башлаган бердәнбер сарафанын киеп, музыка училищесына ашыга, ансамбльгә йөгерә! Эшли дә, укый да ул.

Әгәр Әлфия юлында Рәйсә Волкова, Михаил Федорович Боголюбовлар очрамаса, кем булыр иде икән ятимә татар кызы?!

Сәләтенә инанган остазлары аны Мәскәүгә укырга җибәрәләр. Кыз анда да сынатмый, бик тиз арада башкорт, казах, үзбәк, кыргыз, һинд, төрек, гарәп, фарсы, испан, корея, кытай телләрендә җырларга өйрәнә...

— Артистка булып туган ягыңа кайтасың киләме, Әлфия сеңел? — ди бердәнбер көнне аңа Гали Җәмлиханов. — Актанышка китәбез. Әгәр теләсәң, бу юлы мин сине дә концерт бригадама алам.

Теләмиме соң?! Тели, бик тели Әлфия.

Һәм 1953 елгы Меңнәр авылындагы аның бу тәүге гастроле хәтеренең иң түрендә саклана. Ничектер хәтта сөйләмнәре белән үк шул чор авылының халык образы булып саклана: салам түбәле, алты терәүле салкын клубта утыручы шинель, чабаталар кигән солдат хатыннары булып та, отчет-сайлау җыелышы президиумында утыручы җиде агай булып та. «Кара син аны, колхозның барлык авыр эшен хатын-кыз алып бара, ә президиум өстәле артына ир-ат оялаган» дип уйлап, якташлары өчен оялуы да хәтерендә.

Бәләкәйрәк буйлы, чандыр гәүдәле, кап-кара күзле, «җыр хезмәтенә теше-тырнагы белән ябышкан» бу кызны артистлар арасында бик тиз күрәләр. Татарстанның халык артисты Усман Әлмиев үз бригадасында аны Урта Азия гастрольләренә алып китә.

Ул чактагы бер «итагатьсезлеге» өчен хәзергәчә Усман Әлмиевтән оялып яши Әлфия. Ташкентның мәшһүр сараенда диңгез булып җәелгән тамашачы алдында «Кара урман», «Өй артында шомыртым», «Актаныш басмалары», «Кәккүк» кебек җырларны җырлап көчле алкышларга күмелгән иде ул. Ә Усман абыйсына кешеләр әнә теләр-теләмәс кенә кул чаба. Тиргә батып сәхнә артына кергән Әлмиев янына Әлфия йөгереп килә дә: «Усман абый, шушы «Гөлҗамал» җыруын Сезнең өчен халыкка үзем генә җырлап бирим әле», — ди... Йә Хода! Олы артист Усман абыйсы ул чакта Әлфия турында ни уйлады икән?

Артист кызның тормышында олы борылыш ясап 1955 ел туа. Әлфия Авзалова һәм Илһам Шакиров үз бригадаларын төзиләр. «Яшьләр сәхнәдә» исемле бу ансамбль кыяр-кыймас кына беренче адымнарын ясаган көннәрдә, Әлфия инженер егеткә кияүгә чыга.

Ансамбль Әлфиягә җырчы даны китерә.

Авыр юллы гастрольләр башлана. Әлфияне алкышларга күмүче тамашачы сәхнә пәрдәсе артында аның ике сабые йоклап ятканын каян белсен?!

Бала вакытының кара шәүләсе булып, җизнәсенең усал күз карашы исенә төшкән саен, биш баласы булган тол иргә кияүгә чыгар идем дә шул ятимнәрне җылы күз карашым белән иркәли-иркәли тәрбияләп үстерер идем, дип уйлый Әлфия. Әмма аның юлында мондый тол ир очрамый. Шулай да... ятимнәрне карарга туры килә аңарга. Алты баласын калдырып сеңлесе Флюра, аннары аның ире дә вафат булгач, үзенең ике кызы янына шул балаларны да алып кайта ул. Алты ятимә, кечкенәсенә — алты ай... Сигез бала язмышы өчен җаваплылык аңа, бәләкәй генә бер хатын җилкәсенә төшә.

Ятимлекне генә сизмәсеннәр! Риза, ул барысына да риза.

Чираттагы ялын ала: балаларын кинотеатрларга йөртә, тәмле-тәмле ризыклар пешерә, киендерә, тик... ятимнәр күзендәге сагыш бетми дә, кимеми дә.

«Мин аларга әниләрен хәтерләтеп торам...» Әлеге серне белгәч, сабыйларның һәммәсе белән дә киңәшкәч, тагын балалар йортының ишеген шакырга туры килә Әлфиягә...

Урта Азиягә беренче мәртәбә дүрт айлык гастрольгә ул шул чакта китә: балаларым бераз онытылсыннар, күнексеннәр дип уйлый.

...Юк, дөрес эйтмәгән ич теге чакта Әлфия Фәлән Фәләновичка. «Бәйрәмнәрне яратмыйм», имеш. Шул көннән, әйе, сабыйларын балалар йортына урнаштырганнан бирле, бәйрәмнәрне көтеп ала ул. Балаларның барысын да җыеп алып кайта да мул итеп аш-су әзерли. Идәнгә, җәймә өстенә олы ашъяулык җәя. Берничә көн буе көлә-көлдерә аларны сыйлый. Алып куйган бүләкләрен өләшә. Бу һәр бәйрәмдә шулай. Бу һәр баланың туган көнендә шулай. Тик... Нигәдер Әлфия үзенең дә туган көне барлыгын белми. Бәлки... бәләкәй чакта үзен дөньяга туганы өчен генә дә гел-гел битәрләүләренә-каһәрләүләренәдер.

Көз иде. Күксел-соры болытлардан сыкрап кына яңгыр сибәли.

Ялын алып, авылына — Актанышына кайтучы Әлфия шул җан өшеткеч яңгыр астында Җыракаен күрде. Әнә ул, бөкрәеп утырган да беләгенә утын төйи. Кыйшаеп беткән, җиргә сеңгән шушы өйне җылытмакчы буламы? Тамагына утырган төерне йотып, ул апасын кочаклый:

— Мин квартира алдым бит, Җыракаем. Өр-яңаны. Сине алырга кайттым. Түремдә утырачаксың...

И Казан каласы! Тагын бер ятимеңне, инде олыгайган ятимеңне каршы ал!

Рәнҗетмәде шәһәр әбине. Юк, рәнҗетмәде.

Бермәлне Әлфия уч тутырып акча алды. Дүрт айлык хезмәт хакы (гастрольләр бит!) һәм отпуск акчасы иде ул. Банк кассасында ул аларны өр-яңа унарлыкларга алыштырып чыкты.

Акча яратучы Җыракаен сөендерсен әле!

Бусаганы атлап кергәч үк юри егылган булды. Әлбәттә инде, ул уйлаганча, ачык сумкадан өр-яңа унарлыклар идәнгә сибелде. Юк, секунд та үтмәде, Җыракай бөтен гәүдәсе белән акчалар өстенә ауган иде инде. Суда йөзгәндәй, беләкләре белән ашыга-ашыга әнә ул аларны күкрәге астына этәрә.

— Җыракаем, — ди Әлфия, елмаеп, — бу акчаларның бөтенесе дә сиңа! Ни аласың килә — ал! Һәммәсе дә синеке!

Җыр хезмәтен дә Җыракае үз күзләре белән күрде. Эчтән генә көйләп йөрүләренә дә, тиргә батып әзерләнүләренә дә, әйе, ул шаһит иде.

Әнә бүген аның Әлфиясен Мәскәү алкышлый. Башкаланың затлы сараенда меңәрләгән тамашачы алдында җырлап сынау тотты шул! Күзләрен челт-челт йомып беренче рәттә утыручы Җыракае, мөгаен, шулай уйлагандыр. Аягүрә баскан халык алдында, көчле алкышлар астында Әлфиясе сузган чәчәкләр көлтә-

сен, бу чәчәкләрдә синең дә өлешең бар дигәч кенә, кәшемир яулыгы белән йөзен бераз каплап, ояла-ояла гына алган иде бит.

Аннары соңгы көннәренең берсендә ул болай диде:

— Хәтерлисең микән, кызым, сабый чакларыңда җизнәң сине бик рәнҗетә иде. Үз баласы булмауның үчен шулай синнән алуы булгандыр. Дөньясы да авыр иде бит. Тормыш кыенлыгының бөтен үчен мин дә синнән алдым — кыйнадым. Бүген әнә син ятимә баладан Ил кызына әйләндең, Ил түренә күтәрелдең. Сынатмадың, кызым. Рәхмәт Совет хөкүмәтенә дә. Синдәйләрне үз канаты астына ала белүенә рәхмәт!.. Мең ризамын синнән, Әлфия балакаем, мең риза!..

...Җыракае аңа унике ел элек:

— Ил түренә күтәрелдең! — диде.

Халкы күтәрмәсә ничек үсәр, ничек күтәрелер иде ул?!

«Су буеннан әнкәй кайтып килә», «Туган авылым», «Җәйнең матур аяз таңнарында», «Яшьлегем туга-е», «Әнкәй», «Җидегән чишмә»ләреннән тетрәнүче, сафланып калучы, «Җаным жәл түгел сиңа», «Гөрләшеп яшик, дуслар»ына кушылып куанучы тамашачысы бар икән, утыз биш ел дәвамында иң зур концерт залларында да бер генә буш урынны да хәтерләми икән — ничек инде аны бик бәхетле җырчы димисең?!

Үзе белән бергә иң беренче булып татар сәхнәсенә эстрада җырлары да алып менгән икән, бу җырлары белән бергә ул сәхнәдә яши икән — халкына хезмәт итү бәхетеннән аны кем аера алсын?!

Теге чакта тау башындагы йортка килгәч, аны, Авзал кызын, Ил түреннән төшерергә исәпләнгән имзасыз хатмы?..

— Юк! — диде Әлфия үз-үзенә. Һәм, креслосыннан торып, теге газаплы төн хатирәләрен искәртеп торучы телефон номеры язылган әлеге кәгазь кисәген йомарлады да балконга юнәлде...

Тауга берәү күтәрелеп килә. Агыйдел кызы Әлфия Авзалова ул.

Орден алырга барышы...

*«Азат хатын»*
*Май, 1988*

**ИСЛАМ ГАЛИН**

# Һаман синдә күңел

— Төшемә арыш кыры кереп йөдәтә, Наил энем.

— Кырда дуга күмелерлек кар ятса дамы, Әлфия апа?

— Күз ачкысыз буранда да шулай, арыш серкәләнгән көннәрдә дә. Еракларга китсәм, ни хикмәттер, туган як авылларын сагына башлыйм. Хатирәләремнең иң мөкатдәсе авылга барып тоташкангадыр инде.

Бу көнне дә халкыбызның яраткан җырчысы Әлфия Авзалова, Арча кунакханәсеннән партия райкомы секретаре Наил Габдрахмановка шалтыратып, үзен кичке концертларга хәтле берәр авылдан әйләндереп кайтуын сорады.

— Сөтләп чәй эчәрбез, халыкның күңел сандыгына ниләр өстәлгәнен белербез. Вакыт кысмаса, тәвәккәллик!

Әтнәгә чаклы кырык чакрымлы ара сизелмәде дә. Җырчы юл буена «Илаһи, көне дә көне. Яз галәмәтедер инде» дип, һавага сокланып барды.

Килеп җиткәч, туры фермага киттеләр. Халыкның беришесе төшке ашка кайтып китсә дә, артистка белән сөйләшергә дип кеше хәйран җыелды. Араларында шушындагы Тукай совхоз-техникумында укучылар да бар иде. Практика узалар икән.

— Яшәү учагы сезгә кала, дусларым, — диде җырчы, аларга карап. — Шул учакны сүндермичә киләчәк буыннарга тапшырырга тиешсез. Туган туфракта төпләнеп калырга карар кылуыгыз бик шәп. Димәк, авылның таяныр таянычлары бар!

Берникадәр сөйләшеп утырганнан соң, Әлфия апалары сораулар яудыра башлады.

— Гармун тавышы тынмадымы авылларда? Тынмасын. Гармунсыз авыл сандугачсыз урман шикелле бит ул. Аулак өйләр, кич утырулар бармы? Их, куыклы керосин лампалары яктысында җырлар көйләп, кулъяулык чиккән кичләрнең берсен генә кире кайтарасы иде хәзер. Бәби туйлары күпме? Игелек-әдәпне акча кодрәте басып китмәдеме?

Беравык дәшми торганнан соң, сүзен дәвам итте:

— Авылның әхлак чишмәсе икәнлеген беләбез. Чишмә икән, аны карап, чистартып тору зарур. Ашкынулы заман авылга да яңа төсмерләр китерде. Арада кирәксезләре дә юк түгел. Хөр фикерне, ак күңелне хәмер, ызгыш-талаш, бәгырьсезлек басып китмәсен иде. Гомер яланын үткәндә, шуны истән чыгармагыз, яшь дусларым...

Аннары фотохәбәрче Алик Биктимеров җырчыны яшь дуслары белән ферма тирәсендәге ак каеннар янында истәлеккә фоторәсемгә төшереп алды.

Эштә ут уйнатучы эшсөяр терлекчеләр белән дә сөйләшер сүзе күп булды Әлфия Авзалованың.

*«Социалистик Татарстан»*
*1989*

**МИРҺАДИ РАЗОВ**

# Рәхмәт сиңа, җыр!

Күп чишмәләрне күргәнем бар минем. Талгын гына челтерәп агып ятканнарын, ярларына сыя алмый ташыганнарын. Ә менә халкыбызның атаклы җырчысы Әлфия ханым Авзалованы мул сулы ярсу чишмәгә тиңләр идем. Иң беренче башкарган җыры «Кәккүк»тән алып хәзерге көндә җырлый торган «Картаямыни соң йөрәк»кә кадәр берничә буынны моң белән сугарды ул. Халык җырчысы Әлфия Авзалованың җыр чишмәсе бүген дә мөлдерәмә тулы.

Шушы көннәрдә шәһәребез мәдәният сарайларында барган концертларында да энә төртерлек урын юк. Чөнки халык Әлфиясен сагынган, сагынган гына түгел, ярата ул үз җырчысын. Күптән, бик күптән килгәне юк иде аның бу якларга. Бу юлы безгә кызы Зөлфия белән икәүләп килгәннәр.

Җыр һәм Әлфия. Сәхнә йолдызының бөтен гомере тоташ җыр. Шатлыгы да, хәсрәте дә сыйган аның бу җырга. «Җыр тормышта минем пар канатым булды. Рәхмәт сиңа, ЖЫР!» — ди ул бүген.

Мин җырлап уянам,
Гөлләргә күз салам...

Үзеңә мең-мең рәхмәт, милләтебез кызы Әлфия! Моң чишмәң ташып торсын...

*«Нур», Чаллы*
*19 май, 1990*

**АЛСУ КАДЫЙРОВА**

* * *

Аны халык кушаматы аша белә. Менә шул Әлфия Кәрименә дә инде 60 яшь тулган икән. 35 ел Әлфия Авзалова төркемендә музыкант булып эшләүче Кәрим Габидуллин җырчы белән бергә картайган түгелме соң? Шатлык-сөенечләрне, кайгы-сагышларны да бергә җиңә белгән тату гаилә кебек алар. Алар дигәнем өчәү: Әлфия апаның икенче тавышка җырлап торучысы Кәрим абыйның тормыш иптәше Сания ханым да бар әле.

Гадәттә, артист халкы гастрольдән бер-берсеннән тәмам туеп кайта. Ә Әлфия апа исә Кәрим белән Саниясез бер минут та тора алмый.

Кәрим абый кебек бер җырчыга гомер буе тугрылыклы музыкант юктыр ул. Бигрәк тә бүгенге заманда. Танылган бер эстрада җырчысының: «Кәрим кебек юләр бармы икән ул тагын, гомер буе Әлфиягә карап яшәде», — дигәне истә калган.

Юк, үкенми Кәрим абый. Үкенсә, Казанның ул вакытта бик тә дәрәҗәле саналган химия-технология институтын тәмамлап сәнгать өлкәсенә китәр идемени? Кечкенәдән баян белән җенләнгән Кәримне әтисенең, абыйсының киңәше дә туктатып кала алмый. Инженер булмый егет. Студентлар белән берлектә ансамбль оештырып җибәрә. Ул вакытта «соло» гитараның модага кергән чоры гына була әле. «Минем гитарага алданып күпме кызлар арттан йөгергәндер, белмим», — ди музыкант.

1969 елда София Ротару төркеме белән популяр «Каравелла» вокаль инструменталь ансамблендә дә эшләп ала әле ул. Әмма туган җир үзенә тарта икән шул. Кайтырга туры килә. Казанга «соло» гитаристы кайтуга, филармониягә чакырталар, музыкант Әлфия Авзалова төркемендә эшли башлый. Ул вакытта филармониядә танылган ике вокаль-инструменталь ансамбль генә була: берсе — Әлфия Авзалова җитәкләгән «Казан утлары», икенчесе — Илһам Шакировның «Идел»е.

Казан егете, шәһәрчә фырт киенеп, беренче гастрольгә чыгып китә. София Ротару төркемендәге кагыйдәләрне истә тотып, өстенә җиңелчә генә заманча костюм, аягына ялтырап торган ботинка кия Кәрим абый. Беренче гастроль Башкортстаннан алып Себер якларына кадәр була.

— Гомер онытасым юк, көчкә исән калдык, — дип искә ала Кәрим абый ул вакытны. — Авыл сәхнәсендә уйныйсымны белсәм, өстемә толып киеп барган булыр идем. Гастрольнең гүр газабы икәнен башыма да китермим бит. Яңавылдан концерт куеп кайтканда чыкты буран. Юл күренми, кар көрте каплап киткән. Тирә-юньдә бер йорт әсәре юк. Ул елларда йомырка дефицит вакыт. Уникe кешенең һәрберсенә 100 данә йомырка биргәннәр иде. Ит тә, бәрәңге дә бар. Калдырып китәсе килми бит теге әйберләрне. Мин: «Йомыркалар өшеп бетә, әрәм була бит», — дип кайгырам. Шофер егет: «Нинди йомырка ди инде монда, Кәрим, үзебез исән калсак ярый әле», — ди. 30 градус салкында икенче авылга җәяү көч-хәл белән барып җиттек. Чатнама суык дип тормадык, 104 концерт бирдек.

«Без Кәрим белән сәхнәдә үләргә сүз бирдек», — дип, Әлфия апа сәхнәдән еш әйтә. 35 ел гомер эчендә кайсы гына илләрдә йөрелмәгән дә нинди генә сәхнәләрдә җырланмаган. Бөтен Советлар Союзын әйләнеп чыккан алар. Алны-ялны белмичә, филармония дип янып-көеп йөргән Әлфия апа белән Кәрим абый кебекләрне көндез чыра яндырып эзләсәң дә табып булмастыр ул. Сер түгел, кайбер вакытта сәхнәне ташлап, сулагай кулын селтәп төшеп китәрдәй сүзләр дә ишетергә туры килә Кәрим абыйга. Баянчылар Әлфия апага килештереп уйнамаса да ул гаепле. «Ничек түзәсең, Кәрим?» — дип төрттереп куючылары да юк түгел. Әмма җырчының холкын ятлап бетергән инде музыкант.

— Алай үпкәли башласаң, бөтенләй эшләмәскә генә кирәк, — ди ул.

Кәрим абыйның Әлфия Авзаловага тугрылыклы калуы гомер буе үз тавышына, ягъни «тере» килеш җырлавыннан да килә.

— Үз тавышына җырлаган һәм җырлаучы бердәнбер сандугач ул безнең, — ди Кәрим абый. — Эшенә һәрвакыт җаваплы һәм сак карый торган җырчы. Аның өчен авыл яки шәһәр сәхнәсендә җырлауның аермасы юк. Репертуардагы җырларны бервакытта да кыскартмады. Авыл клубының тәрәзәсе ватык булса, тун киеп җырладык. Буран, салкын дип бер генә концертны да кичектермәдек. Хәтерлим әле, Башкортстанның бер авылына концерт куярга барабыз. Соңга калдык. Бердәнбер тиз баруның юлы — Агыйдел аша. Әмма боз әле тотрыклы түгел, бик юка. Тәвәккәлләдек тә, беткән баш беткән дип, елга аша чыгарга булдык. Әлфия апаның биленә бау бәйләп, ике кеше ике яктан аны тотып бара. Үзе елый, үзе үрмәли теге. Арттан боз чыртлап ярыла бара. Күргәннәрне сүз белән сөйләп кенә аңлатып булмастыр ул.

Әлфия апа Кәримсез бер генә концерт та уздырмый.

Шулай да җырчының бер гастроле музыкантсыз уза. Бәрәңге районына гастрольгә барганда юл һәлакәтенә очрыйлар. Кәрим абыйның шул вакытта сигез кабыргасы сына. Әлфия апага исә бернәрсә дә булмый, әмма гастрольләрен кичектерми. Музыкантсыз китәргә була.

Менә шуннан соң Әлфия Авзалова, Кәримсез гастрольгә китмим, дип, үз-үзенә сүз бирә. Кайбер вакытта башка җырчылар белән «кесә» ягын калынайтырга чыгып китәсе килгән чаклары да булгандыр Кәрим абыйның. Бүген музыкантларның һәрберсе диярлек шулай эшли. Аларның да бит гаилә туйдырасылары, әйбәт яшиселәре килә. Кәрим Габидуллинга да бу мәсьәләдә мөрәҗәгать иткәннәре бар. Әмма ул Әлфия Кәриме дигән кушаматына тугрылыклы калган музыкант.

— Элек бит 5–6 сумга да эшләп йөрдек, — ди ул. — Акчаның беркайчан да җитәсе юк инде аның.

Әлфия апа хастаханәдә үлем белән көрәшеп яткан авыр вакытларда да җырчының өметен сүндермәүче Кәрим абый була. «Аның яшәячәгенә әз генә дә шикләнмәдем. Әлфия апаның үзенә генә хас энергиясе бар аның. Авырып температурасы кырыкка җитсә дә, сәхнәгә чыгып басуга, икенче бер кешегә әйләнә дә куя. Безне дә шулай «авырмаска» өйрәтеп бетерде инде», — ди ул.

Гадәттә, музыкантларны, баянчыларны, җырчы артына күмелеп, «пәрдә» артында кала, диләр. Кәрим Габидуллин андый «ширма»га яшеренеп кала торганнардан түгел. Әлфия Авзалованың «озын гомерле» җырчы булуында аның да өлеше зур.

*1990*

**АЙРАТ АРСЛАНОВ**

# Татарның моңлы кәккүге

60 нчы еллар башында «Азат хатын» журналында дөнья күргән бер мәкаләсендә Татар дәүләт филармониясе лекторы Ф.Вәлиева җырчы Әлфия Авзалова турында түбәндәге юлларны яза:

«Моннан ике ел элек РСФСР күләмендә эстрада осталарына үткәрелгән конкурста Татар дәүләт филармониясеннән дә бер төркем артистлар катнаша. Алар арасында яшь җырчы Әлфия Авзалова да була. Озак та үтми, аны дуслары конкурста алган дипломы белән котлыйлар. Әлфия татар көйләреннән тыш башка халык көйләрен дә башкара: ул 15 телдә — һинд, гарәп, үзбәк, казах, азәрбайҗан һ.б. телләрдә җырлый.

Аның тавышы моңга баеганнан-байый бара. Халкының мәхәббәтен казанып өлгергән яшь җырчының көче күп, максаты ачык. Аның киләчәктә дә халык көйләре яратучыларга көтелмәгән куанычлар китерүенә чын күңелдән ышанабыз».

Әйе, Әлфия музыка сөючеләребезнең ышанычын, аңа багланган өметләрен тулысы белән аклады диясебез килә. 40 елга якын иҗат гомерен татар музыкаль культурасына багышлаган Татарстанның халык, РСФСРның атказанган артисты Ә.Авзалованың сәнгатьтәге юлы роза чәчәкләре белән генә түшәлгән туры юл булмый. Роза чәчәкләренең кулларны каната торган чәнечкеләрен дә татырга туры килгәндер җырчыга.

Әмма үзенең иҗат юлында очраган барлык авырлыкларны җиңеп, үз алдына сәнгать үрләренә менүгә зур максатлар куйган Әлфия, армый-талмый халкыбызга хезмәт итеп, татар эстрадасының сандугачы дәрәҗәсенә күтәрелә һәм инде менә дистәләгән еллар буена илебезнең күп төбәкләрендә яшәгән милләттәшләребезгә үзенең җырларын, моңын җиткерә һәм тамашачылар аңа рәхмәт йөзеннән кочак-кочак роза чәчәкләрен күпме бүләк иткәннәрдер, аларны санап чыгуы да мөмкин түгел. Зур сәнгатькә килгәнче Әлфиянең тормыш юлы җиңел булмый. Актаныш якларында ятимлектә үскән кыз бала җидееллык мәктәпне тәмамлагач та эшкә керә, үз көнен үзе күреп, тормышның ачысын-төчесен яшьтән үк татый, кызның тавышы да тирән моң белән сугарыла. Радиодан концертлар тыңлаганда да Әлфия еш кына онытылып-онытылып кала. Җырчылардан аңа иң ошаганы Гөлсем Сөләйманова була.

Әлфия үзе дә авыл клубларындагы кичәләрдә җырлый башлый. Бер генә үзешчән сәнгать коллективларының ярышы да аңардан башка үтми. Әлфиянең җырлавын халык яратып тыңлый. 1950 елда Актаныш районы күләмендә үткәрелгән ярышта ул беренче бүләкне ала. Җыр, сәнгать ярату Әлфияне 1951 елда Казанга алып килә. Күренекле музыка эшлеклесе, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленең сәнгать җитәкчесе Зөләйха Әхмәтова аны ансамбльгә эшкә ала, анда берничә ел солистка булып эшләгәч, ул Татар дәүләт филармониясенең эстрада бүлегенә эшкә күчә һәм үзенең бөтен иҗат эшчәнлеген татар эстрадасын үстерүгә һәм тагын да камилләштерүгә багышлый.

Әлфия Авзалова — үзенчәлекле җырчы. Аның башкару манерасы милли традицияләргә нигезләнгән. Үзеңнең талантыңа гына ышану җитмәвен ул яхшы аңлый, армый-талмый эшләргә, өлкән сәхнәдәшләреннән бу эшнең нечкәлекләренә өйрәнергә, сәхнәдә тотышыңны, зәвыгыңны, эчке культураны күтәрү зарурлыгын артистка озак еллар эшләү дәверендә кат-кат төшенә. Әлфия Авзалованы без беренче нәүбәттә татар халык җырларын, халкыбызның фольклор әсәрләреннән төзелгән программалар башкаручы буларак беләбез. Чыннан да, халкыбызның борынгы җырларын, бигрәк тә беркайчан да картаймый торган «Зөләйха», «Шахта», «Гөлҗамал», «Казан сөлгесе», С.Габәшинең «Кәккүк» романсы һ.б. көйләрне Әлфия Авзалова үзенә генә хас күңелгә ятышлы моң-бизәкләр кушып башкара.

Ул — шулай ук безнең мәшһүр композиторларыбыз С.Сәйдәшев, М.Мозаффаров, Җ.Фәйзи, А.Ключарев, Р.Яхин, С.Садыйкова, А.Монасыйпов, Ф.Әхмәтов әсәрләрен тыңлаучыларыбызга җиткерүдә зур хезмәт күрсәткән җырчыбыз. Шул ук вакытта аның яшь композиторларыбыз һәм үзешчән композиторлар, шагыйрьләребез арасында да дуслары күп. Миңа да, татар эстрадасында 50 нче еллардан бирле эшләүче буларак, төрле концерт бригадалары составында Ә.Авзалова белән илебезнең төрле өлкәләрендә, шәһәр һәм районнарында үткән күпсанлы концертларда катнашырга туры килде. Ул концертлар вакытында без тамашачыларның җырчыны көтеп алуларын, аны чын күңелдән ятатуларын һәм хөрмәт итүләрен күрә торган идек, Әлфия катнашкан концерт программалары зур уңыш белән үтә торган иде.

Ул елларда Ә.Авзалова Мәскәүдә дөнья халыкларының җырларын оста башкаручы СССРның халык артисты И.П.Яунземда укый, стажировка үтеп, дөнья халыклары җырларыннан матур программа әзерләп кайткан иде. Менә шул программаның студент яшьләр тарафыннан бик җылы каршылануы әле дә хәтеребездә.

Ә нигә 60 нчы еллар традициясен искә төшереп, профессиональ сәнгать осталары белән очрашулар, милли сәнгатебезнең төрле жанрларда эшләүче вәкилләре турында, гомумән, олы сәнгать тарихын искә

алу кичәләре оештыру турында уйлап карамаска? Минемчә, мондый очрашулар яшьләребездә сәнгатькә мәхәббәт уятуда уңышлы адым булыр иде.

Быел республикабызның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты исеменә кандидатлар исемлегендә халкыбызның яраткан җырчысы Әлфия Авзалова да бар. Ул бу бүләккә үзенең соңгы елларда башкарылган «Туган туфрак» һәм «Бер шатланам, бер моңланам» исемле концерт программалары өчен күрсәтелгән. Бу программалар тамашачылар тарафыннан бик җылы каршыланып, зур уңыш казандылар. Җырчы һаман иҗатта, юлда... Төрле өлкәләрдә һәм Татарстан районнарында аның гастрольләре дәвам итә.

*«Мәгърифәт»*
*Апрель (№ 11), 1992*

# «Очрашырбыз әле җыр аша...»

Бүгенге язмамда мин татар эстрадасының сандугачы саналган, халкымның яраткан җырчысы Әлфия ханым Авзалова турында үземнең кайбер фикерләремне әйтеп үтәргә булдым.

Әлфия Авзалова Татар дәүләт филармониясенә эшкә 50 нче еллар башында килде, ул башта Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә солистка булып эшләде.

50–60 нчы еллар, татар эстрадасы артистларына эшләү шартлары тудырылмаганлыктан, ифрат авыр иде. Ул елларны эшләү авырлыгы турында эстрадабызның йолдызлары Рәшит ага Ваһапов, Зифа Басыйрова, оста гармунчы Гани ага Вәлиев, Фәйзерахман ага Биккинин, Гали Җәмлихановлар үзләренең искә алуларында һәрвакыт ачынып сөйли торганнар иде.

Безнең өлкән артистларыбыз Фәйзи ага Йосыпов, Әзәл ага Яһүдин, Җәваһирә ханым Сәләховалар да тамашачылар белән очрашуларда булсын, газеталарда язылган истәлекләрендә Татарстанның иң ерак авылларына атларда, трактор чаналарында, ә кайбер кышкы көннәрдә җәяүләп барып, концерт хезмәте күрсәтүләрен сөйлиләр.

Әлфия ханым эстрадада менә шушы телгә алынган сәнгать осталары белән бергә эшли башлый. Җырчы һәрвакыт юлда, иҗатта.

— Кышкы буراннарда җигүле атта авылдан авылга, ә кайчакта җәяүләп тә дистәләрчә километр юл узган вакытлар булды, — дип искә ала Әлфия ханым. — Ягылмаган клуб сәхнәләренә аяк басуга, тамашачыларны күреп, юл газаплары тәмам онытыла. Кешеләргә кирәкле булуымны тою мине гомерем буена дәртләндерә.

Ул еллардагы концертлар Бәхти Гайсинның Әнгам Атнабаев сүзләренә язылган «Саубуллашу» җыры белән тәмамлана. Ул җырда «очрашырбыз әле җыр аша» дигән юллар бар. Тыңлаучылар җырны күтәреп алалар, җырчыга матур җырлары, моңнары өчен рәхмәтләр укыйлар, җырчы аларга тагын килергә вәгъдә бирә. Ул сүзендә тора. Еллар үтә, Әлфия Авзалова үзенең эстрада ансамбле белән шул ук маршрутлар буенча концертлар оештырырга килә. Һәр килүендә яңа программа әзерләнгән була.

40 елга якын иҗат гомерендә нинди исемнәрдә генә чыкмады ул концерт программалары.

Ә.Авзалованың репертуары, гомумән, татар халык фольклоры әсәрләре һәм хәзерге композиторларыбызның, яшьләрнең бүгенге уңышлы әсәрләре исәбенә баеп тора. Бу җырларның тематикасы бик бай — туган ил турындагы, хезмәт сөюче халкым улларына һәм кызларына багышланганнары, гражданлык пафосы белән тулы әсәрләре, мәхәббәткә багышланган лирик җырлары бар. Уфада гастрольләр вакытында Башкортстанның халык артисткасы Флера Нагумангованың: «Әлфия ханым, сезнең репертуарда дөньяда тынычлыкны саклау өчен көрәш темасына җырлар күп бугай?» — дип соравына җырчы болай дип җавап бирә: «Безнең чор кешеләренең бала чагын сугыш көйдерде. Ятимлекнең ни икәнен үз җилкәмдә татыдым. 4–5 яшьтә әтисез дә, әнисез дә калдым. Әмма илем, туган халкым ярдәменнән ташламады: белем бирде, һөнәрле итте. Сәнгать дөньясына кулымнан җитәкләп чыгарды. Җыр-моң өлкәсендәге хезмәтемне таныды. Иҗатым белән тынычлыкка, халыклар арасында дуслыкка хезмәт итәргә тырышам».

Чит ил халыкларының җырларын, аларны башкарудагы специфик үзенчәлекләрне өйрәнү өчен 60 нчы елларда Әлфия Мәскәүгә, дөнья халыкларының җырларын оста башкаручы И.П.Яунземга укырга бара. Укудан соң дөньяның күп халыклары җырларын туплаган яңа концерт программалары туа. Корея, кытай, гарәп, һинд, индонезия, фарсы һ.б. халыклар җырларын пропагандалаганы өчен артистка Тынычлыкны яклау буенча Совет комитетының мактау грамотасы белән бүләкләнә. Ул шулай ук зур осталык белән үзбәк, азәрбайҗан, каракалпак, башкорт җырларын башкара һәм тыңлаучыларның күңелендә онытылмас эзләр калдыра.

Җырчының озын иҗат гомерен күз алдыннан кичерәсең дә уйланырга мәҗбүр буласың. Нишләп әле Татарстанның моңлы кәккүге саналган Әлфиябез шушы көнгә кадәр сәнгать әһелләренә бирелә торган дәүләт бүләгенә бер дә күтәрелмәгән, ул аңа лаек түгелмени яисә җырчы яшьрәк вакытында М.Җәлил исемендәге бүләккә дә лаеклы табылмаган?

Торгынлык чорының талант ияләренә илтифатсыз карау чиреме, әллә безнең Татарстан филармониясе сәнгать җитәкчелегенең битарафлыгы һәм иҗат көчләренә карата үтә дә ваемсызлыгымы? Минемчә, биредә ике фактор да урын ала торгандыр.

Ә җырчы һаман үзенең иҗат эшен дәвам итә, республикабыз һәм башка өлкәләрдә гастрольләрдә йөри.

Ә.Авзалова турындагы язмамны Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, күренекле шагыйрәбез Гөлшат Зәйнашева сүзләре белән тәмамлыйсы килә: «Үзешчән сәхнәдән зур профессиональ сәхнәгә күтәрелгән Әлфиянең бөтен иҗатын күздән кичереп уйласаң, шундый нәтиҗәгә киләсең: туган илгә, туган халкыбызга чын күңелдән бирелеп хезмәт иткән Әлфия — мәхәббәт һәм дуслык җырчысы ул. Үз җырларында ул кеше йөрәгенең иң нечкә кичерешләрен чагылдыра. Аның җырлары туган җиренә бирелгәнлек, халыклар дуслыгы, тынычлык турында зур һәм җитди сөйләшү булып яңгырыйлар».

*«Татарстан хәбәрләре»*

*18 април, 1992*

**ГӨЛШАТ ЗӘЙНАШЕВА**

# Халкыбызның сөекле кызы

Татар эстрада сәнгатендә Әлфия кебек 40 елдан артык сәхнәдән төшмичә, һаман әле концертына шыгрым тулып килгән тамашачыларның мәхәббәтен яулаган башка җырчы-артистка юк. «Сәхнәдән төшмәү» хикмәтле сүз ул. Сәхнәдән төшмәүчеләр булгалый. Әйтик, кайберәүләр инде тамашачылар теләмәсә дә, әйтер сүзе, тыңлатыр моңы калмаса да — сәхнәдә. Андый җырчыларның концертына тамашачы килми, әллә нинди афишалар чыгарып элсәң дә, бушлай чакырсаң да килми, вәссәлам!.. Бу инде чын-чынлап сәхнәдән төшү дигән сүз. Аяусыз һәм катгый сүз.

Ә Әлфиябез һаман сәхнәдә, аның концертларында заллар һаман шыгрым тулы, кая гына бармасын, аны көтеп алалар, концертларына бик теләп киләләр һәм аны кайнар алкышларга, чәчәкләргә күмәләр. Бу инде халык мәхәббәтенең һаман сүрелмәве, җырчыны яратуның иң аңлаешлы дәлиле. Халыкның шулай сүнмәс мәхәббәтенең берәр сере бармы әллә?

Бер генә түгел, аның серләре күп. Әлфия Авзалованың иҗаты туган халкыбызга, туган җиребезгә тирән мәхәббәт белән сугарылган. Аның җырлары, моңнары тамырлары белән халкыбыз күңеленә тоташкан. Ул җырларда, ул моңнарда халкыбызның уй-кичерешләре, өмет-шатлыклары, кайгы-сагышлары, үткәне-киләчәге. Ул җырларда, ул моңнарда туган җиребезнең сулышы, туган туфрагыбызның бәрәкәтле дымы, туган як чишмәләренең шифалы су тәме, урман-болыннарында сайраган сандугачлары, кәккүкләренең үзәк өзгеч аһәңнәре. Әлфия Авзалова тумыштан җырчы, табигый талант. Күренекле композитор А.Ключарев әйтә торган иде: «Әлфия бит ул Актаныш туфрагыннан табылган самородок!» Самородок дип рус халкы җирдән табылган кыйммәтле хәзинәне атый. Халкыбыз өчен хәзинә, табигать бүләге ул. Мәктәпләрдә нота өйрәнеп кенә, китаплардан укып кына җырчы булып китмәгән, җырчы булып туган. Әлбәттә, сугыш алды елларында дөньяга килеп, илебез кичергән иң авыр елларда үсеп буйга җиткән бик күпләргә хас булганча, Әлфиягә адәм рәтле укып, зур белемнәр алырга, бигрәк тә музыкаль белем алырга бернинди шартлар да, мөмкинлекләр дә булмый. Әмма ул бик зур тырышлык куеп, үзлегеннән өйрәнеп, үзенә кирәкле музыкаль белемне ала, нотасын да үзләштерә.

Тырышлык турында сүз башласаң, Әлфиянең тырышлыгына исең китәр. Ул башлаган эшен ахырынача төгәлләмичә туктамый торган гаҗәп эшчән, тырыш кеше. Яңа программа әзерли башласа, яңа җыр өйрәнә башласа, сәгатьләр белән исәпләшми, көнне төнгә ялгап эшли. Җыр өйрәнгәндә аңа махсус репетиция бүлмәсе кирәкми. Күңелен биләп алган матур җыр тапса, ул аны гастрольдә йөргәндә дә, юлда баргандa да өйрәнә һәм репертуарына кертә. Туктаусыз эзләнү, яңа җырлар өйрәнү, үз өстендә эшләү, ирешкән уңышлар белән тынычланып калмау — Әлфиянең иҗат принциплары. Хәзерге иҗат кешесе әз генә тынычланып, үз уңышларыннан башы әйләнеп йөри башлады исә, хәзер артка кала. Заман ритмы, заман сулышы иҗат кешесеннән туктаусыз эзләнү, туктаусыз яну, дөрләү таләп итә.

Әлфия — янып-дөрләп иҗат итүче ул. Кулына берәр матур шигырь керсә, композитор янына килеп, тын да алырга ирек бирмичә, аңардан шул шигырьгә музыка язуын үтенә, сорый, таләп итә. Кайвакыт хәтта, миңа шушындыйрак көй булсын иде, дип, булачак җырның көен үзе көйләп тә күрсәтә. Мәрхүмә Сара апа Садыйкова белән бер очрашуында ул: «Сара апа, миңа шушындыйрак көй язмассызмы миңа?» — дип, үзе көйләп-көйләп утырган иде. Ниһаять, Сара апа, аның көйләүләрен исәпкә алып, «Чит илләргә чыксаң» дип аталган бик матур җыр язды (И.Юзеев сүзләренә). Әлфия Авзалова һәр җырны бер вакыйга, бер күренеш итеп тасвирлап җырлый. Җырның эчке асылын ача, аңа җан кертә. Театр белгечләре мондый иҗатка карата артистның образга керүе диләр.

Мин инде Әлфияне якыннан 30–40 ел беләм, аның бөтен сәхнә юлы, иҗат эшләре минем күз алдымда узды, мин аның өчен махсус күп кенә җырлар да яздым. Бик күп җырларының ничек язылуы, ничек дөньяга килүе, ничек сәхнәдә яңгырап китүе, ничек озак еллар репертуарында саклануы — барысы, барысы миңа бик таныш дисәм, газета укучыларга бу мактану кебек тоела күрмәсен. Юк, бу мактану түгел, бу безнең эшебезнең киңәшле булуын әйтү генә. Бу — иҗатта дуслык кына. Шушындый дуслыгыбыздан чыгып та мин бүген Әлфия турында, аның иҗатына хас үзенчәлекләре хакына җыр сөючеләребезгә сөйләргә хаклымындыр дип уйлыйм. Образга керү шулкадәр хас аңар, хәтта әле композитор һәм шагыйрь язмаган, язарга уйлаган гына җырны да, нәрсә турында сүз барачагын аңлау белән Әлфия инде образга керә, «миңа шушылай җырлар идем» дип, матур бер көй көйли башлый, мөлаем бер лирик халәткә керә.

Композитор Илгиз Мәҗитов белән без Әлфиянең шулай «юк җырны җырлап» безнең каршыбызда рояль янында сөйкемле чыгышын күреп исебез киткән иде. Композитор, шагыйрь, җырчы — җырның өч авторы. Әлфия кебек җырчылар гына шулай өченче автор — композитор һәм шагыйрьнең чын иҗатташы була ала.

Табигый тавышны Әлфия Авзаловага Ходай бөтен тулылыгы белән мул итеп биргән. Артык калын да түгел, артык нечкә, чәрелдәвек тә түгел, йомшак, шул ук вакытта көчле, яңгыравыклы, төрле төсмерләргә

бай халыкчан матур тавыш, киң сулыш, бик сизгер музыкаль ишетү сәләте, килешле буй-сын, ягымлы йөз аның җырчы булыр өчен генә туганлыгын раслый шикелле.

Әлфия Авзалова композиторлар әсәрләрен дә, халык көйләрен дә бердәй осталык белән башкара. Ул С.Сәйдәшев, М.Мозаффаров, А.Ключарев, И.Мәҗитов, Ж.Фәйзи, Р.Яхин, С.Садыйкова, Ф.Әхмәдиев, З.Гыйбадуллин, М.Имашев, С.Хәбибуллин һәм башка композиторларның әсәрләрен яратып башкара. Шулай ук башкорт һәм башка халыкларның җырларын да репертуарыннан төшерми. Әлфия үз гомерендә җырлаган җырларның исемлеген төзесәң, ничә йөзгә җыела икән?

Иң матур җырларын, халык арасында популяр булып, күңелләрдән күңелләргә, телдән телгә күчеп җырланып йөри торган берничә җырын әйтми китеп булмый: «Кәккүк», «Гөлҗамал», «Шәл бәйләдем», «Актаныш таңнары», «Кайтам инде», «Яшь гомер», «Күл буена килсәң иде», «Мәхәббәтем», «Яшь нарат-лар», «Туган авылым», «Йөрәк сере», «Шахта», «Сөясеңме дип ник сорыйсың?», «Кукмара», «Бик сагын-дым, авылым», «Җәйләүләрдә тугай» һ.б. шундый җырлар.

Әлфия Авзалова үзенең сәхнә эшчәнлеген Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә башлап җибәрде, аннары үзенә аерым эстрада группасы төзеп, чыгышлар ясый башлады. Татар сәхнәсендә беренче булып инструменталь ансамбльгә кушылып, эстрадача җырлау сәнгатен башлап җибәрде һәм татар эстрадасы-ның якты йолдызына әверелде. Әлфия Авзалова чыгыш ясамаган берәр сәхнә бар микән безнең татар яшә-гән киң илебездә?! Үз гомерендә аның авырып торганда да концертын өзгәне юк. Филармония планнарын арттырып үти-үти ничә мең концерт бирде икән ул?! Әлфия — Татарстанның халык, Русиянең атказанган артисткасы.

*«Шәһри Казан»*
*10 апрель, 1992*

**С.ГАЛИЕВА**

# Голос, трогающий душу

Альфия Авзалова — бесспорно, яркое явление в татарском исполнительском искусстве последних двадцати лет.

Известность и любовь народа принесли Альфие исполнение народных песен. В них она нашла полнейшее применение своему артистизму и вокальным данным, как будто созданным для виртуозного преодоления всех технических и образных трудностей татарских песен. А ведь для этого недостаточно иметь очень хорошее дыхание и природную гибкость голоса. Альфие известен один маленький секрет, без которого самое блестящее исполнение оборачивается профанацией народного искусства. По-татарски он называется непереводным словом «моң», приблизительно означающим особую, берущую за сердце трепетность, национальную специфичность исполнения.

Мы встретились с Альфией Авзаловной Авзаловой, народной артисткой ТАССР, после репетиции. Беседовать с ней увлекательно, но нелегко. Импульсивность ее натуры проявляется и в том, что при разговоре ее мысли как бы перебивают друг друга, создавая некоторую непоследовательность рассказа. Все в ней чуждо бесстрастной пунктуальности, подчинено стихийному порыву, эмоционально окрашено. Увлекаясь, она начинает говорить горячо и быстро. В разговоре ее голос звучит гортанно, чуть хрипловато.

Мы попросили Альфию рассказать, как начинался ее путь в искусстве.

— Когда еще училась в 4-м или 5-м классе сельской школы, я страстно увлеклась театром и частенько играла в школьных спектаклях. Выросла сиротой, и меня не водили, нарядную, смотреть выступления приезжих драматических актеров — в клуб проникала украдкой. И тогда же дала себе слово — стать актрисой драматического театра. А песня?.. Конечно, в то время я уже пела, вскоре стала выступать, но... ведь пели все, с песней тесно переплетались дни в колхозе. А в театральных спектаклях я увидела сказку, что-то чудесное, не имеющее отношения к будням. Это был праздник, мечта, манившая меня из деревни в город, в Казань.

И вот однажды, услышав мое пение, Камалеев, тогда первый секретарь Актанышского райкома партии, сказал: «Альфия, все, к чему ты стремишься, тебе даст твой голос». И в 1951 году меня направили в Казань.

После года работы в ансамбле песни и пляски ТАССР Альфия стала заниматься в музыкальном училище, но вскоре вернулась в ансамбль. По мнению Авзаловой, певице с «народным» голосом (о таком голосе говорят: не высокий и не низкий) весьма небезопасно обучаться в классе колоратурного сопрано.

— Учителей у меня, по существу, не было, — продолжает певица свой рассказ. — До всего доходила сама. Вначале пела «горлом», перегружала голосовые связки и быстро уставала. Очень помогло слушание известных певцов. Думала, анализировала. С годами пришло понимание тонкостей вокального исполнения. Теперь, даже если даю по три концерта в день, пою легко, с удовольствием — и никогда не устаю.

Авзалова в совершенстве владеет трогательным, трепетным «тихим» пением, требующим большого технического мастерства.

— Певица должна любить природу, — убежденно говорит Альфия. — Я хорошо знаю нашу лесную кукушку и в романсе Султана Габаши «Кукушка» просто стараюсь точно передать ее кукование. Типичная орнаментика народных песен, я думаю, очень близка в своих истоках к природе, как бы вырастает из нее, и поэтому задача певца — максимально приблизиться к постижению этой основы фольклора.

Обычно я волнуюсь, выходя к зрителю. Но начала петь — и уже вокруг никого нет, я остаюсь наедине с песней. Очень много зависит от аккомпаниатора: все будет хорошо, если он даст вступление «от души», свободно, уверенно, а в шуточной песне — с огнем (очень люблю шуточные быстрые песни — так и хочется плясать).

Певице часто говорят, что ее исполнение актерски богато, — это потому, что она полностью входит в образ, и в этом ей помогают слова песни.

— Чем показывать «звучок», лучше полнее передать содержание песни, рассказывать напевая, ведь в народной песне особенно важны слова.

— Альфия, Вы почти не бываете в Казани, все больше в дороге, на гастролях. Когда Вы успеваете работать?

— Как раз чаще всего в пути. Когда едешь в поезде, сидишь в аэропортах (иногда по двое суток!). Поездки — это время отработки новой программы, обдумывания, работы над мелодией, словом. Я считаю, что поющим народные песни надо много работать над ритмом. — В ответ на мой удивленный взгляд Альфия поясняет: — Мы привыкли к ритмической свободе, поэтому я постоянно воюю с ритмом: считаю, когда сижу в аэропорту, считаю, когда засыпаю, — одним словом, живу ритмами своих песен.

— Но сложнейшим импровизационным ритмом протяжных песен Вы владеете в совершенстве...

— Я говорю о ритмах современных песен, которые я тоже очень люблю исполнять. К сожалению, многие новые песни оказываются недолговечными, и причина часто не в них самих, а в нас, певцах: иногда с таким трудом сделаешь песню «своей», но стоит один раз исполнить, как уже закружилась шарманка исполнений-близнецов. В результате получается то, что называется «перекормили слушателя».

— А как принимает молодежь старинные песни?

— Не буду приукрашивать: слушают часто очень внимательно, но потрясены, тронуты бывают редко. Музыкальные вкусы стали проще, примитивнее, что ли. Молодежь часто не понимает тонкостей — ритмических, образных, музыкальных — народной песни, отвыкла от неспешного течения музыки. В этом сказывается влияние музыки Запада, с ее часто жесткими, однообразными ритмами.

— Нельзя ли тогда подвергнуть старинные напевы обработке, сделать их доступнее?

— Осовремениванию поддаются только быстрые напевы, их аранжировками занимается руководитель ансамбля «Огни Казани» Карим Габидуллин. Но и мы ему помогаем, подсказываем новые характерные детали. Так, в дореволюционной песне «Эй, друзья!» я предложила тянуть вступительное «эй!» целую минуту — это действует на публику зажигающе: и стар и млад начинают подпевать.

Альфия первой в Казани создала свой ансамбль. Его еще называют эстрадной бригадой Альфии Авзаловой. Потом с эстрадным ансамблем стал выступать Ильхам Шакиров и другие певцы.

Я спросила у Альфии, не хочет ли она создать концерт как единое целое, своего рода спектакль одного певца.

— О, это было бы исполнением моих творческих чаяний! Но я мыслю себе такое музыкально-песенное театрализованное представление в содружестве с чтецами и другими артистами. Конечно, это возможно только при содействии композиторов и поэтов.

Недавно певица вернулась с больших гастролей в Москве, где она записала пластинку с новыми песнями. В будущем году планирует записать с оркестром фирмы «Мелодия» песни Р.Яхина, Б.Мулюкова, А.Монасыпова.

После серии октябрьских концертов в Казани Альфию Авзалову ожидает двухмесячное турне по городам Нижнего Поволжья, Киргизии, Таджикистана. Артистка полна новых творческих сил и замыслов.

*«Вечерняя Казань»*
*1981, 5 ноября*

**ФЛОРА АХМЕТОВА-УРМАНЧЕ**

# Народная артистка

Как-то я получила приглашение на так называемые Мензелинские вечера. Они стали традиционными, до нас в гостях у мензелинцев уже побывали композитор Ф.Ахметов, писатель М.Магдеев и другие известные в республике творческие личности. Приближалось 8 Марта, поэтому состав нашей творческой группы был в основном женский: поэтесса Э.Шарифуллина, композитор М.Шамсутдинова, звезда телеэкрана Ф.Хакимова и я как ученый-фольклорист, и вдова Баки Урманче. Узнав, что по пути к нам присоединится народная артистка Татарстана Альфия Авзалова, я очень обрадовалась, так как вот уже почти тридцать лет являюсь большой почитательницей ее таланта. А вот познакомиться с ней до сих пор так и не доводилось. До Мензелинска езды более шести часов, и я надеялась за это время о многом расспросить Альфию ханум...

Мензелинск мне понравился, он чем-то напоминает город моей юности — Тобольск. А когда на концерте преподаватели местной музыкальной школы исполнили дуэт Лизы и Полины из «Пиковой дамы», перед моим взором встал незабвенный образ моей учительницы пения Нины Андреевны Филипович, ссыльной женщины, некогда обучавшейся музыке в Италии, кстати, племянницы В.И.Немировича-Данченко. Одной из ее учениц была народная артистка СССР Наталья Шпиллер.

Тогда на концерте я подумала: «Вот бы и нашим татарским певцам такого педагога, как Нина Андреевна». Она, между прочим, очень любила татарскую музыку и хорошо разбиралась в ней. После того как одна наша певица, воспользовашись уроками Н.А.Филипович, исполнила романс Р.Яхина на стихи Г.Тукая «Кто оценит тебя?», более прекрасного исполнения этого шедевра я не слышала...

Сравниться с тем впечатлением может разве что «Кукушка» в исполнении А.Авзаловой. Эта мелодия С.Габаши сопутствовала ей почти всю творческую жизнь. Впервые она исполнила ее, будучи солисткой Государственного ансамбля татарской песни и пляски. И по мере того как совершенствовалось вокальное мастерство певицы, ее «Кукушка» приобретала ту особую мелодичность, для определения которой в татарском языке есть трудно переводимое слово «моң».

В Мензелинске, когда подошла очередь Альфии ханум выйти на сцену, среди прочих песен она исполнила русскую народную «Волга-реченька». Я запомнила каждое слово этой песни. Правда, это милый моему сердцу фольклор, который всегда легко заучивается. Но было что-то еще в самом пении Авзаловой, от чего песня входила в душу сразу и навсегда. Это был театр в миниатюре, своего рода трагический монолог, плач о многих и многих, кому не улыбнулось счастье, кто покинут своими любимыми. В пении Авзаловой слышались и неизбывная боль, и гордое, мудрое смирение перед своей судьбой...

Я спросила Альфию ханум, как ей удается одинаково проникновенно петь не только татарские, но и русские, еврейские, узбекские, цыганские песни.

— Для меня это давно стало правилом, — ответила певица. — В Баку я пою «Сурею». В Ташкенте — «Яр-яр» или «Наманганские яблоки». После этого слушатели и мои родные татарские песни принимают ближе к сердцу.

На ее концерты в Москву, Ленинград и другие города приезжают татары из-за рубежа. Ей самой Госконцерт ни разу не предоставил возможность выехать с концертами за рубеж. Почему? Разве это объяснить теперь?.. Но она не обиделась, и из гордости, а вернее, «гарьлек» (еще одно непереводимое татарское слово) туристом объездила почти полмира, побывала в Турции, Греции, Нидерландах и т.д. Самый ценный багаж, который она везла оттуда, были новые песни.

— Кстати, Альфия ханум, почему Вы не исполняете со сцены столь модные в последнее время мунаджаты, баиты?

— Я с трудом себе это представляю. Перед моим мысленным взором всегда моя бабушка в белом платочке с книгой в руках, читающая «Бэдэвам», «Мухаммадию», «Сак-Сок» и другие мунаджаты. Для меня выйти с ними на сцену значит разрушить этот образ.

Альфия рано осиротела, отец погиб на войне, мать она потеряла в пять лет. Ее и сестру воспитала тетя, которую они называли «эби» — бабушка. А когда и ту засадили в тюрьму за пригоршню зерна, якобы унесенного с поля, пришлось скитаться по детдомам. А позже, кроме своих двух дочерей, ей пришлось приглядывать и за детьми рано умершей сестры, достойно проводить в мир иной и любимую тетю... Жизнь ее никогда не баловала.

О многом успели мы поговорить во время мензелинской поездки. В тряском автобусе с ее слов я записывала дивные образцы татарского фольклора, которые она знает во множестве.

Альфия Авзалова в полном смысле слова народная артистка.

*«Советская Татария»*
*1992, 23 апреля*

**РӘШИТ САБИРОВ**

# Аны халык үзе үстерде...

Гадәттә тәсбих төймәләрен дога укый-укый берәм-берәм тарталар. Һәр 33 төймәдән соң куела торган, бер төр догадан икенчесенә күчүне белдергән зур төймәне тәсбих анасы диләр. Мин бүгенге җыр сәнгатендәге артистларны шушы тәсбихка охшатам. Берсеннән-берсе матур тавыш тембрына, башкару осталыгына, моңга ия булган бик күп яшь җырчыларыбыз бар бит әле безнең. Һәм алар арасында бөтен осталыгы белән аерылып торган «тәсбих анасы» — күренекле җырчыбыз Әлфия Авзалова да бар. Яшь җырчыларыбыз көндәлек матбугат битләрендә басылып чыккан бик күп мәкаләләрендә үзләренең беренче укытучылары итеп Әлфия Авзалованы яки Илһам Шакировны атыйлар, гәрчә алар уку йортларында дәресләр бирмәсәләр дә. Бу ике зур шәхеснең моңнары, осталыклары тәэсирендә бик күп сәләтле яшьләребез үсеп чыкты. Җырчыларыбызның барысына да диярлек Әлфия Авзалова белән Илһам Шакиров, уку дәреслеге шикелле, җыр сәнгатенең башлангыч һәм эзләнү чорында гомер буена кулланма булып килделәр. Алар, җыр сәнгатендә икесе бер пар ат булып, төпкә җигелеп тарттылар. Милләтебезнең йөзек кашлары булган бу ике җырчы бер чорда эшли башладылар һәм бүген дә дәртләнеп иҗат итәләр.

Әлфия Авзалова үз концерт бригадасы белән чыгыш ясамаган бер генә авыл, бер генә шәһәр дә калмагандыр. Бүген дә ул юлда, бүген дә ул халкыбызга шатлык өләшә. Әлфия Авзалованың артистлык тормышы 1952 елда Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә башланды. Кая гына барса да, ул татар сәнгатенең илчесе булды. Бөтен дөньяда яшәүче татарлардан аның исемен белмәүчеләр юктыр, мөгаен.

Әлфия Авзалова гомере буена татар халкының йолаларына, традицияләренә турылыклы булып, мәңгелек темаларны яктыртты. Аның репертуарындагы җырларда туган якка, ата белән анага мәхәббәт, гомер һәм яшәү мәгънәсе бер җепкә тезелеп бардылар. Аның репертуарында һәркемнең күңелен тетрәндерә торган, бернинди сыйнфый катламнарга бүленми торган мәңгелек кыйммәтләр бар. Аның җырлары яшәргә көч бирәләр, иң авыр минутларда күңелләргә канат куялар. Әлфия Авзалова үзен һәрвакыт иркен тота, халыкның эчке ихтыяҗларына, рухи халәтенә юл сыза, халык белән уртак телне тиз таба белә. Шуңа да ул озын гомерле җырчы. Әлфия дигән исеме үзе үк «меңьяшәр кыз» дигән мәгънәне аңлата.

Аның тагын бер сыйфаты бар. Ул башка милләт җырларын да гаять зур осталык белән башкара. Аның «Дөнья халыклары җырлары» исемле концерт программасы белән чыгышлар ясавы яки һәр концертта диярлек үзбәк, азәрбайҗан, гарәп, һинд, башкорт, болгар һ.б. халык җырларын башкаруы милләтләрне туганлаштыруга керткән өлеше итеп кабул ителә. Мәсәлән, «Әниемә» исемле казах җыры белән Әлфия Авзалова иксез-чиксез дала баласының дала кебек киң хисләрен кояш биеклегенә күтәреп безгә китереп җиткерде. Шушы җыр белән ул анага булган мәхәббәтне тагын да югарырак күтәрде. Шулай итеп, ана темасын популярлаштыручы да булды.

С.Сәйдәшев, М.Мозаффаров, Р.Яхин, А.Ключарев, С.Садыйкова, А.Монасыйпов кебек күренекле композиторларыбызның әсәрләре белән бергә, үзешчән композиторларыбызның әсәрләрен дә халыкка җиткерүче булып торды һәм шулай булып кала да. Аның йөрәккә үтеп керерлек итеп җырлаган «Зөләйха», «Гөлҗамал», «Казан сөлгесе», «Шахта», «Кәккүк» һ.б. әсәрләре халык күңелендә юылмас эзләр калдырды.

Оптимистик рухлы җырчыбыз Әлфия Авзалованың тагын бер иң зур һәм иң кыйммәтле сыйфатын — кешелеклелеген әйтми китү мөмкин түгел. Үзенең башыннан күп авырлыклар, ятимлек, ачлык, ялангачлык, хәерчелек кичергәнгә күрәдерме, ул яшь артистларга җаны-тәне белән ярдәм итүче булды. Кешеләргә һәр яктан ярдәм итү сыйфаты аның канына сеңгән.

Татарлар яши торган араларны бергә кушкан, сәнгать күгендә якты йолдыз булып калыккан олы шәхесебез Әлфия Авзалованы халык үзе үстерде. Ул да үз чиратында халыкка турылыклы булып, гомерен туган халкына багышлады.

**ИЛҺАМ ШАКИРОВ**

# Күгебездәге якты йолдыз

Безнең татарда халык бәгыренә әверелгән талантлы шәхесләр байтак. Кол Гали, Мөхәммәдъяр, Г.Тукай, Г.Исхакый, С.Сәйдәшев... Мин әле иң якты йолдызларны гына — әллә нинди афәтләр дә сүндерә алмаган йолдызларны гына атадым. Әлеге йолдызлар яңа йолдызларны кабызалар, һәм, әлбәттә, шул хисапка үзләренең дә балкышлары көчәйгәннән-көчәя.

Иң якты йолдызлардан яралган, үзе дә сәхнә йолдызына әверелгән Әлфия Авзалова бар. Әлфия үз талантын ил-халык язмышы белән бәйләде. Хәзер инде татар тарихын Әлфия Авзаловадан башка күз алдына китерүе дә кыен. Аның турында уйланганда, шагыйрь Равил Фәйзуллин сүзләре искә төшә:

Холкыбызмы шундый: без, эш узгач,
Әй үксибез тәүбә иткәндәй.
Ә эчебез поша исән чакта
Берәребез гөрләп үскәнгә...

Шагыйрь хаклы. Хөрмәтле композиторыбыз Сара апа Садыйкованы үзе вафат булгач кына Г.Тукай бүләгенә тәкъдим иттеләр. Шул чакта мин болайрак язган идем: татар акылы төштән соң, үзе исән чакта кадерен белеп бетермәдек, инде гөнаһыбызны юыйк, аның якты рухы алдында акланыйк һәм пакьләник, дигән идем. Үзе исән чакта иҗатына тиешле бәясен ала алмаучылар арасында Сара Садыйкова ялгызы түгел...

Татар дәүләт филармониясенең гомуми җыелышында Әлфия Авзалованы Г.Тукай бүләгенә кандидат итеп күрсәтергә дигән тәкъдим булгач, бөтен зал бердәм «аһ» итеп куйды, бераз өнсез торганнан соң, тыела алмый дәррәү кул чаба башладылар. Нигә бу шулай яшен суккандай тәэсир итте соң әле? Сәбәбе ачык: һәркемнең башыннан бер уй йөгереп узгандыр: «Ни өчен соң әле без бу хакта моңарчы уйламаганбыз, әллә кайчан булырга тиешле ич бу?!»

Шагыйрь хаклы. Мең мәртәбә хаклы. Адәм баласының үзе исән чакта ук иҗатына тиешле бәя бирелмәүне безнең сукырлыкка яки чукраклыкка гына сылтау дөрес түгелдер... Моның төбендә көнчелек дигән әшәке гадәт ятмыймы икән? Мөгаен...

Әлфиянең иҗаты хакында кайта-кайта уйланам.

Аның язмышы да Тукайныкы кебек диярлек бит әле. Сабый чакта ук әнкәсеннән, аннары әткәсеннән ятим калып йә ерак туганнарына елыша, йә балалар йортына эләгә, яки ятлар почмагына сыена, яки бөтенләй урамда кала. Урамда калудан да читене юк. Өйдән өйгә хәер эстәп, төн уртасында далада калып, кая барырга, кая керергә белмәгәч, сүнгән учакның җылы көленә ятып йоклаулар дисеңме... Иртән, яктыра башлауга, Әлфия тагын юлын дәвам итә.

Сәнгать дөньясына шундый урау юллардан килсә дә, Әлфия җыр сәнгатенә ятимлек тойгысы алып килмәде. Киресенчә, аның җырларын тыңлаганнан соң кешенең дәрте-дәрманы арта, яшәүгә ышанычы ныгый, иманы камилләшә. Бары тик кешене уйландыра торган, әйбәт фикер уята торган җырларны гына халыкка җиткерергә тырышты ул. Үземнең дә башымнан кичкән хәлләр: кайчакта янасың-көясең, төннәр йокысыз үтә, күңелдә ачу, үпкә, рәнҗү, аерым кешеләргә генә түгел, хәтта халыкка рәнҗисең... Әмма ул үпкә-рәнҗүләрне башкаларга да таратып йөрергә безнең хакыбыз юк! Сәхнәгә — тамашачы каршына — якты йөз, пакь күңел белән чыгарга кирәк. Безгә Ходай шулай язган. Әлфия дә сәнгать дөньясына шундый иман белән килде, шул иманына тугры булып калды.

Бүләккә тәкъдим иткәндә «ниндидер аерым хезмәт өчен булырга тиеш» дигән фикер йөри. Әлфия Авзалованың хезмәте ни дәрәҗәдә? Әйе, ул моңләгән җыр башкарды, ул башкарган җырларны миллионлаган кешеләр отып алды, күңеленнән кабатлады. Җырлый башлап, карыны белән кар ярып, борыны белән боз ярып, нинди газаплар белән һәр төбәккә моңыбызны, милли сәнгатебезне илткәне өчен генә дә без аңа рәхмәтле булырга тиешбез. Әлфиянең хезмәте аның белән генә тәмамланмый әле. Үзеннән соң килгән уннарча җырчыга юл күрсәтүе дә зур каһарманлык, олы хезмәт дияр идем мин. Бу хезмәтне күрмәү — надanлык, күрергә теләмәү — гөнаһ.

Хәер, без хәзер гөнаһ эшләүдән курыкмыйбыз инде. Берәр талант борын төртүгә, аның хакында гайбәт куера башлый. «Ул фәлән икән, ул төгән икән...» Күренекле шәхесләрнең ашау-эчүен, гаилә хәлен тикшерү бездә бер гадәткә әйләнеп бара... Адәм баласы хатадан хали түгел, сәнгать кешеләре дә адәм балалары. Әмма кеше хакында — дөресме ул, түгелме — гайбәт таратып йөрү зур гөнаһ. Әлфия тирәсендә дә гайбәт аз булмады... Аның әледән-әле кабатлый торган зары бар: «Без бит, — ди ул, — диварга — өскә менәргә азапланган бөҗәк кебек идек. Әзрәк үрмәлибез дә егылып төшәбез, тагын тырыша-тырмаша үрмәли башлыйбыз... Шунда, ичмасам, берәр булышучы табылса икән...» Кая ул булышу! Сәхнәгә чыгудан ваз кичтермәсәләр, рәхмәт әйтерсең инде...

Әлфия белән без җыр сәнгатенә бер чорда килдек, бергә иҗат иттек. Җырларны үзе тапты (шагыйренә әйтеп яздырды, композиторына көйләп күрсәтте), үзенчә, бары тик үзенчә генә башкарды, һәр җыры халык күңеленә барып җитте. Әлфия туган халкын — татар халкын яратты, үзен дә яраттыра алды. Әлфия фәкать кул чаптыру уе белән мәгънәсез җырлар башкармады. Кырык елга якын иҗатын тикшереп карагыз: табарсызмы икән сез анда мәгънәсез, шырдый-бырдый берәр җыру? Әлфия сәнгатькә Солтан Габәшинең «Кәккүк» җыры белән килде. Габдулла Тукайның «Кузгатмакчы булсаң халык күңелләрен... «дигән шигырь юлларын дога итеп алып, «Тәфтиләү», «Әллүки», «Туган тел»ләрен бала чактан ук белеп, бөтен гомере буена шул догага тугрылыклы булып, халык күңелен кузгатып яши.

Әлфия Авзалованың иҗатына тиешле бәя бирелмәде, ул бөтенләй читтә калып барды дисәк тә хата булыр. Әйе, ул — Татарстанның халык, Русиянең атказанган артисткасы, ике мәртәбә Хезмәт Кызыл Байрагы орденына лаек булды. Димәк, күрми калмаганнар... Әле моннан кала аның бер сандык ураклы-чүкечле, йолдызлы, кызылга буялган мактау кәгазьләре дә бар. Һәр концерт саен Ленин бюстын бүләк иткәннәр (ишетеп белүемчә, фатирының бер бүлмәсе шул бюстлар белән тулган). Андый «бүләкләр» миндә дә байтак. Һәрхәлдә, Әлфиянекеннән ким түгелдер. Әмма шулар арасында иң кадерлесе бар — Тукай! Шул мөкатдәс бүләк искә төшүгә үк милләт улы икәнлегеңне тоясың.

Озын сүзнең кыскасы: Әлфия Авзалованың татар милләте каршында йөзе ак, күңеле пакь. Әлфия — тумышы белән моң! Ул — милләт кызы. Әлфия кебекләр дөньяга сирәк килә. Килгәннәренең кадерен белик, хезмәтләренә тиешле бәяне бирергә соңармыйк. Әлфия гарәпчәдән «меңьяшәр» дип тәрҗемә ителә. Әйдәгез, без дә Әлфия Авзаловага «Мең яшәсен!» дигән теләктә булыйк.

*«Ватаным Татарстан»*
*10 апрель, 1992*

**МИРХӘТ МӘРДӘНОВ**

# Халкыбызның моңлы кошы

Булдым инде моңлы коштай,
Сайрамыйм чыгып кына.

*Халык җыры*

Сабый чакта елак балага кайчак: «Әйдә җыласын, үскәч җырчы булыр», — дип әйткәлиләр. Бу ике сүз арасында тирән бер мәгънәви бәйләнеш бар кебек. Башта «елау» сүзе алдан йөри. Аннан соң инде, үсә төшкәч, җыр сүзе төпкә җигелә һәм ул йә елатырга, йә елмайтырга тиеш. Шулай булмаганда җырлауның мәгънәсе юктыр.

Безнең Әлфиябез дә, әлбәттә, башка һәр сабый кебек үксеп-үксеп елагандыр. Биш яшьтә әнисез калгач та, сугышта әтисе үлгәнлеген ишеткәч тә, балалар йортына китергәч тә, чит кешеләр кулына калгач та күз яшьләре түгелгәндер. Гомер агышында очрап торган мәрхәмәтсезлекне, җәберләүләрне, кимсетүләрне татып та күңеленнән әрнегән, тавышсыз гына сыкрангандыр ул Актаныш кызы, Агыйдел сылуы Әлфия. «Сайрамыйм чыгып кына» дигән җыр юлларына капма-каршы буларак, «Моңлы бала түгел идем, моңнар төште башыма» дип, иртә, бик иртә җырлый башлаган ул. Мәктәпкә кергәнче үк.

Укучым инде, шәт, абайлагандыр. Бу язмада сүз җырчы Әлфия Авзалова турында бара. Соңыннан әйләнеп кайтмас өчен хәзер үк әйтеп куям, ул — Татарстан Республикасының халык, РСФСРның (элекке атамышы) атказанган артисткасы, ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены кавалеры. Мондый чакта «түше тулы орден-медаль» дип тә җибәрәләр.

Җырчы Әлфия турында язуы бик авыр. Аның иҗат биографиясе, җыр башкару сәләте сөйләү өчен катлаулы. Аны тулысынча ачу өчен үзеңә олы музыка белгече яки җыр остасы булу кирәктер. Әлфиягә минем үз мөнәсәбәтем бар, мөмкинлек чыгудан файдаланып, үз сүземне кабат әйтәсем килә. Моңа минем хакым бардыр сыман. «Кабат» дип тикмәгә генә белдермәдем.

Без бер чор кешеләре диярлек. Икебез дә Агыйдел якларыннан. Икебез дә ятим. Зур иҗат юлына аяк басарга икебезгә дә шушы якның — Актанышның мәрхәмәтле кешеләре булышты. Бусын сүз уңаеннан гына хәтергә төшерәм. Әлфия турында иң беренче итеп республика яшьләр газетасында мин кайчандыр, иҗатымның башлангыч чорында «Яңа язмыш» дип очерк язып, яшь талантлар конкурсында катнаштым. Һәм призлы урын алдым. Беренчесе түгелме икән әле? Әмма без Әлфия белән иртәрәк, очерк басылганчы ук очрашкан идек. 1948–1949 елларның җәй айларында. Аңа кадәр дә Актанышның бәләкәй җырчы кызы турында ишеткәнем бар иде. Күрергә дә насыйп булган.

Казанда татар театр училищесының беренче курсын тәмамлап каникулга кайткач, мине райкомолга чакырып алдылар һәм агитбригадага кушылырга өндәделәр. Риза булдым. Анда Әлфия дигән кызчык та бар иде. Бер гармунчы, тагын бер биюче кыз һәм мин. Без нәни генә программа төзеп, айдан артык авылларда «концерт» куеп йөрдек. Авыр заман иде. Сугыштан соңгы чор. Әмма халык сәнгатькә шулкадәр сусаган, гади генә бер агитбригада чыгышы да сугыш еллары михнәтен җилкәсеннән коя башлаган авыл халкы өчен бәйрәм төсе ала иде. Кулыбызда районның зур җитәкчеләр кул куеп биргән «юллама» бар. Анда «һәрьяклап булышлык күрсәтергә» дигән җөмлә дә өстәлгән. Авылга килгәч, иң беренче итеп колхоз идарәсендәге җитәкче кешегә шул кәгазьне Әлфия тоттыра. Ул инде бөтенесен рәтләп, тиешле ризыкка язу алып кайта. Беләбез, авыллар шулкадәр хәерчеләнгән иде. Кайберләрендә шушы биш-алты кешелек агитбригаданың тамагын туйдырырлык та ашамлык табуы авыл башлыгын читен хәлгә куя иде. Әлфия «аяк терәп каты» сөйләшә. «Җырчының тамагына бал да, май да, йомырка да кирәк. Югыйсә җырлап булмый», — дип кенә җибәрә теге. Табалар. Тамакны туйдыралар. Ә кичен берничә терәүле авыл клубы (шулай дип әйтергә яраса инде) шыгрым тулы була. Әлфияне юри азакка калдырабыз. Концертның бүтән номерлары — бию, гармунда уйнау, нәфис сүздән соң гына сәхнәдә ул пәйда була... Кул чабулардан клуб стенасының тузаннары оча иде. Һаман, һаман аның җырлавын сорыйлар. Әлфия исә карышмый — җырлый. Җырлый гына түгел, моң суза.

Бакчаларда гөлләр чәчәк атты,
Тормышыбыз кебек ямьләнеп.
Урман суларына аккош кайтты,
Сандугачлар килде әйләнеп.
Сандугачлар килде, аккош кайтты,
Син кайтмадың киткән җиреңнән...

Зал сулкылдап елый. Ирләре, сөйгәннәре, уллары сугыштан кайтмый калган хатыннар, кызлар, аналар үкси. Шушы мизгелне мин әле дә оныта алмыйм. Аның исемен әйтүгә, әнә шул тәбәнәк кенә иске авыл клубындагы халәт мине әле дә хисләндерә, тетрәндереп җибәрә. Таң атканчы, яктырганчы җырлаган чак-

лары да була иде Әлфиянең. Чөнки халык сорый, ялвара: «Җырла, балакаем, җырла, хәсрәтебез дәрья булып аксын», — диләр иде алар.

Әлфия кинәт туктап кала. Гармун җиңел көйгә күчә, һәм сәхнәдән дәртле шаян җыр — «Сызылып киткән кара мыек» яңгырый башлый. Колхоз рәисе, торып: «Җитәр инде, иртән эшкә барасы бар», — дип тә карый. Ләкин җыр белән әсәрләнгән халык кузгалырга да уйламый. Әлфия дә моны белә, аңлый. Күңелләрендәге тирән моң Әлфия җыры аша халыкның үзенә әйләнеп кайта. Моң ул — халык күңеленең тапсыз көзгесе, дип юкка гына әйтмәгәннәр. Кырык еллык иҗат йомгагына анализ ясап әйтсәң, Әлфия һәр халыкның үз моңы булуын чын күңеле белән төшенгән. «Уннан артык чит телдә җырларга өйрәндем, малайкаем, үз илебезнең ничә төрле халкы телендә җырлаганымны чутлап та бетерерлек түгел. Хәтта яһүдләр телендә дә җырларга өйрәндем», — диде ул әңгәмә вакытында. Саннар белән төгәл генә әйтеп булмый, үз гомерендә ул йөзләрчә төр җыр башкарган. Һәркайсын уннарча тапкыр кабатларга туры килгәнен дә өстәсәк, кем әйтмешли, «бер капчык» булыр иде. «Малайкаем» дип безнең якта иң якын кешегә генә эндәшәләр. Бу күркәм гадәте аның әлегә кадәр бетмәде.

Радиокомитетта эшләгәндә, миңа Әлфия турында бер тапкыр радиоочерк язарга туры килде. Монда очеркның үзенчәлеге шул: андагы сөйләм җыр белән бергә үрелеп бара. Әлфия башкаруында халык бик яратып тыңлый торган җырлар сайлаган идем. Шушы концерт-очеркка карата тыңлаучылардан бихисап күп хат килде. Тулы бер папка. Әлегә кадәр саклыйм. Моннан 30 ел чамасы элек язылган ул хатларны тагын бер кат актарып, укып чыктым. Нинди генә рәхмәт хисләре юк иде, нинди генә мактау сүзләре тезелмәгән хәзер инде ул саргаеп барган кәгазь битләрендә. Күбесендә бер үк сүзләр: «Халкыбызның моңлы кошы ул Әлфия, — дигәннәр. — Ходай Тәгалә аңа озын гомер бирсен, тавышы тутыкмасын...»

Әйе, тутыкмаган. Тирән тау астыннан ургылып чыккан чишмәләр агышы тукталмаган кебек, Әлфиянең дә моң чишмәсе һаман сүрелми. Шушы юлларны язарга әзерләнгәндә очрашкач та әле: «Иртәгә тагын чыгып китәбез», — дип ашыктырды ул мине. Аның иҗат сандыгында үз халкы җырлары белән бергә композиторларыбызның заманча җырлары, яшьләр ярата торган җиңел көйләр дә бар. Фәлән яшьтә булуына карамастан (монысын әдәп йөзеннән әйтмиләр), ул һаман юлда. Гөлсем Сөләйманова, Зифа Басыйровалар эстафетасын үз кулына кыю алып, аны үзенчәлекле төсмерләр белән баетып дәвам итә-итә, үз эстафетасын булдырган. Аны хәзер бик тырышып яшьләргә тапшырырга омтылган җырчы бүген дә халыкның үз җырчысы, үз сөекмлесе, Әлфия концертларында зал буш була алмый. Ул башкарган һәр җыр алкышларга күмелми калмый. Тагын бер очрашуны хәтерлим. Бусы алар фатирында булды. Гөлшат Зәйнашева да килгән иде. Кич буе сөйләшеп утырдык. Җыр башкару осталыгы турында сүз барганда, Әлфия чәй яныннан тиз генә кузгалды да, түр башындагы пианино янына утырып, аның аклы-каралы шәкәртмәләренә бармакларын җиңел генә тигезеп алды һәм, русчалатып, «Я люблю свою землю» дип җырлап та җибәрде. Бу җырны рус артистлары башкаруында да ишеткәнем бар иде. Әмма Әлфия аны үзенчә, татарча аһәң белән башкарды. Көй бозылмаган, әмма яңгыраш башкача. Әлеге дә баягы моң үзенчәлеге өстенлек итә. Моны, бәлки, Әлфия генә булдыра ала торгандыр. «Һәр халыкның үз моңы, җыр башкаручы моны күңеленнән тоярга тиеш», — дип тагын кабатлады Әлфия. Ләкин мине гаҗәпләндергәне аның уйнавы иде. Нәрсәдә бит әле! Пианинода. Минем өчен бу чын-чынлап яңалык иде. Ә соңгы очрашуда, әле менә кичә-бүген генә дигәндәй: «Малайкаем, мин бит хромкада да уйныйм, яшьләр кебек эстрадада бии-бии җырлыйм. Төшеп каласың килмәсә, өйрәнәсең аны», — дип көлдерде. Тик монда хикмәт коры теләктә генә түгел, сәләттә. Кайбер иҗат кешеләренең таланты олыгая барган саен сүрелә төшә. Ә аныкы — юк. Ул үзендә замана белән атлап барырлык көч таба.

Гомерем буе гармунчыга, биючегә, җырчыга гашыйкмын. Сокландым да, көнләштем дә, кызыктым да. Үзем чөнки берсен дә булдыра алмадым. Әлфиягә исә бигрәк тә гашыйк идем инде. Хәер, мин генә түгел... Ничәмә-ничә еллар ул сәхнәдән төшми. Бик төшәр иде, ял вакыты да җиткән, әмма аның моңлы җырын сорап һаман-һаман хатлар агыла. Халык бит бик сизгер күңелле, яратмаган җырчысын сорамый, күңел кылларын тибрәтмәгән җырны кабул итми.

*«Ватаным Татарстан»*
*10 апрель, 1992*

**АННА МУСАТОВА**

# «Я вам спою еще на бис...»

Она выходит на сцену, где в течение двух с лишним часов играет моноспектакль из жизни женщины. Рассказывает о любви к родной земле, к мужчине, к детям. Жизнь ее лирической героини складывается непросто, она набивает много шишек на жизненном пути, но при этом никогда не унывает. «Пусть со мной случится хоть что — мне все равно! Пусть со мной случится хоть что — мне наплевать!» — пела когда-то знаменитая Пиаф. Женщины с такой «удесятеренной» жизненной силой, с одной стороны, вненациональны, с другой — богатство нации.

«Она — самородок, Бог, природа наградили ее талантом, которым она радует и взрослых, и детей. Причем Альфия никогда не останавливается на достигнутом, она — на редкость работоспособный человек. Все песни она трактует по-своему, вкладывает в них частичку души», — так отозвался о творчестве Альфии Авзаловой известный татарский композитор Фасиль Ахметов.

В чем же феномен этой певицы, вот уже почти четыре десятилетия не сходящей с эстрадных вершин нашей республики? Невысокая, чуть полноватая, с низким грудным голосом, она поет в огромных дворцах и маленьких сельских клубах — прием везде бывает одинаковым, восторженным.

Детство Альфии Авзаловой прошло в Актаныше, на берегу полноводной Агидели. Она любила петь с детства, но, может быть, это так бы и осталось просто увлечением, если бы на гастроли в Актаныш не приехал Татарский государственный ансамбль песни и пляски. Девочку-подростка уговорили переехать в Казань, она стала работать в профессиональном коллективе, поступила в музыкальное училище.

С благодарностью вспоминает Авзалова Разию Тимерханову и Зулейху Ахметову, которые руководили в то время ансамблем. Теплые слова находит для Раисы Каримовны Волковой, бывшей в те годы художественным руководителем Татарской государственной филармонии имени Г.Тукая. Волкова поставила ей голос и научила нотной грамоте.

Незаметно пролетели годы. Альфия Авзалова ушла из ансамбля: ее актерская природа требовала индивидуального самовыражения. Так в филармонии появилась концертная бригада Авзаловой с самостоятельной цельной музыкальной программой. Помимо певицы, это инструментальный ансамбль «Казан утлары» и танцевальная группа.

«Песни народов мира» — так называется одна из ее программ. Авзалова поет песни индийские, арабские, китайские, узбекские, афганские, еврейские, русские.

«Я люблю свою землю» — эта песня одна из самых дорогих для певицы, потому что она наиболее точно отвечает ее внутренней человеческой сущности. Авзалова добра, щедра к людям, она до сих пор чувствует неразрывную связь со своей родной землей.

В программе «Песни народов мира» все произведения исполняются на языке оригинала. Это признак хорошего вкуса и крепкой школы, полученной певицей в Москве во время учебы у знаменитой исполнительницы народных песен Ирмы Яунзем.

«Наша родина — земля» — под таким названием Альфия Авзалова выпустила в свет еще одну свою концертную программу. Она состоит из песен самодеятельных авторов и современных татарских композиторов, а с певицей работают уже названный Фасиль Ахметов, Риф Гатауллин, Масхуд Имашев, Луиза Батыркаева, Масгуда Шамсутдинова и многие другие.

Певица интуитивно нашла очень верный ход — не отказываясь от народных татарских певческих традиций, она, тем не менее, исполняет песни в эстрадном, более современном, виде. Для этого ансамбль «Казан утлары», состоящий из гитары, органа, клавишных и синтезатора, подходит как нельзя кстати, а руководит им вот уже двадцать два года подряд прекрасный музыкант Карим Габидуллин.

...«Гуси, вы можете улететь туда, где тепло, вы летите на юг, нам грустно провожать вас, но грусть разлуки становится меньше, когда мы вспоминаем, что на холодном севере рядом с нами остаются наши друзья» — лирическая мелодия песни «Гуси» Рустема Яхина на стихи Мустафы Нугмана звучит во всех концертах Авзаловой, певица называет ее одной из самых для нее дорогих. Более двух часов обычно длится концерт Авзаловой, она поет около тридцати песен, уходя со сцены лишь на считанные минуты, чтобы переодеть платье (певица уделяет огромное внимание внешней стороне зрелища — в концертной программе все должно быть красиво!).

Она сама объявляет номера, разговаривает со зрителями, шутит, поет частушки. Впрочем, иногда строй заранее запланированных концертных номеров меняется, и программу приходится переделывать на ходу. Это происходит, когда певица, выйдя на сцену, видит, что большая часть зрительного зала люди пожилые. Тогда появляется баянист, и Авзалова долго с огромным удовольствием поет татарские народные

песни — веселые, грустные, бесхитростные. А после концерта седые аксакалы приходят за кулисы и степенно благодарят певицу за доставленное удовольствие.

У нее нет проблем со зрителем. Зимой она гастролирует по городам республики, выезжает на Урал, в Сибирь, в Среднюю Азию, в места компактного проживания татар. Лето же принадлежит селам и деревням родной республики. Авзалова не выбирает концертные маршруты попроще и покомфортнее, она с удовольствием едет в самые дальние колхозы, потому что считает: одна из самых главных обязанностей артиста — заниматься просветительской деятельностью, пропагандой народного музыкального творчества.

Найти свое место на эстраде, которую захлестнула волна дурного вкуса, — непросто. Особенно сложно это для человека, который не хочет меняться в угоду конъюнктуре, идти на поводу у сиюминутного успеха.

Альфия Авзалова придумала себе сценический имидж, наиболее соответствующий ее человеческой природе, — веселой, неунывающей хохотушки, которая в нужный момент может стать серьезной, но при любых обстоятельствах остается доброй и без страха смотрит в будущее. Может быть, вот эта уверенность, которой нам так сейчас на хватает, это душевное здоровье, — а им в полной мере наделена Альфия Авзалова, — и делают ее творчество таким привлекательным для людей самых разных возрастов и социальных прослоек.

Впрочем, ее простота и легкость не имеют ничего общего с бездумностью, которой сейчас так грешит наша эстрада. Авзалова — человек вдумчивый, серьезный. Она тщательно подбирает репертуар, причем, — что вовсе редкость для певиц, — при выборе песен решающим фактором для нее является не музыка, а текст. Она любит хорошую поэзию, петь «подтекстовки» — это не для нее. Наверное, поэтому в ее репертуаре так много песен на стихи чудесных поэтов Мусы Джалиля и Сибгата Хакима. И своими концертными программами она пропагандирует не только нашу музыку, но и поэзию.

Так пусть же разговор о женщине-певице завершит женщина-композитор.

«Помню, в детстве я увидела крутящийся черный диск, потом раздался женский голос — это был миньон Альфии Авзаловой. Она находилась в зените славы, и мы все были в нее влюблены. Теперь я понимаю, почему это происходило: она может проникнуть в душу песни, в душу женщины. В Авзаловой есть женская цельность. Она всю жизнь стремится не останавливаться на достигнутом, всю жизнь старается учиться, но при этом, к счастью, не теряет этой необычайной непосредственности, которая дается людям от рождения» — это мнение об Альфии Авзаловой прекрасного татарского композитора, много работающего в области собирания и пропаганды фольклора, Масгуды Шамсутдиновой.

*«Известия Татарстана»*
*1992, 21 апреля*

**КИРАМ САТИЕВ**

# Уртаклык

80 нче еллар башы... Хәрби хезмәттән кайтып, Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә кабат эшли башладым. Сөекле җырчыбыз Әлфия Авзалованың концерт бригадасына билгеләделәр. Күп тә узмады, Әлфия апага Достоевский урамындагы йорттан яңа фатир бирделәр. Бу барыбыз өчен дә шатлыклы вакыйга булды, чөнки безнең, артистларның, барысы да — шатлыгы да, кайгысы да уртак иде.

Яңа фатирга күчергәннән соң, яңа адресны язарга дип куен дәфтәремне алдым һәм... тукталып калдым. Йорт һәм фатир номерлары нәкъ минеке кебек иде: 53 нче йорт, 71 нче фатир. Әлфия апа да минем адресны язып тормады, Восстание урамы икәнен генә хәтерендә калдырды.

Югарыда язылганнарга өстәп тагын шуны әйтәсем килә: 1992 ел тагын бер уртаклык алып килде: Әлфия Авзалова — Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә, мин Ф.Туишев исемендәге премиягә лаек булдык.

*«Ватаным Татарстан»*
*1992*

**ФАНИЯ ХУЗИАХМЕТОВА**

# Сама мелодия

Кажется, ее знают с незапамятных времен, потому что везде, где живут татары, имя ее с одинаковой любовью произносят и старики и подростки. «Она приезжала к нам в таком-то году», — вспоминают в ином ауле и припоминают события до подробностей. И я помню ясно, как она приезжала к нам в село в 1960 году.

Была пора сенокоса — чудесные, самые лучшие дни лета, когда светло почти круглое время суток. Клуб битком набит людьми.

Детворе, как обычно, мест не осталось, и мы облепили окна клуба. К счастью, от духоты окна открыли, и песни вырвались на волю, помчались по сельским улицам, поплыли над полями...

И мы услышали песню кукушки. Да, именно песню, раньше мы были уверены, что кукушка лишь кукует, а она, оказывается, и поет! Мы изо всех сил тянули шеи, чтобы увидеть певицу, исполнявшую песню кукушки. Альфия апа после каждой песни уходила за сцену. А мы потихоньку, друг за другом, перелезали через окно и устраивались на полу, прямо возле сцены. Казалось, что эти чарующие звуки песен магнитом притягивали нас в клуб, к сцене.

Вскоре из нас на улице никого не осталось. Мы слушали, что называется, открыв рот. В тот вечер Альфия апа спела так много песен, что мы думали: больше на свете и песен не осталось.

На следующий день мой отец, обычно немногословный, но любящий песню, сказал:

— Вот родится дочка, назову ее Альфией.

Через год у меня появилась сестричка, которую назвали Альфией. Знаю, что это не единственный случай имянаречения в честь певицы. Я спрашивала у многих девушек с именем Альфия, и многие отвечали, что их назвали в честь певицы Авзаловой. Такова бесхитростная любовь простого народа к певице. Надо сказать, что далеко не каждый, даже известный и талантливый, артист удостаивается народного признания. Тем более что некоторые артисты зачастую слишком высокого мнения о себе и своем мастерстве и никогда не снизойдут, например, до того, чтобы трястись на телеге по сельским ухабам или тащиться в тракторном прицепе по снежному бездорожью. А Альфия Авзалова с любыми дорогами была на «ты».

— Мне ничего, кроме зрителей, не надо было, — вспоминает те годы Альфия апа. — За один выезд я давала иногда больше ста концертов, колеся по аулам два-три месяца. Не знала усталости, все пела и пела... Вообще в жизни для меня существуют две ценности: хорошие песни и хорошие люди. Я рано осталась сиротой, росла у родственников, в детдоме, у чужих людей. И ничего — не пропала, не сломалась. Еще в Актаныше я выступала с песнями. Моими первыми наставниками, баянистами были Марзия Юнусова, Масхут Ахметшин. Именно они научили меня песням, которые прошли через всю мою жизнь, стали любимыми, — «Кәккүк» (Кукушка), «Салкын чишмә» (Холодный родник), «Гульджамал», «Аллюки», «Тэфтиляу», «Туган тел»... А в Казани меня встретила руководитель Татарского государственного ансамбля песни и пляски Зулейха апа Ахметова. А баянистом была Оркыя апа Ибрагимова...

— Альфия апа, нужно ли учиться, чтобы стать певицей? Учились ли Вы?

— Ну, спасибо, вопрос, как говорится, не в бровь, а в глаз. Знаешь, у меня много было и врагов и завистников, не среди зрителей, конечно, а среди коллег. Бывало, вспылю или чем-то другим не понравлюсь, так сразу же мне в лицо бросали, что, мол, я неуч и консерваторию не заканчивала. Что же, признаюсь, что «университеты» свои я проходила не в стенах консерватории. И в музыкальном училище проучилась всего восемь месяцев, потому что голос сорвала. А голос сорвала потому, что его мои педагоги хотели сделать тонким, высоким. Словом, бросила я училище и стала петь по-своему. Слава Аллаху, прежний голос мой восстановился... Как и голос, так и характер мой не удалось изменить. Да, я бываю и вспыльчивой, острой на язык, говорю прямо, без обиняков... Вы посмотрите на сегодняшних артистов. Только выйдут на сцену, рта еще не раскроют, а уже аплодисменты у зрителей выпрашивают. Да это же все равно что подаяние клянчить. Ты спой, а зрители сами поймут, хлопать им в ладоши или нет. Таким, как Хамдуна Тимергалеева, Зухра Шарифуллина, Салават Фатхутдинов, народ аплодирует сам, едва услышав имя... А что касается учебы, то я понимаю ее как работу над собой, над самоусовершенствованием. Как-то я поехала в Москву на годичную учебу и вернулась оттуда, научившись петь на тринадцати языках. Исполняла потом песни китайские, индийские, арабские, корейские... Зрители эту программу полюбили. Кроме того, я изучала песни тех народов, в республики которых ездила на гастроли: узбекские, азербайджанские... Словом, певец должен все время работать над собой.

— Альфия апа, в последнее время мир сильно изменился, жить стало гораздо труднее, цены неудержимо растут. Вот и на концерт билеты стали стоить аж 15 рублей. В связи с этим возникают ли трудности в вашей работе?

— Правильно, милая, жить стало трудно. Но у меня пока есть свой зритель. Недавно вернулась с гастролей по Самарской, Пермской областям. Залы были полны. Народ песню любит по-прежнему, на концерты ходят и стар и млад. С повышением цен на билеты, думаю, должна повыситься и требовательность к артисту... Впрочем, вопрос о трудностях жизни имеет для меня и другую сторону. В чем-то мне стало легче жить. Я имею в виду то, что раньше, как возвращалась с гастролей, меня тут же вызывало начальство и показывало кучу анонимок в мой адрес. Чего только в них про меня не говорилось: мол, и пьет, и гуляет она, и такая, и сякая...

— Альфия ханум, может, не надо об этом?

— Почему же, пиши, пиши, у меня от народа секретов нет. Я и сама могу сказать, что у такой-то и такой-то там-то есть кто-то, и от него ребенок. Но не поворачивается язык, совесть не позволяет разносить это на конце сорочьего хвоста. Что касается меня, то, скажите на милость, как можно «гулять, пить» и сорок лет при этом быть популярной певицей, да еще вырастить двух дочек? Обе они уже замужем, у них трое детей.

— Альфия ханум, но ведь ваши начальники наверняка не только анонимки про вас читали. Ведь были и ордена, медали, звания. В пору работы в отделе писем редакции мне довелось прочитать много писем, в которых вам выражались благодарность и признательность. Писем, повторяю, было много, всех их в газете напечатать не представлялось возможным, поэтому мы отправляли их в филармонию, в отделы культуры.

— По-всякому, видимо, было. Помню, заработали мы во время гастролей (дали больше ста концертов) 80 тысяч рублей и по возвращении решили следующую поездку организовать в Каракалпакию. В то время был один секретарь обкома, вечно совавший палку в колеса искусства. Этот начальник распорядился не пускать на гастроли меня и Назию Минкину. Я, конечно, вспылила и, хотя должна была отдыхать, не угомонилась, пока не собрали бригаду и не поехали на гастроли. В самые трудные минуты меня поддерживали зрители. Я самостоятельно тащила и семейную жизнь, и творческую... А нынешним руководителям я благодарна за то, что они не выискивают, образно говоря, грязь под моими ногтями, не высматривают подробности личной жизни, и к тому же на мои концерты ходят — спасибо.

— Альфия ханум, когда Вас выдвинули на соискание премии имени Г.Тукая, во многие газеты поступили теплые письма в Ваш адрес — от Ильхама Шакирова, Гульшат Зайнашевой, других. Ильхам абый назвал Вас «светлой звездой нашего неба»...

— Он все время был для меня и опорой, и маяком, на который я равнялась. Если бы не Ильхам Шакиров, возможно, и не состоялась бы я как певица. Я старалась не отстать от него, по-хорошему завидовала и сама росла творчески. Спасибо ему за теплый отклик, уважил меня. И Гульшат Зайнашевой «рахмат». Она все время была для меня близким другом, помощником. Такие песни, как «Күңелле ял итегез», «Яшь гомер», «Күл буена килсәң иде» были написаны композитором Зиннуром Гибадуллиным и поэтессой Гульшат Зайнашевой, а я эти песни с удовольствием исполняла. Так родилась наша творческая дружба. Вместе творили, переживали, волновались...

— Альфия апа, Вы знаете, что наша газета в основном адресована татарской диаспоре. Что бы Вы хотели им сказать?

— Я никогда не воспринимала их как диаспору, как соплеменников, живущих где-то необозримо далеко. Я всегда чувствовала их близость, никогда не жаловалась на дальность и трудность ведущих к ним дорог. Даст Аллах, еще к ним поеду. Скоро, например, отправлюсь в Оренбуржье...

Ильхам Шакиров так написал о ней: «Альфия Авзалова чиста душой перед народом. Она — сама мелодия! Альфия с самого рождения — истинная дочь нации. Такие, как она, редко появляются на свет. Оценим же по достоинству ее талант, ее труд. Имя Альфия переводится с арабского как «будет жить тысячу (лет)». Мы тоже говорим: «Живи вечно!» Вклад Альфии Авзаловой в татарское песенное искусство поистине неоценим».

При всем моем старании не смогу сказать лучше, чем Ильхам эфенди.

*«Татарские края»*
*1992, май*

**РӘЙСӘ ЯХИНА**

# «Яшьлегемә кире кайтыр идем...»

Татар халкында исемнәре мәңгегә тарих битләренә кереп калган шәхесләр бар. Исән чакта без аларның күбесен аңлап та бетермибез, җиңел кулдан гына төрле имеш-мимешләр дә таратабыз, тиешле кадер-хөрмәтебезне дә күрсәтә алмыйбыз. Барысы да соңыннан, еллар үткәч кенә искә төшә.

Әле шушы көннәрдә Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисткасы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Әлфия Авзалова белән сөйләшеп утырганда да мин шул фикергә килдем. Ни өчен икәнен һәркем үзенчә аңлар, үзенчә нәтиҗә ясар. Мин фәкать үземнең сорауларымны һәм аның җавапларын гына тәкъдим итәм.

— Әлфия апа, Сезнең бала чагыгыз һәм яшьлек елларыгыз турында шактый күп язылды инде. Шулай да бераз искә төшереп узыйк әле. Сез ничек җырчы булып киттегез?

— Әй җаным, ятим бала моңлы була, диләр бит. Мин биш яшемнән әниемнән калып, бик авыр тормышта, ятимлектә үскән кеше. Яза башласаң, бер дә Габдулла Тукайның бала чагыннан ким түгел. Тиздән минем «Үзем турында» дигән китабым басылып чыгачак*. Шунда барысы да тулы язылган. Башта әле без Башкортстанның Яңа Кабан авылында яшәгәнбез, аннан Актанышка китергәннәр. Әнә шунда беренче класстан ук җырлый башладым мин. «Карлыгач» дигән спектакльдән бер җыр җырлый идем.

Һаваларда очкан карлыгачлар
Болытларга кереп югала.
Кыз булганчы, булсам канатлы кош,
Тоткын булмас идем дөньяда.

Шушы җырым белән бөтен кешене җылата торган идем. Үсә төшкәч, агитбригада белән колхозларга концертларга йөртә башладылар. Ә 1951 елда инде райком кешеләре миңа Казанга килергә ярдәм иттеләр. Зөләйха Әхмәтова җитәкчелегендәге ансамбльгә алдылар. Инде менә 41 ел буена сәхнәдән төшкәнем юк.

— 41 ел үзе бер кеше гомере бит, арытмадымы?

— Юк, арымадым. Яшем шактый олы булса да, тавышым бар әле. Мине халык яратадыр дип уйлыйм. Чөнки кая гына барсам да алкышлап каршы алалар, сәхнәдән төшермиләр. Мин шулай эшләп кенә яшим, яшәрәм.

Әле менә быел апрель аенда Камчаткада булып кайттык. Шунда яшәүче татар, башкорт халкы «Әлфия Авзалова килсен иде» дип махсус чакыру кәгазе язып җибәргәннәр. Бөтен бригадабыз белән бардык. Синтезаторда уйнаучы Кәрим Габидуллин, җырчы Рөстәм Маликов, нәфис сүз остасы Әлифә Вәлиева, баянчы Равил Закиров һәм мин 10 көн буена балыкчылар янында яшәп кайттык. Аэропорттан чыгуга, «Волга»лар белән каршы алдылар. Күз ачып булмаслык кар явып торуга, салкын булуга карамастан, кулларыбызга чәчәк бәйләмнәре китереп тоттырдылар. Остабикәләр кебек өйдән өйгә кунакка йөрттеләр. Бару-кайту өчен самолетка билет хакларын да үзләре түләделәр. Хәзер сабантуй бәйрәменә чакыралар. Ташкентта да ел саен булам, көтеп кенә торалар. Шулай булгач, мин үземне әле халкыма кирәкле кеше дип саныйм, өйдә генә утырырга җыенмыйм.

— Ә үзебезнең Татарстаныбызда бигрәк тә кайсы районнарга барырга яратасыз?

— Әгерҗегә. Минем андагы халыкка исем китә. Мәдәният бүлегендә эшләүче иптәшләр анда төн йокламыйча поездны көтеп каршы алалар, кунак итәләр. Колхоз рәисләрен юри сайлап куйганнар кебек, берсеннән-берсе мәгънәле, шәфкатьле кешеләр. Бигрәк тә Закировлар нәселенә рәхмәт. Әгерҗедә аларны белмәгән кеше юк. Биектау авылындагы кунакчыллыкны да әйтеп бетерә торган түгел. Хәзер безнең бөтен артистлар Әгерҗегә барырга тырышалар. Без үзара сөйләшәбез бит — кайда ничек каршылыйлар, дип. Сарманны, Минзәләне, Кукмараны, Чүпрәлене бик мактыйлар.

— 41 ел сәхнәдән төшмәгән эстрада йолдызына, әлбәттә, чит илләрдә дә булырга туры килгәндер инде, шулаймы?

— Әйе, мин бик күп илләрдә булдым. Ләкин берсенә дә хөкүмәт исәбеннән концерт куярга дип түгел, ә үземнең барлы-юклы хезмәт хакым исәбенә, балаларымның авызларыннан өзеп җыйган акчага бардым мин. «Әлфия чит илдә булган икән», — дигән сүз өчен генә. Чөнки артистлар арасында көнчелек бик көчле бит. Ә миннән көнләшүчеләр бик күп булды заманында. Терелә́й килеш чокырга күмәргә әзер тордылар, нинди генә пычрак гайбәтләр таратмадылар. Аны бит халык түгел, артистлар тарата. Халык барысын да белеп бетерми, ышана. Үзе дә кайчакта аны-моны уйлап тормыйча сөйли башлый. Бер караганда көнчелек дигән нәрсә башында акылы булган сәнгать кешесенә әйбәт тә икән әле, үсәргә ярдәм итә ул. Мин дә гайбәтләргә игътибар бирмичә үсәргә тырыштым. Репертуарым өстендә эшләдем. Мәскәүләргә киттем, кайсы якка гастрольгә барасы булсам, шул халык телендә җырларга тырыштым. Усалларга карап усаллан-

мадым, хуҗаларга жалоба белән йөрмәдем. Авызым тулы кара кан булса да, кеше алдында түкермәдем, йоттым.

Татар халкының күренекле җырчысы дип мине чит илләрдән чакыручылар булмады түгел, булды. Җибәрмәделәр. Мәхәббәт сатып йөрүче вак-төяк артистлар йөрде элек чит илләргә. Мин хәтта Каракалпак Республикасында үткәрелгән Татар әдәбияты һәм сәнгате атналыгында да катнаша алмадым. Хәзер инде бөтенләй икенче хәл. Җитәкчеләребез әйбәт. Мин үземнең якташым, Президентыбыз Минтимер Шәрипович Шәймиев алдында, премьер-министрыбыз Мөхәммәт Галләмович Сабиров һәм башка җитәкчеләр алдында баш иям. Алар каршына нинди генә чибәр-чибәр артисткалар килеп бассалар да, хәйлә кора алмаячаклар. Хәзерге җитәкчеләребез янына кереп баш ияргә, киңәшләшергә була. Элек бит якын килеп булмый иде обкомга. Мин үзем коммунист булмадым, әмма намусым чиста иде.

— Ә филармония директорыгыз ничек соң хәзер?

— Әсгать Сафин үзе дә артист кеше, артистларның ничек интеккәнен яхшы аңлый ул. Барысына да бертигез карый. Хәзер сәхнә күлмәкләребезгә кадәр филармония исәбенә тектерәләр. Әлбәттә, хуҗа кеше бөтен кешегә ярап бетмәскә дә мөмкин. Тик мин үзем риза. Гомумән, хәзер икенче бит тормыш — безнең яшьлек чорындагы кебек түгел. Әнә безнең эстрада йолдызларыбыз Асаф Вәлиев, Хәмдүнә Тимергалиева, Зөһрә Шәрифуллинаны алыйк. Алар шулкадәр иркен яшиләр, директор алдында, миңа акча аз түләдегез, дип зарланып йөрмиләр инде. Хәзер үз өстеңдә эшләсәң, планнарыңны тутырсаң, икенче җиргә барып концерт куярга акча эшләргә дә була. Моның өчен бөтен шартлар бар.

— Менә Сез яшьрәк вакытта иҗатыгызга көнләшеп караучылар булды дидегез. Аларның исемнәрен атап тормыйк, дусларыгыз белән генә танышып китик әле.

— Чын дуслар күп булмый. Минем бик якын өч дустым бар: берсе — Гөлсинә Сәлахова — Казан дәүләт университетында укыта, икенчесе — Гөлшат Зәйнашева, өченчесе — Татар дәүләт академия театрында тавыш режиссеры булып эшләгән Зөләйха Йосыпова. Миңа бит гастрольләрдән төнге бердә дә, икедә дә, өчтә дә кайтырга туры килә. Төнлә лифтлар эшләми — мин үз өемә кайта алмыйм. Шуңа күрә кайда булсам да, Казанга кайтыр алдыннан Зөләйхага телеграмма җибәрәм. Ул мине төн йокламый көтеп тора, өчпочмаклар пешереп каршы ала. Әмма безнең беребездә дә өстәл өстенә аракы чыгарып куеп туган көннәрне, китү-кайтуларны бәйрәм итү гадәте юк. Туган көн дигән нәрсәне гомумән яратмыйм мин. 28 ел ирсез торып, балаларым өстәл өстендә шешә күрмәделәр. Аллага шөкер. Шуның белән бәхетле дә мин.

— Сез үз балаларыгыз өстенә тагын сеңлегезнең балаларын да үстердегез бит әле.

— Әйе. Сеңлем үлгәнгә инде 19 ел. 6 баласы калган иде. Балалар йортларына урнаштырсам да, аларны мин үзем үстердем дип әйтә алам. Хәзер зурлар инде. Берсе генә Минзәләдә интернатта яши. Мин гастрольдән кайтышка алар сумкаларын тотып килеп җитәләр. Барысына да өлеш чыгарам. Тәмле итеп ашарга пешерәм. Мине бик уңган диләр артистлар. Чөнки ризыгын табам, уам, юам, ашханәдә ашап йөрергә яратмыйм, нинди генә шартларда да үзем пешереп ашыйм! Кибеттән пәрәмәч алып ашаучыларга исем китә.

— Шушы көннәрдә Сез тагын үзегезнең туган якларыгызга гастрольгә чыгып китәсез икән. Бик ашкынып кайтасызмы Актанышка?

— Яшь чагымда мин анда елына икешәр-өчәр тапкыр кайта торган идем. Чөнки анда элек кунакны кунак итә беләләр, ачык йөз белән каршы алалар иде. Хәзер инде ул вакыттагы җитәкчеләр зуррак урыннарда — Казанда эшлиләр. Алардан соң килгән кешеләр еш алышынып тордылар. Алар мине белеп, аңлап бетермиләр иде, ахрысы. Актаныш кызы булсам да, мине анда эти-әнием көтеп тормый бит.

Бервакыт шулай Актанышның 60 еллык юбилеена чакырдылар. Шул районда туып үскән берничә артист үз акчаларыбызга билет алдык та юлга чыктык. Самолет очмый. Шуннан мин аптырап калмадым — Минзәлә аркылы кайтасы булдым. Кайтып төштем райкомга.

— Рәшит Сәетович, машина табасызмы? — дим.

— И Әлфия апа, машина гына түгел, Сезнең хакка самолетын да табабыз аның, — ди.

Бераз ял итеп, ашап-эчеп алганнан соң, машина белән Актанышка илттереп тә куйдырды. Бер дә онытылмый бит менә мондый яхшылык.

Икенче көнне юбилей тантанасына киттек. Халык арасына кереп утырдым, карап, күзәтеп торам — районның талантлы кешеләре турында сөйли башладылар. Актаныштa беренче булып трактор йөртә башлаган бер хатынны мактый-мактый сәхнәгә алып мендeләр. Кулына бер астра чәчәге тоттырдылар да яңадан төшерделәр. Төшкәндә ул чәчәге дә сынды. Бөтен зал гөж килеп алды. Хурландым шунда. Их, мин әйтәм, неужели бу районда ике пачка чәй белән бер яулык тапмадылар икән әлеге хатынга? Башы күккә тияр иде бит моның, дим. Шулкадәр саран булуларына оялып утырдым актанышлыларның. Ә миңа килгәндә, мин дә бит үземә күрә төшеп калганнардан түгел. Шулай да концерт беткәндә генә миңа да бер чәчәк эләкте...

Бер ел үткәч, шундый ук юбилейны Сарманда да үткәрделәр. Анысына Зөһрә Шәрифуллина барды. Һәм, гафу итегез, өр-яңа сандык белән бер сандык бүләк төяп кайтты ул. Көнләшүемне сиздермәскә тырышсам да, сизде Зөһрә, бик үткен хатын ул, күзләремнән белде.

Хәзер инде Актанышка башка җитәкче килгән. Район администрациясе башлыгы булып Таһир Зиннурович Ахмаев эшли. Үзебезнең Актаныш егете икән. Әле күптән түгел туганлашкан дусларыма кунакка кайткач, аның янына танышырга кердем. Шулкадәрле ачык йөзле, озын буйлы чибәр кеше, мине якты йөз

белән каршы алды. Икмәк хәлләрен сораштым. Көне-төне яңгыр ява анда. «Икмәкне җыя алмаганга бик борчылам», — дип сөйләде. «Күңелләрегез төшенке булса да, монда инде 4 ел сәхнәдә булганым юк, бригадам белән 20–25 концерт бирә алам. Бу минем юбилей елым да. Халкым белән сәхнәдә саубуллашып китүем булыр», — дигәч, тәкъдимемне хуплап каршы алды: «Килегез, Әлфия апа, һәр авылда бишкуллап каршы алачаклар Сезне, оештырырбыз», — диде.

— Ә репертуарыгыз нинди, нинди яңа җырлар алып барасыз Актанышка? Гомумән, Сез үзегезнең иҗат гомерегездә нинди җырларны аеруча яратып җырладыгыз?

— Әгерҗедә яшәүче Әнвәр Закировның Гөлшат Зәйнашева сүзләренә язган «Соңлап килгән мәхәббәт» җырын башкарырга уйлыйм. Минем бик яраткан артисткам бар — бик матур гәүдәле, матур тавышлы Хәния Фәрхи. Без аның белән икебез дә түбән тавышлылар. Аның «Үпкәләмә» дигән җырын яратам. Хәниядән рөхсәт алып, шуны өйрәндем. Ә элекке җырларыма килгәндә...

Әлфия апа үзенең сихри тавышы белән җырлап та җибәрде:

Син ант иттең, вәгъдә бирдең,
Гомерлеккә яр булырмын, дип.
Арган-талган чакларыңда
Йөрәгеңә ял булырмын, дип.

Бер җырны икенчесе алыштырды:

Яшьлегемә кире кайтыр идем,
Кире кайта торган юл булса...

Җыр өзелде. Әлфия апа телефон трубкасын алды.

— Кәримулла, нихәл, җаным! Әзерләнәсеңме? Җылырак киен, яме, көннәр салкынайта. Йон оекбашларыңның барысын да алып бар.

— ...

— Сүтәбез дә яңартабыз аны, старье түгел бер дә, ал, ал. Оекбаш искерми бит ул, табаны гына туза. Биш энә бар.

— ...

— Шикәр, чәй, май, варенье алырга кирәк. Обязательно, фатирларда яшәячәкбез. Хәзер халык бәрәңге ала. Синең турыда уйларга вакыты юк. Бу сиңа Әгерҗе районы түгел.

— ...

— Иртәгә телевидениегә төшерәләр. Урманда. Салкын тидермәсәм генә ярар иде. Өем дә бик салкын...

Бөтен республикабыз буйлап командировкаларга йөргән кеше буларак, үземнең дә бар нәрсәне сумкама төяп, юлга җыенган чакларым исемә төште. Әлфия апа Авзалова да бит гомер буе шул юлларда йөргән. Ләкин ул күренекле артистыбыз — татар эстрадасының мәңге сүнмәс йолдызы гына түгел, ә балалары турында кайгыртучы Ана да, ятим туганнары өчен иң изге күңелле Апа да, хезмәттәшләре өчен акыллы Киңәшче дә. Ходай түземлек, илһам, саулык-сәламәтлек бирсен аңа!

*«Шәһри Казан»*
*18 сентябрь, 1993*

**ХАРРАС ӘЮП**

# Сандугачлар ызгышмый...

Хөрмәтле Әлфия апа!

Хат язарга һәвәс кеше түгел мин. Очрашып сөйләшүгә ни җитә! Әйтәсе сүзләремне үзегезгә генә дә җиткерә алган булыр идем. Әмма «Шәһри Казан» газетасында Сезнең белән үткәрелгән әңгәмәне («Яшьлегемә кире кайтыр идем», 18 сентябрь, 1993) укыгач, куллар каләмгә тартылды. Сезгә ачык хат язу теләге туды. Әңгәмәдәге кайбер фикерләрегез күңелдә күптән йөргән борчулы уйларымны Сезгә генә түгел, галим-голәмага да белдерергә этәрде.

Сез эстрада җырчыларының бик үк кадере булмавы турында берничә урында искә аласыз, гыйбрәтле мисаллар да китерәсез. Килешмичә мөмкин түгел. Моны дәлилләү өчен ерак барасы да юк. Сезнең кебек мәшһүр җырчыга республикабызның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләген бик соңлап бирүләрен искә төшерү да җитә торгандыр. Ул чактагы җитәкчеләрнең гаделсезлеге үз намусларында калсын. Әмма мәсьәләгә мин бераз бүтәнчәрәк карыйм.

...60 нчы еллар. Безнең студент чак. Кесә төпләрен кырыштырып, концерт-спектакльләргә чабабыз. Опера-балет театрында Сез биргән концерт әле бүгенгедәй хәтердә. Җиңелчә ак күлмәктән сәхнә уртасында талпына-талпына «Күбәләгем»не җырлавыгыз һаман да булса күз алдыннан китми. Сезне бөтен зал аягүрә басып алкышлаган иде. Бәхетле идек без: Әлфия Авзаловалы идек... Үзегез дә бәхетле булгансыздыр дип уйлыйм ул минутларда. Сәхнәгә чәчәкләр менде. Бүләк итәргә халыкның затлы келәмнәре, япон телевизорлары, видеомагнитофоннары юк иде шул әле... Ул Сезгә үзенең мәхәббәтен бүләк итте. Һәм гомерлеккә... Әнә күпме еллар узгач та калкып чыга бит ул: Камчаткага чакырып алдылар, дисез. Шул мәхәббәтнең чагылышы түгелмени бу?! Әгәр Айда кеше яшәп, татар халкы анда барып чыккан булса, Сезне Айга да чакырмый калмаслар иде... Татарстанның гына түгел, халык кадәр халыкның еллар буена яраткан җырчысы булып калу бәхете һәркемгә тәтеми торгандыр. Дөнья малы моның белән чагыштырганда өч көнлек кенә. Тик әнә шул өч көнлек мал бүгенге талантлы яшь җырчыларыбызны харап итмәгәе дип хафаланам мин. Ходай биргән рухи байлыкларыбыздан язмагаек дип борчылам.

Зинһар, дөрес аңлагыз — артистларның әйбәт, мул тормышта яшәвенә каршы түгел мин. Алар да адәм рәтле гомер итәргә хаклы. Япон телевизоры да, машинасы-келәме, башкасы да булсын. Бүләк итсеннәр аларга киң күңелле милләттәшләребез җаннары теләгән бүләкне, тарыгырга кирәкмәс. Әмма нигә байлык артыннан кууны үзмаксатка әйләндерергә? «Машина миңа булырга тиеш иде, нигә аңа бирделәр», — дип ямьсезләнешү, бер-береңне дошман күрү җырчылар гамәлеме? Алар белән рәтле генә итеп аралашып та булмый бит хәзер. Нindидер сагаю, шикләнү, ышанмау галәмәте үзләрендә. Сандугачларның ызгышканын кемнең күргәне бар? Инде шуңа бара ала икән, димәк, ул сандугач түгел...

Әле дә, шөкер, халкыбызның рухи чишмәләре исән, корымаган. Алар тирәннән тибеп чыга торалар. Бүгенге көндә хозурланып тыңларлык бик күп яшь җырчыларның мәйданга чыгуы шуны раслый.

Ләкин болар замана баткагын исән-имин үтә алырлармы, бу зилзиләләрдән, гарасатлардан моңыбызны коткарып калырга көчләре җитәрме, мал-байлык арасында көя күбәләкләренә әйләнеп калмасларму? Үзләренә табигать биргән байлыкны югалтмыйча, Сезнең шикелле еллар буена күтәреп бару кулларыннан килерме, үз дәверләренең Әлфия Авзаловалары була алырлармы алар? Әлегә минем моңа иманым камил түгел. Сәбәпләре бар, бигайбә...

Әңгәмәгездә Сез, Әлфия апа, бер яшь җырчының рөхсәте белән ул башкара торган җырны репертуарыгызга кертүегез турында әйтәсез. Гафу итегез, мин Сезне аңлап җиткермим.

Дөрес, һәр җырчының үз йөзе, үз репертуары булырга тиешлеген мин, җыр сөюче кеше буларак, бераз чамалыйм. Тик һәрбер җырга табу салу кайчан башланды соң әле? Бер җырчы башкарган яңа җырны икенчесе җырламаска тиеш дигән гамәлгә сыймас нинди кагыйдә ул? Кем уйлап чыгарган аны? Авторлар үз әсәрләренең күбрәк кеше тарафыннан башкарылуын, популяр булуын теләмиләрмени? Сез «Шахта», «Сарман»нарны җырлаганда Зифа Басыйровалардан, Рәшит Ваһапов, Илһам Шакировлардан сорауның кирәге булдымы? Беренче булып Сез халыкка җиткергән әсәрләрне үз репертуарларына керткәндә, башкалар Сездән рөхсәт алдыларммы? «Әниемә хат»ны җырлыйсым килсә, Илһам Шакировка торып йөгериммени инде?! Көлке бит бу, билләһи! Үзләре күмелеп калудан куркып, булыр-булмас җырчылар уйлап чыгарган «закон».

Җыр — сәнгать әсәре ул. Авторлар кулыннан киткән һәр сәнгать әсәре — халыкныкы. Ул аерым беркемнеке дә түгел, ә уртак байлык. Теге яки бу җырны башкарырга да һәркемнең хокукы бар. Үзара җыр бүлешү — алда телгә алган мал бүлешүнең бер ямьсез чагылышы инде ул. Ярар, малын бүлеш тә ди. Халык байлыгына тимә инде син агайне! Җырга табу салып кына үз йөзеңне, оригинальлегеңне саклап калып булмый торгандыр ул. Талантың чамалы икән, үзеңнән көчле җырчылар барыбер каплап китәчәк. Хакыйкатьнең кануннары катгый аның. Мәсьәләне талант хәл итә. Кешегә талант бирсен, илһамнан аермасын

аны Ходай. Үз вакытында көнче бәндәләр күпме генә аяк чалырга тырышмасын, Сез бит менә шушы кыйблага карап иҗат иттегез, шуңа табынып яшәдегез. Һәм замана Сезнең хаклы булуыгызны үзе раслады.

Сезгә тагын бер соравым бар, Әлфия апа. Нинди җырлар башкарып халык җырчысы булдым дип уйлыйсыз? Минемчә, татар халкы йөрәгенә Сез «Гөлҗамал»лар белән кереп урнаштыгыз, «Күбәләгем», «Сарман»нар белән... Ә замана тудырган җиңелчә җырлар, композиторларыбыз әсәрләре әлеге төп баганалар арасындагы матур рәшәткәләр булдылар. Сезнең моңыгыз бервакытта да халыктан аерылмады. 41 ел буена сәхнәдән төшмичә иҗат иткәнсез икән, бу — әнә шул тугрылыкның матур нәтиҗәседер, анда-монда ташланмыйча, бер юлдан баруның җимешедер.

Бүгенге яшь җырчыларга килсәк, алар моны бәяләп, кадерен белеп бетермиләр шикелле. Оригиналь, яңа җыр дип, колакка ятышсыз такмаклар җырласалар җырлыйлар, әмма халык җырлары кебек олы рухи хәзинәбезгә сирәк мөрәҗәгать итәләр. Әгәр күтәреп карасаң, күпме җырларыбыз онытылып, башкаручысын көтеп ята. Юк-бар өчен тарткалашып гомер уздырганчы, кайбер яшь җырчыларыбызга бәхетне мин әнә шул Сез кадерен белгән рухи хәзинәбездән эзләргә тәкъдим итәр идем...

Кичерегез, хатым озынга китте бугай. Шулай да бер хикмәтне сөйләмичә кала алмыйм.

Кайсыдыр мәмләкәттә шагыйрьләр поэзия бәйрәменә барырга җыелганнар. Кеше күп, поездда буш урыннар аз икән. Үзара ызгыш, тарткалаш киткән. Ниһаять, кайсы кая эләгеп, поездда китеп барганнар. Рельслар арасында моңлы бер кыз гына торып калган.

— Син кем, нишләп монда басып торасың? — дип сораган аңардан станция эшчесе.

— Мин — Поэзия, — дигән кыз, дымсу күзләрен һаман ераклаша барган поезд ягына төбәп. — Утыра алмадым...

Әлеге кыз урынында нигәдер мин бүген моңны, халкыбыз моңын шәйлим сыман. Моңыбызны шул хәлгә калдырмыйбызмы без?

Сәхнә йолдызлары булырга дәгъва кылучылар күп бүген. Булсын. Һәр йолдызның үз яктылыгы, күктә һәр йолдызның үз урыны бар, һәммәсенә дә урын җитә анда. Тукай әйтмешли, очсыз-кырыйсыз күк бит ул! Тик җан яктысын, йөрәгеңне югалтмаска кирәк. Иң мөһиме шул. Сез дә шул фикердәдер дип беләм, Әлфия апа...

*«Шәһри Казан»*
*16 октябрь, 1993*

**ЛӘЙЛӘ ДӘҮЛӘТОВА**

# «Бәхет — ир белән тору гына түгел…»

Мәшһүр җырчыбыз Әлфия Авзалова бүген ни хәлләрдә ята икән? Әйдәгез, үзеннән сораштырып карыйк әле.

— Әлфия апа, хәлләрегез ничек?

— Аллага шөкер. Әле күптән түгел Актаныштан кайттым. Икенче Швейцария инде. Хәтта ял йорты эшләргә кирәк анда. Ямь-яшелгә төренгән бит безнең як. Кипр кебек утрауда утырамыни. Кипрны да күрмәгән булыр идем — икенче кызым Зөлфия шунда яши. Кияүне сәүдә эшләре буенча шунда җибәрделәр. Кызым артистлыкка укыган иде. Ә беренче кызым Алабуга институтын бетереп, төзүчеләр институтында эшли.

— Үзегезне бай дияр идегезме?

— Бай түгел, мин — урта хәлле крестьян. Иркенләп түгел, чамалап кына яшисең инде.

— Бүген хөкүмәттән күпме акча аласыз?

— Пенсияме? 740 сум. Аңа гына карап торып булмый. Беренче кызыма да ярдәм итәм — хезмәт хакы азрак. Үлгән сеңлемнең дә алты баласына кулдан килгәнчә булышам. Тормышлары авыррак. Менә шулай. Минем гаилә бик зур ул, сөйләп бетерерлек түгел.

— Бер концерттан күпме керә?

— Күпме бирәләр инде.

— Мәсәлән?

— 500 сум. Аннан артыгын алып буламыни аның?

— Ничек уйлыйсыз, җырчыларга хөкүмәт ярдәм итәргә тиешме, әллә байлармы?

— Байлардан соравы бик авыр бит. Менә мине һәр шәһәрдә, һәр районда зурлап каршылыйлар. Ләкин ничек оялмыйча сорыйсың алардан?

— Эстрадада сезне иң гаҗәпләндергәне нәрсә?

— Гел «яратам» дип җырлаулары. Барам-кайтам, килдем-киттем, мин сине агач төбендә көтәм... Эчтәлекле җырлар юк. Гөлшат Зәйнашева сүзләре түгел инде.

— Яшьләрдән кемне югары бәялисез?

— Ирләрдән — Салават. Бик мәхәббәтле бит. Җырчы — багана кебек басып җырлау гына түгел ул. Тавыш, моң гына да түгел, аны тапшыра белергә кирәк. Гәүдәң, сөягең дә һәр сүзеңне әйтеп торырга тиеш. Халыкны яулап ала белү кирәк. Ә Салаватта бары да бар. Ул безнең йолдыз һәм шулай булачак та, чөнки үз өстендә эшли. Машинада чапса да, тәгәри-тәгәри ярышларда катнашса да, яңа җыр өйрәнә.

— Ә хатын-кыз җырчылар?

— Хәния белән Зәйнәп ошый. Бүтән җырчы юк та. Кылдый-былдыйлар күп инде ул. Алар бит бөтенесе бертөсле.

— Яңа җырлар өйрәнәсезме?

— Һәрвакыт өйрәнәм. Күбрәк табигать, матурлык турында җырларга яратам. Ничек җырламыйсың матур авыллар турында?! Әле Әлдермешкә барган идем, анда да йортым бар. Андагы матурлык, байлык, пөхтәлек! Сукмагында да асфальт. Әлдермеш турында хәзер мең җыр язарлык. Элек урамының бер ягыннан икенчесенә чыгарлык түгел иде. Концертлар белән баргач, шаярып кычкыра идем, карета бирегез әле, йөзеп кенә чыгып булмас микән клубка, дип.

— Әлфия апа, иртән уяну белән күңелегезгә нинди уй килә?

— Ашау турында уйламыйм, кием турында уйламыйм. Фатирым да шикарный. Үзегез күрдегез, безгә милиция аша гына кертәләр. (Без Әлфия Авзалованың фатирында сөйләшәбез. — *Л.Д.*). Президентка рәхмәт. 60 еллыгыма менә дигән фатир бирде.

— Моңарчы кайда яшәдегез соң?

— Бер бүлмәледә. Башта ул дүрт бүлмәле иде. Кызларыма бүлеп бирдем дә үзем бер бүлмәледә калдым. Алай бик кыен булып чыкты. Кунаклар килә, йокларга да урын юк. Минтимер Шәриповичка хәлне аңлатып кына бирдем дә, менә дигән фатирлы булдым. (Кухнясында Кашаповлар бүләк иткән затлы суыткыч балкыса, Әлфия апаның түшендә шул ук эшмәкәрләр биргән алтын чылбыр, ә бармагында Салават киертеп куйган зур бриллиант кашлы йөзек ялтырый.)

— Сезне нәрсә шатландыра?

— Балаларым, оныкларым. Һаман да тавышым, халкым бар. Әле гастрольләрдән кайттым. Халык шыгрым булды.

— Ә нәрсә борчый сезне?

— Әзрәк авырып алган идем. Рак больницасында яттым. Бик куркытты. Рифкать Таҗиев дигән врач җайлап кына, 15 нче больницага барабыз, дигән булып, икенче капкадан гына алып керде анда. Шулай да капкадагы язуны укып өлгердем, анлык кына белем бар бит. Тамагымда ярты килолы шеш бар иде. 20 минутта аякка бастырдылар. Шуннан соң 150 концерт бирдем. Сәхнәгә чыккан саен Ходай Тәгаләдән сорыйм: «Тел ачкычы бир, исәнлек бир, кан басымнарым күтәрелмәсен иде, халкым яратсын иде», — дип.

— Әлфия апа, мәңге яшь калу серен әйтегез әле?

— Хәлдән тайганчы чапмаска, вакытында йокларга, ашарга, эчмәскә кирәк. Әлфия эчә-исерә дип һаман да сөйлиләр. Андый нәрсә белән гомергә мавыкмадым. Ә кунакта 30–50 грамм тоту эчүмени ул?

— Сезнең хакта, чыннан да, күп гайбәтләр йөри шул.

— О-о-о! Әле Илһамга да зарланган идем. Килер бер вакыт, телгә дә алмаслар, димәк, кемгәдер син кирәк, ди.

— Мәхәббәт хәлләрегезне дә сорыйм әле?

— Беренчесе белән кавышмадым. Яратмый гына чыгып алдым иргә. Соң, мәхәббәтләр булды инде ул. Берәү булды, икәү... Ләкин онытыла икән ул мәхәббәт. Менә бүген дә әйбәтрәк, матуррак, үземә тиң бер кеше килеп андый-мондый матур сүзләр сөйли икән, шунда да мәхәббәт туарга мөмкин.

— Сез бәхетлеме?

— Бик бәхетле. Бәхет — ир белән тору гына түгел бит. Нинди ирең була бит. Ә мин иң бәхетле җырчы. Кем җырлаган 45 ел? Әле һаман да чакыралар. Төмәндә, Ленинградта көтәләр...

*«Татарстан яшьләре»*
*1993*

**НӘСИХ ТАҖИЕВ**

# «Миннән дә бәхетле җырчы юк!»

— Әтиебез гомере буе көтүче булды безнең. Бик матур җырлый иде. Көтүдән җырлап кайтканын әллә кайлардан ишетеп торыр идек. Эчә иде шул. Без өйдә өч бала — әниебез үләр алдыннан гына тагын бер кыз тапты. Баладан соң ук тиф белән чирләп китте. Һәм безне мәңгелеккә авыр язмыш кулына тапшырып калдырды. Миңа нибары биш кенә яшь иде әле ул чакта.

Әни үлгәч, эти тагын да катырак эчүгә сабышты. Аннан сугышка китеп югалды...

Фәкыйрьлектә, чит-ят кулларда узган һәм югалган балачак. Әтиләре Әлфиянең күңеленә моң иңдерсә дә, тормыш терәге булалмаган шул. Әнисе артыннан ук яңа туган сабый үлгән. Әлфия сеңлесе Флюра белән баштанаяк нужа эчендә калган.

...Актанышта яшәүче апалары, әнисенең сеңлесе, ятим-нарасыйларның хәлен ишетә һәм, башкорт ягыннан килеп чабата сатучы татарларны туктатып:

— Зинһар өчен, Әлем авылына барып чыксагыз, шул сабыйларны алып кайтыгыз әле, — дип ялвара.

...Кышкы зыкы суык чак. Чанада өстенә тун кигән кешенең дә теше тешкә тимәс көннәр. Башкорт ягы чабата «сәүдәгәрләре» чанасында саламга күмелеп яткан ике гөнаһсыз сабый юл бара. Менә алар Актанышка да килеп җитәләр. Апасының иске булса да өе җылы.

— Ничекләр генә катып үлмәдегез, балалар, — дип каршы алган апасының җылы мөгамәләсеннән җылынырга да өлгермиләр, өй түрендә торaташ сыман басып торган җизнәләренең салкын карашы урамдагы зәмһәрир суыктан да битәррәк җаннарны куыра. Утырыгыз диюче дә юк. Апасы белән җизнәсе бала күргән кешеләр түгел шул. Бәгыре өтелгән бер гөнаһсыз сабый шул чакта: «Бу җизнәкәйне гомеремдә дә күрмәсәм иде», — дип уйлап куя. Ходай Тәгалә аның шушы ялваруын ишеткәнме, әллә язмыш шаукымымы — җизнәсе дә, беренче көннән үк китеп, сугыштан әйләнеп кайта алмый, яу кырында ятып кала.

Ятимлекнең уң канаты булган фәкыйрьлектән күрәселәре алда көткән икән аларны. Апаларының җылы канаты астында тернәкләнергә өлгерә дә алмый калалар. Шул нарасыйлар ачтан үлмәсен дип амбардан ыштырына кыстырып кайткан икмәге белән апасын тоталар. Сугыш елларының кырыс законнары аны төрмәгә озата. Ниләр генә күрми бәләкәй Әлфиянең балачак хәсрәтләре белән шыгрым тулы башкайлары. Капчык тотып хәер дә сораша. Үзләре шикелле үк өй тулы ач балаларны шунда очрата һәм бәгырьләре телгәләнә.

Аннан — балалар йорты. Апасы төрмәдән кайтканчы — алты ел буе — бер йортка тупланган ачы язмышлар белән күзгә-күз очрашып яши. Шул чакта ук җыр аның өмет нурына әверелә. Балалар йортында иң чая, үткен һәм җор телле кызларның берсе булып үсә. Моңы белән күпләрне әсир итеп өлгерә. Шул чакта ук сәхнә җене кагыла, балалар театрында уйный, җырлый.

Фәкыйрь көтүче кызы җырчы Әлфия Авзалова булып үскәнче михнәтнең, ятимлекнең, хәерчелекнең бөтенесен күрергә, татырга насыйп булган икән.

— Шуңа күрә дә дөньяның тәмен, ямен белеп яшәргә тырыштым. Беркайчан да масаймадым, дан-шөһрәткә алданмадым. Күзгә каршына басам да үз-үземә: «Масайма, Әлфия, бетле баш идең, кем булдың», — дип кат-кат кабатлап торам, — диде ул чәй эчә-эчә сөйләшеп утырган чагыбызда, уенын-чынын бергә кушып.

Татар эстрада сәхнәсе беркайчан да олы талантларга мохтаҗ булмады. Кырык ике ел элек Әлфия Авзалова көр тавышы белән халык күңеленә килеп керде. Яңа кабынган йолдыз сыман, көннән-көн яктырак янды. Үз тавышы, үзенә генә хас моңы, халыкчанлыгы белән тамашачыларны җәлеп итте. Борынгы халык көйләре дә, заманчалары да аның репертуарын тулыландырып торды. Иске җырларга яңа рух өстәде, күкрәк тулы тавышы белән үзәкләрне өздереп җырлады ул.

— Халкым үз җырчыларын бик ярата. Кая гына барып керсәк тә: «Әлфия апа!» — дип күтәреп каршы алалар. Миннән дә бәхетле җырчы бармы икән бу дөньяда! Юктыр, дим. Озын гомерле җырчы мин. Кырык елдан артык халыктан өзелмәдек, шыгрым тулы залга җырладык...

Сәхнәдә «картая белмәс йөрәкле» Әлфия Авзалова көйне көйгә ялгап җырлый да җырлый. Моңлы көйләрне сузганда, бәлки, ачы язмышлы балачагы калган Әлем авылын, дәртле җырларга күчкәч, шул михнәтләрне күрергә насыйп булмаган, әниләренең канат астында бәхетле булып үскән ике кызын күз алдына китерәдер. Артист сәхнәдә бар дөньясын оныта, дисәләр дә, җыр моңландыра да, уйландыра һәм көлдерә дә ул. Йөрәккә үтәрлек итеп башкаручы булганда!

— Әгәр дә галәмгә татар җыры белән сәфәр чыгарга туры килсә, үз ракетагызга бүгенге җырчыларыбыз арасыннан кемнәрне сайлап алыр идегез?

— Бер ракетага гына сыймас идек без. Талантлы яшьләр күп бит хәзер. Хәмдүнәне, Зөфәр белән Зәйнәпне, Хәнияне, Асафны, Хәйдәр Бигичевны, Венера Ганиева белән Зөһрә Шәрифуллинаны... Үзешчәннәрдә дә талантлылар бик күп. Җырны да таба беләләр.

Тик минә күңелне әрнеткән яман чир йокты яшьләребезнең күбесенә. Халык ярата дип, биш-алты еллык гомере булган такмак-җырларга күчтеләр. Борынгы җырларыбызны халык күңеленә кире кайтарырга кирәк иде. Моның өчен Илһам Шакиров та гел борчыла. Ә безнең репертуардан шул озын көйләр әле дә төшми бит. Үлемсез җырлар алар. Кеше дә яратып тыңлый. Әле дә сәхнәдән күз яшьләрен яулык читенә яшереп кенә сөртеп утыручы әби-апаларны еш күрәбез һәм шул күз яшенә сөенеп туя алмыйбыз.

Ә минә бүгенге яшьләрне елатып булмый. Аларның кайгы-хәсрәт күргәннәре юк. Такмак тыңлап күңелләре була. Урысның җыр сәнгате бөтенләй бетеп бара, әле безнең Аллага шөкер. Җиңел жанр күп таралды, талантлы, тавышлы яшьләребез шул юлга басып югалалар. Аннары мал артыннан куучылар да ишәйде.

Җырчының сәхнә гомере кыска була, диләр. Ышанасы килми. Әлфия Авзалованың моңлы сандугач тавышын үсмер малай чактан ук тыңлый башлаган идек. Бүген без дә сакал үстерер ирләр яшенә җиттек бугай. Ә ул һаман, һаман җырлый. Яшьлегендәге дәртле, аһәңле тавышы бераз басылса да, моң җитәрлек. Озын гомерле һәм бик бәхетле сандугач ул безнең Әлфиябез. Тыңлагыз, Авзалова җырлый!

*«Юлдаш»*
*Ноябрь, 1994*

**РӘМИС АЙМӘТ**

# Казанны шаулаткан бер көн

Бенефис! Бенефис!

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры үзенең гомерендә нинди генә иҗат кичәләре, очрашулар күрмәгән. Шушы көннәрдә генә әлеге бинада тагын бер тарихи вакыйга — Татарстан Республикасының халык, Русиянең атказанган артисты, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Әлфия Авзалова бенефисы булып узды.

Актанышның сибелгән авыллары буйлап йорттан йортка хәер сорап йөргән ятим сабый, балалар йортында берүзе «концерт» куйган чакларында, шундый көн килер дип уйладымы икән? Барлык гомере, һәр сукмагы, һәр сулышы газиз халкы белән үткән аның.

Бүген аны халык зурлый. Бүген ул чәчәкләргә уралган сәхнә түрендә — тәхеттә утыра. Ул — ханбикә. Ул — Җыр әнкәсе. Ә дуслары күпме аның? Хәтта ерак Камчаткадан да аны котларга килгәннәр. Әнә шуңа күрә дә Айрат Арсланов: «Читтә яшәүче милләттәшләребезнең һәрбер күзәнәгенә моң алып баручы илче ул», — диде.

Бенефис хуҗасына җыр сәламнәрен юллаучы Х.Тимергалиева, Р.Маликов, З.Шәрифуллина, Г.Сафиуллина, А.Вәлиев, С.Фәтхетдинов, И.Биктаһиров, Н.Мөхәммәтҗанов, нәфис сүз остасы Р.Сабиров — барысы да заманында Әлфия Авзалованың олы ярдәмен тоеп зур сәхнә түренә күтәрелгән сәнгать осталары. Ул көнне аларның Әлфия ханымга әйтәсе рәхмәтләре чиксез иде.

Залда республиканың премьер-министры М.Сабиров белән Югары Совет Рәисе Ф.Мөхәммәтшинның булуы да җырчыга җөмһүриятебез җитәкчеләренең зур хөрмәте дигән сүз.

*«Шәһри Казан»*
*1994*

# «Мин сезнеке инде...»

— Әлфия ханым, күп йөргән күп күрер, ди. Соңгы вакытларда кай тарафларда йөрдегез, нинди маҗараларга тап булдыгыз?

— Кай вакыттан башлыйм икән... Безнең группа Зәй районында йөрде, егерме сигез концерт бирдек. Бөтен районны шаулаттык, рус авылларында да чыгыш ясадык. Руслар да шаккатты.

Аннан соң Ульян, Төмән, Свердлау, Самара якларында булып кайттык.

Тамашачыларым бик сагынган икән үземне. Яше-карты дигәндәй... Концертлар гөрләп үтте. Программа яшьләрнең дә, өлкәннәрнең дә күңеленә хуш килерлек.

— Группагыз белән дә таныштырсагыз иде.

— Минем белән икенче тавышка Сания Габидуллина җырлый. Аның ире — музыкант Кәрим Габидуллин. Баянчы-җырчы Равил Закиров бар, җырлавын да бик яратам.

Менә шулар белән Омскида булып кайттык. Үзләре чакырып алдылар, егерме бер ел булмаган идек. Мең өч йөз кешелек залга ике көнлек билетлар сатылып беткән... 300–500 чакрым узып, ерак шәһәр-авыллардан килүчеләр дә бихисап.

Шулай итеп, беренче концертны башладык. Биш-алты җыр җырлап өлгердемме-юкмы, белмим, бервакыт миңа «пес-пес» диләр. Карасам... этле милиция. «Ханым, концертны туктатыгыз!» — диләр.

Нишлисең, туктаттык инде. Кемдер бу бинага бомба куелды дип шалтыраткан икән. Тиз генә залны бушаттылар. Белмим инде, әллә татар концертын өзәргә теләүләре булды, әллә икенче катта җыелышкан депутатларны куркыттылар — безнең концерт өзелде. Халык шау килә. Икенче көнне Зур концерт залында өч сәгатьлек концерт куйдык. Тамашачының безне һич тә сәхнәдән чыгарасы килми, алкышлыйлар, рәхмәт әйтәләр. Шул залда эшләүче марҗалар шаккатты, аларның мондый хәлне күргәннәре булмаган.

Икенче көнне поездга озаттылар. Ул пешеренгәннәр, ул әзерләнгәннәр...

Юлга чыктык. Барабыз. Килеп җиттек Петропавловскига. Утырды халык — күбесе безнең якташлар. Шәһәрләрендә ут юк, тәүлегенә бер сәгать чамасы гына бирәләр. Ашны урамнарда, ишегалларында учаклар ягып пешерәләр икән. Елый-елый сөйләделәр. Туган якларына сукыр лампа, керосинка, керосин алырга кайтулары икән.

Бер казах гаиләсе утырды. «Урамда эт тә калмады, ашап бетердек», — диләр...

Килеп җиттек Павлодарга. Анда да шул ук хәл. Шаккатып кайттым.

Без оҗмахта яшибез икән! Читтәге милләттәшләремнең авызында бер үк сүз: «Сезнең Шәймиевегез бар бит», — диләр. Аллага шөкер! Булдым Биектауда, Әтнәдә. Авылларга асфальт юллар килгән, газ кертәләр. Мәчетләр төзелә. Кирегә китмибез бит, үсәбез. Эшләгән кешегә яшәргә җай бар бездә, зарланышмыйк.

— Әлфия ханым, гаилә хәлләрегез ничек?

— Аллага шөкер, үз кызларым да, ятимнәрем дә үсеп кеше булдылар. Олы кызым Алабугада пединститут тәмамлаган иде. Инде үзенең ике баласы үсеп җитте, кызы юридик факультетта укый. Зөлфиям театр училищесын тәмамлады, ике ел минем белән эшләде. Кияүдә, ике баласы бар, ире — фәннәр кандидаты, әлегә Кипрда яшәп торалар.

Дошманнарым да булды, хәзер дә бар. Йә, әйт әле, кайсы татарның унөч телдә җырлаганы бар? Ә мин җырладым. Ә бит мин укыган җырчы да түгел. Үз-үземне үстердем. Классикларны тыңладым. Сүзенә, теленә карап тавыш алдым. Мин бит альт тавышлы, шуңа да карамастан «до, ре, ми»ны алдым. Төрле тональностьтан җырласаң, халык арымый, синең белән җырлый башлый, тәне җырлый.

Миңа Фәридә Кудашева бәя бирде. «Әлфия, мин синең кебек җырлый алмыйм», — диде. Ул — бөек җырчы, әмма монотонно.

Бүген генә ул дүрт нотадан торган тавышлар күбәйде. Бөтен җырлары бер нотадан башлана.

Мин тавышымны күкрәккә куеп җырлыйм, шуңа күрә арымыйм да. Көнгә өч-дүрт концерт бирәм.

Их, элегрәк русча җырларга өйрәнмәдем. Мировой җырчы буласы идем бит! Венгрның «Журавли» романсын җырлап җибәрсәмме?! Диапозон да бар. Син инде татар түгел, венгр чегәне...

Безнең халык — бик әйбәт халык, әмма зур кимчелеге бар — бердәм түгелбез. Дус дигәнең дә сиңа киртә куя.

Хәзер иң популяр җырчы — Салават. Ул — минем стильдәге артист, җырлавын үлеп яратам. Хәзер андый артистларга рәхәт, халык аңлый.

Ә безнең чорда? Зифа апа ике кулын тотып, туп-туры басып җырлады, Гөлсем апа да шулай. Ә мин алардан соң чыктым. Темпераментлы булдым, биеп тә җибәрдем. «Әлфия Авзалова эчеп чыккан» дигән гайбәтләр дә шуннан туды. Хәзер дә ишетәм. Аны бит халык әйтми, көнчел артистлар чыгара.

Әмма мин бирешмәдем. Җырлавымны белдем. Яһүд тикле яһүдне җырым белән елаттым.

Минем грамотам юк. Әгәр акылым булмаса, әллә кайчан төшеп калырга тиеш идем.

Ә Салават молодец! Король! Ул әле җырлаячак. Егет нык эшли.

Чаллыга баргач гел аларда торам. Үз бүлмәм бар. Ишек өстенә «Авзалова бүлмәсе» дип язганнар... Оҗмахта яшиләр.

— Сез бүгенге яшь җырчылар хакында нинди фикерләр әйтер идегез?

— Безнең нинди яшь җырчыларыбыз бар соң? Көндез — базарда, кич — эстрадада, телестудиядә... Тавык кебек җырлаганы да чыга, азрак аруругы да.

Кем күзәтергә тиеш бу эшне? Мин күзәтә алмыйм бит, мин җырчы гына.

Өч куплетлы җыр гел «яратам» дигән сүздән генә тора. Әле анысын да йодрык төеп җырлыйлар. «Яратам» сүзе шулай әйтеләме?

Эльвира Хәйруллинаның тавыш тембрын яратам, оригиналь. Әмма аны үстермәячәкләр. Аның кебек тагын берничә яшь җырчы бар, аларга да киртә куячаклар.

Мин кайбер җырчыларга карыйм да: «Эх, азрак кына ярдәм итеп җибәрсәң иде моңа», — дип уйлап куям.

Заманнар үзгәрде. Тәртипле, әйбәт Президент сайладык. Ләкин аның эше бездән башка да күп. Ә мәдәният министры нәрсә карый?

— Җырны тудыручылар хакында да берничә сүз әйтсәгез иде.

— Мин үзем Гөлшат Зәйнашева сүзләренә яшим. Гомер буе шулай булды. Роберт Миңнуллинның язганнарын яратам. Композиторлардан Мәсгут Имашевка еш мөрәҗәгать итәм.

— Гөлшат апа белән сез якын ахирәтләр дә бугай...

— Өч дустым бар минем: Гөлшат, Гөлсинә, Зөләйха. Гомерем буе шулар белән яшим. Дусларны сайлый белергә кирәк. Акыллы белән акыллы картаясың.

— Соңгы елларда чит илләргә гастрольләр дә күбәйде. Сезнеңчә ничек — чит илләргә чыгып татар сәнгатен күрсәтү хокукы кемнәргә бирелергә тиеш?

— Иң элек Илһам абыегыз белән Әлфия апагыз барырга тиеш иде. Халык җырлары белән. «Пи-пи-папа»ны алар үзләре дә бездән шәбрәк җырлыйлар.

Мине бервакытта да чит илгә гастрольләргә алмадылар. Дөресен сөйләшкәнем өчен.

Үз акчама Грециягә, Төркиягә, Франциягә, Германиягә... тагын әллә кайларга бардым. Балаларымның ризыгын кисеп бардым. Ни өченме? Тегендә-монда булып кайттым, дип сөйләнер өчен. Ә чит илгә һич исем китмәде.

Әле кызларым янында Кипрда булдым. Тәмам туйдым, гарык булдым. Мине анда беркем танымый, ни ямь бар?

Ә минем Казаным! Казаныма мәхәббәтем чиксез! Ямашев проспектында яшим мин. Унбиш көнгә гастрольгә китсәм, кайтуыма яңа йорт калыккан. Ә ризык? Киштәсе белән.

Олыгайгач ялгыз яшәве кыенрак икән. Яшь чакта егетләр күп була бит ул, уйланылмый. Бергә утырып чәй эчәргә, фатирдаш булып яшәргә бер кеше кирәк икән.

— Әгәр кемдер килеп сезнең кулыгызны сораса?..

— Тормыш кору өчен бер-береңне нык белгән кеше кирәк. Хатын аерган кеше кирәкми, рәтле ирдән хатын кусаң да китмәс. Эчкәне дә кирәкми, ә эчмәгән кеше вакчыл була. Ярар инде, сеңлем, насыйп булса, миңа шул хур егетләре булыр инде.

Хәзер инде бердәнбер теләгем — исән-сау халкыма хезмәт итеп, олыгайган көнемдә халкымнан хөрмәт күреп яшәсәм иде.

Алла боерса, Яңа елда, Чыршы бәйрәмнәре үтүгә, Казанда Тинчурин театрында концертларымны башлыйм. Мине яраткан тамашачы килер дип ышанам.

*«Шәһри Казан»*
*1996*

# «Чибәр түгел, мәхәббәтле булдым...»

### Ә.Авзалова хатларга җавап бирә

* * *

Ак биләүгә биләп үстерергә насыйп булмаса да, бәхете булсын, дип теләгәндер кызына Миңьямал апа. Бәлки әле, ни күрәчәге язылган язмыш дәфтәрен укыса, сабыен тапмаган да булыр иде... Туганда ук елап та, җырлап та тәүге аваз салган сабый бүген Русиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Әлфия Авзалова булып үсеп җитте. Шагыйрьләрчә әйтсәк, «Тәңребездән иңгән сандугач»ның тагын да тезеп китәрлек исемнәре күп. Ул әни дә, әби дә, әннәкә дә һәм мәңге яшь безнең Әлфиябез дә. Әлфия исеменең татарча тәрҗемәсе «бердәнбер» дигәнне аңлата икән. Әлфияләр күп бит, диярсез. Әмма «Мәгърифәт» газетасы укучылары алдында җавап тотучы Әлфия Авзалова бердәнбер:

Йолдызлар арасында да
Унга түгел — йөзенә бер...
Йөз дә түгел, мең дә түгел —
Әлфия апа — үзенә бер!..

— Әлфия апа, Илһам абый әле дә сәхнәдә җырлап йөри. Сез кая югалдыгыз?

*Хәлим Алимов,*
*Октябрь районы Яңа Иглай авылы*

— Дөрес, Норлат, Октябрь районнарына ун еллап барганым юк. Җыенам. Килмәвемнең сәбәбе — вакыт җитми. Күптән түгел генә Екатеринбург, Тольятти, Самара, Сембер шәһәрләрендә гастрольдә булып кайттым, өстәвенә гаилә мәшәкатьләре. Бер кызым — Мәскәүдә, берсе Казанда яши. Шуңа әле Мәскәү, әле Казан, әле Мәскәү, әле Казан.

* * *

— Танылмаган Әлфия Авзаловага нинди киртәләрне җиңәргә туры килде?

*Вафина Гөлия,*
*Бөгелмә педучилищесы*

— Ул чакта минем зу-у-ур җырчы буласым килде. Хыялым, чит ил җырларын өйрәнеп, «мировой» җырчы булу иде. Бөтен дөнья телен өйрәнмәсәм дә, бар көчемне куеп тырыштым, хыялымны чынга ашырырга омтылдым. Өч ай эчендә мине Ирма Яунзем исемле укытучы 15 телдә җырларга өйрәтте. Менә шулай теләк, хыялларыма үзем сорап, әкрен-әкрен ирешә килдем. Мин бит матур, чибәр хатын түгел. Матурлар алар иkenче яклап үсте, ә миңа, матур булмагач, андый «поддержка» гомергә тәтемәде. Акыллы булдым, мәхәббәтле булдым...

* * *

— Көн дә тормыштан зарланабыз. Бу зарлануларны Сез ничек кабул итәсез?

*Хәлим Алимов,*
*Октябрь районы Яңа Иглай авылы*

— Нәрсә дип әйтим... Элек эшләгән акчам «күп» булганга, ашарыма да, балаларымны ашатырга да җитми иде. Хәзер дә әллә ни күп түгел, ләкин ашарга да, кияргә дә җитә. Мин хәзерге заманны мактыйм. Бу заман миңа ошый, зарланмыйм. Кирәкми миңа элекке заман!

* * *

— Беренче мәртәбә ничә яшьтә «үлеп» гашыйк булдыгыз?

*Яңа Кәкреледән исемсез хат*

— 16 яшьтә, ләкин андый гыйшыклык тиз уза, ул яшьлек гыйшкы гына. Үз гомеремдә иң яратканы Йосыф (Җасаф) Вәлитов атлы иде. Бер-беребезне 20 ел яратыштык. Ул мине кияүгә дә сорады, тик 8 яшь аерма, өстәвенә минем ике кызым да бар. Үземә бик кыен булса да, Йосыфны өзелеп яратсам да, мәхәббәтен кире кагарга мәҗбүр булдым. Хәзер инде ул гаиләсе белән бик бәхетле гомер кичерә, чын дусларча аралашып яшибез.

* * *

— Кәефегез даимиме, әллә үзгәрүчәнме?

*Светлана Хәлимова,*
*Бөгелмә педучилищесы*

— Шаян мин. Шаян булып туганмын, шаян булып китәрмен дә. Муса Җәлил «җырлап үләм» дигән бит, мин җырлап һәм көлеп үләчәкмен.

* * *

— Әгәр дә дөньялар үзгәрми торып, Советлар Союзы бетмәсә, китабыгызны чыгара алган булыр идегезме?

*Имаметдин Газиев,*
*Саба районы Югары Утар авылы*

— Чыгара алмас идем, чөнки дошманнар, аяк чалучылар күп иде. Хәзерге заманга, Татарстаныма мең рәхмәтлемен. Китабымны чыгарырга булышкан якташым Илгиз Бариев кебекләр булганда тагын берне язам әле, Алла боерса. Бәлки, яңа спонсорлар да табылыр дип өметләнәм.

* * *

— Әгәр минем кулыма, могҗиза булып, әкияттәге Галәветдиннең серле лампасы эләксә, лампаны ышкыр идем дә: «Җырчы Әлфия Авзалованың Балык Бистәсе районындагы Күгәрчен мәдәният сараенда биргән концертын күрсәттер, җырласын шул вакыттагы кебек, тыңласын кеше рәхәтләнеп», — дип боерык бирер идем. Ә Сез җенгә нинди эш кушар идегез?

*Марсилә Садыйкова,*
*Балык Бистәсе районы*

— Тылсымы да, җене дә бардыр, ләкин мин гомерем буе ышандым бер Аллама. Йә Раббым, исәнлек бир якыннарыма, балаларыма, йә Раббым, тавышларым яхшы булсын, дип сорадым. Сәхнәгә чыгар алдыннан иң беренче, бисмилламны укып, Аллаһы Тәгаләкәем, үземне халкыма мәхәббәтле күрсәт, тел ачкычлары бир, йә Раббым, Аллам, дип ялварам. Коръәндә дә бит: «Сорагыз гына, бирәм», — дип әйтелгән. Исәнлегемне дә, бәхетемне дә сорадым. Шөкер, балаларым да бәхетле, үзем дә ялгыз түгел — күпме халкым, тамашачым бар.

* * *

— Бүгенге җырчыларның сәхнәдә конферансьега әйләнеп китүенә ничек карыйсыз?

*Фирая Каюмова,*
*Бөгелмә педучилищесы*

— Җырлый белмәгәннәрнең сөйләшеп вакыт үткәрәселәре килә. Әле алар сөйли дә белми бит. Сөйләр сүзләре дә юк. Нәрсә күргән соң алар тәмле ризыктан башка? Шуңа сәхнәдән дә тиз югала андыйлар.

— Мәктәптә укыганда кем булырга хыяллана идегез?

*Миләүшә Нәсмиева,*
*Минзәлә районы Дәвек урта мәктәбе*

— Колхозчы. Валлаһи, колхозчы булырга теләгән идем. Гомергә дә Актанышны калдырып китәрмен дип уйламаган идем.

* * *

— Көзгегә күз салгач, башыгызда нинди уйлар өере барлыкка килә?

*Мөршидә Хәнәфиева,*
*Казан*

— Күпкә картайдым микән? Җыерчык кермәде микән дип карыйм көзгегә. Башка артистлар кебек, операцияләр ясатып, ясалма яшьлеккә кайтмасам да, шөкер, керми, курка җыерчык миннән.

* * *

— Көтүче Авзал кызын ничек дип үртиләр иде?

*Чулпан Фәрхетдинова,*

*Түбән Кама районы*

— Маймыл. Шимпанзе дип.

* * *

— Әлфия апа, Сезнең китабыгызга карата сорау бирәсем килә. Аны үзем җыйдым (хәреф җыючы булып нәшриятта эшлим). Җыюымнан туктап, кульъязмаларыгызны укып чыктым. Исләрем китеп, үз-үземә сорау бирдем: «Ничек итеп Әлфия апа кешеләргә булган ышанычын югалтмады икән?» Җавабын да таптым: тормышында, һичшиксез, яхшы, изге җанлы кешеләр юлдаш булгандыр. Бу чыннан да шулаймы?

*Фирдәвес Исмәгыйлова,*
*Казан*

— Казанга килгәч тә ике әйбәт кеше очрады. Иң беренчесе — шагыйрәбез Гөлшат Зәйнашева, икенчесе — Гөлсинә Сәләхова. Өченчесе — тормыш дустым, Зөләйха исемле. Шушы дусларымны очратуыма мең рәхмәтлемен. Начар иптәшләр булса, бәлки, начар юлдан киткән булыр идем. Җан дустым, кан дустым итеп Гөлшатны сайлаганмын бит. Ул яхшы булгач, мин дә яхшы булып чыктым. Элеккеләр дә: «Дустың үзеңнән яхшырак булсын», — дигән.

* * *

— Сезгә өч мөмкинлек бирелсә: яшьлегегезгә кире кайту, чит илгә китү, яңа фатир — шуларның кайсын сайлар идегез?

*Хәлим Алимов,*
*Октябрь районы Яңа Иглай авылы*

— Иң беренче: чит илгә китмим, гомергә дә. Минем хәтеремә бабайлар сүзе сеңеп калган: «Чит илгә китеп солтан булганчы, үз илеңдә олтан бул», — дигән, һәм дөрес тә бу. Бер кызым гаиләсе белән чит илгә китеп яшәмәкче булып тора. Мин әйттем, аңлаттым. Сез мине мәңге күрә алмаячаксыз. Ул якка муенымны борып та карамаячакмын, дидем. Үзем гомер буе байлыкка, акчага алданмадым. Кирәкми бер байлык та. Миңа кирәк исәнлек-саулык, сәламәтлек, тынычлык, үз җиремнең туфрагы. Ә яшьлегемә кайтыр идем. Олыгайганыңны тою шатлык түгел икән. Балачакта бит кайгы-хәсрәтне аңламаган. Үз күңелеңне күреп, тик уйнап йөргән, ә хәзер мең төрле уй. Балалар, оныклар... Гел өйрәтәм, минем кебек булыгыз, бәбекәйләрем, дип торам.

Фатир мәсьәләсенә килгәндә, кыенлык кичермәдем һәм хәзер дә Аллага шөкер.

* * *

— Иң милли, иң моңлы, иң кунакчыл татарлар кайда яши?

*Илшат Лотфуллин,*
*Минзәлә районы Дәвек урта мәктәбенең тарих укытучысы*

— Кайсына барып керсәң дә, күтәреп кенә алмый, кунак итә. Ә аерым алганда — Ташкент. Анда елына өчәр барып тордык.

* * *

— Килер бер көн һәм, Сөембикә манарасы кебек үк, Әлфия Авзалова манарасын төземәсләрме?

*Мөршидә Хәнәфиева,*
*Казан*

— Төзелмәс, манара ук төземәсләр. Әмма үлгәч һәйкәл куярлар дип өметләнәм. Дөрес, ул вакыттагы җитәкчеләр минем иҗатны белмәскә дә мөмкин, әмма Кашаповлар, Кәлимуллиннар кебек мөселман яшьләребез онытмаслар. Хәзер үк һәйкәл куябыз, Әлфия апа, тик озын гомерле булыгыз, дип торалар. Рәхмәт аларга.

* * *

— Әгәр президент булсагыз, башлап нинди указ чыгарыр идегез?

*Хәлим Алимов,*
*Октябрь районы Яңа Иглай авылы*

— Әлфия Авзалованың гомергә дә президент булмаячагын беләм бит мин. Хыялланмыйм да. Хатын-кыз эше президент булу түгел. Ул укып һөнәр алырга, кияүгә чыгып бала үстерергә тиеш. Хатын-кыз — өйнең хуҗабикәсе.

* * *

— Беренче мәртәбә сәхнәгә чыккач, нинди хисләр кичердегез?

*Фәридә Камалетдинова,*
*Бөгелмә педучилищесы*

— Курыктым. Сүземне дә бутадым әле. Бүгенгедәй исемдә: «Безнең илнең егетләре сугышларда йөрделәр. Кояш килеп чыкты да җир тишегенә кереп югалды», — дидем дә беттем. Оркыя Ибраһимова миңа карап гармун уйный, шунда әйтеп җибәрсә була бит инде, ул белә бит сүзләрне. Баянистларыбызга шулай да бик рәхмәтлемен. Минем бригадада Кирам Сатиев, Хәйдәр Сафиннар эшләде. Алар репертуарымдагы бөтен җырларны яттан белә иде. Кайчак халык күп еллар җырламаган җырларны сорый, ә минем «отказым» юк. Бер Аллага, бер баянистка тапшырам да җырлыйм.

* * *

— Татар җыр сәнгатенең киләчәге бармы? Ул такмак белән ике-өч ноталы җырга әйләнмәсме?

*Мөршидә Хәнәфиева,*
*Казан*

— Әйтергә дә куркам инде. Кызганычка каршы, моң югалып бара шул. Бер югалса, ак калфак кебек, табылыр микән? Бүген сәхнәгә менгән, кызыл, кара икра ашап үскән яшьләргә каян килсен ди ул моң? Моң ул хәсрәттән, кайгыдан моңлангач туа.

* * *

— Әниләргә иң зур бүләк нинди була?

*Хәлим Алимов,*
*Октябрь районы Яңа Иглай авылы*

— Әниләр өчен иң зур бүләк — бала. Кызың булып яхшы кешегә кияүгә чыкса, малаең булып тигез гаилә корып бәхетле булса — менә шушы була инде анага зур бүләк. Яулык алып бирү, күлмәк алып бирү түгел. Анысы шатлык кына аның, ул вакытлыча гына.

* * *

— Барыбызның да кылган гамәлләре өчен үкенгәне, үз-үзен битәрләгән чаклары була. Ә Сез үкенәсезме?

*Яңа Кәкреледән исемсез хат*

— Мин үкенмим. Чөнки үкенерлек эш эшләгәнем булмады. Ялгышымны вакытында күреп төзәтә идем. Гомерем буе көрәшеп яшәдем. Миңа аяк чалучылар, көнләшүчеләр белән көрәштем. «Ә ничек?» — диярсез. Яңа җырлар өйрәнеп, үземнең тавышымны саклап, һәм җиңдем дә.

* * *

— Кыш, Яңа ел җиткәч, нинди «утларда» янасыз?

*Мөршидә Хәнәфиева,*
*Казан*

— Мин гел 31 декабрь көнен көтеп ала идем. Балаларча шатланып, ниндидер бер дулкынлану кичереп. Нишләптер нәкъ менә быел алай булмады, җанымда нидер китек тоелды.

* * *

— Студентларга бушлай концерт күрсәтер идегезме?

*Хәлим Алимов,*
*Октябрь районы Яңа Иглай авылы*

— Киләм, чакырсыннар гына.

* * *

— Әлфия апа, Сезнең хакта чыккан бөтен мәкаләләрне, фотоларны җыеп барам. Тик китабыгызны таба алмадым.

*Мансур Аймәт,*
*Чүпрәле районы*

— Аны мин үзем дә күрми калдым, алганнар да бетергәннәр. Эшкә дә, өйгә дә шалтыратып сорыйлар. Шуңа күрә нәшриятка тагын өч меңгә заказ бирдем. Озакламый чыгачак. Китапны нәшриятка хат язып та соратырга була.

* * *

— Сез, Алла Пугачева урынында булсагыз, Филиппка кияүгә чыгар идегезме?

*Мөршидә Хәнәфиева,*
*Казан*

— «Никогда» бала-чагадан үземне көлдертмәячәкмен.

* * *

— Әлфия ханым, әгәр Сезне марсианнар үзләренә кунакка чакырса, нинди җыр бүләк итәр идегез?

— Әлбәттә, «Туган тел».

— Әле ачылмаган талантларым да бар, дип әйтә аласызмы?

— Әйталмыйм. Минем бөтен гомерем җыр булды. Февраль аенда хушлашу гастрольләрен башлап җибәрергә уйлап торам. Татарстан, Башкортстанда, Себердә яшәүче татарлар, минем концертларга йөргән тамашачыларым белән саубуллашып, кабат килә алмам дип, соңгы концертларымны күрсәтәчәкмен.

Сорауларым бетте, Әлфия апа, хәзер җинүчене билгеләгез, дигәч, ул: «Яз, бәбекәем, яз, егетләрем мишәрләрдән булмаса да, беренчелек — Мансур Аймәткә», — диде.

Шулай итеп, Әлфия Авзалованың автографлы фотосурәте «Мишәрстанга» очачак. «Ә ни өчен?» дип аптыраучылар Әлфия апаның күңеленә хуш килгән хатны укыгач аңлар.

*Хөрмәтле Әлфия апа!*

*Сез Чүпрәле районының Шылангы авылына концерт белән килгәндә, миңа 13–14 яшьләр тирәсе булгандыр. Аннан соң, 1978 елны, мин авыл мәдәният йортында эшли башлагач, Чүпрәлегә сезнең концерт бригадасы килде. Ә безнең Шылангы авылына колхоз җитәкчеләре, җәен кызу эш вакыты дип, концертны кабул итмәделәр. Мин район мәдәният бүлегенә барып маршрутка керттердем. Бездән 11 км ераклыктагы Яңа Кәкерле авылына барып, Сезне табып, афишалар алып кайттым. Ул чакта Сезнең бригадада, ялгышмасам, Х.Шәйдуллин, баянчы Х.Сафин, биюче Ш.Хисмәтуллин иделәр. Безнең авылда концертыгыз гөрләп үтте. 200 ләп тамашачы иде. Миңа концерт китергән өчен җитәкчеләрдән бераз эләкте. Ләкин мин Сезнең килүегез, матур концертыгыз, якыннан Сезне күрүем белән бик шат идем. Миндә 1978, 1983, 1992 елгы үзем яздырган концерт (магнитофон тасмасында) язмаларыгыз саклана. Сезнең, Әлфия апа, күп концертларыгызны карадым. Эстрадага бик күп яңа җырчылар килде. Алар Сезне алыштыра алмый. Мин Сезнең тавышыгызга мәңге гашыйк.*

*1992 елны концертларыгыз Ульяновск шәһәрендә булды. Минем чакыруым буенча безнең район мәдәният йортында ике тапкыр концерт күрсәттегез.*

*Истәлекләрем бик күп. Ләкин иң кыскасы шул — Сез, Әлфия апа, татар эстрада сәхнәсенең мәңгелек һәм мәңге сүнмәс йолдызы!!!*

Моң чишмәсенең җавапларын М.Җиһан язып барды.

*«Мәгърифәт»*
*20 гыйнвар, 1996*

**ФИРҮЗӘ ҖАМАЛЕТДИНОВА**

# Халыкның нәкъ үзе кебек ул

Йөрәгемдә, хисләремдә
Хушлашам казлар белән.
Алар минем хәлне белми,
Мин аларныкын беләм...

Әлфия апа җырлый. Бу моң, бу тавыш тамаша залындагы һәркемгә таныш. Әнә иңнәренә мамык шәлләрен ябып утырган апалар, маңгайларына тирән сырлар төшкән агайлар, уйнак сабый балалар тын да алмый аны тыңлый. Аларның күбесе монда бик авырлык белән эләкте, керер юллар табып яшьләр сәхнәдән залга коелды, кемнәргәдер этеш-төртеш төркемендә көч сынашырга туры килде.

— Артистлар арасында мин иң бәхетле кеше. Минем халкым бар, — ди Әлфия апа. — Чаллыга бушлай концерт алып килдем. — Һәм өстәп куя: — Кайберәүләргә бушлай да килмиләр, — ди.

Әйе, Әлфия апаның үзе янында Татарстанның халык артисты, Русиянең атказанган артисты, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты кебек олуг исемнәре дә бәләкәй генә булып күренәләр кебек. Аның күңеленә безнең халыкның көчле рухы, бетмәс моңы, гади, халыкчан җорлыгы сыйган. Әлфия апа халыкның нәкъ үзе кебек. Ни кыланса — шул килешә, ни сөйләсә — шул кабул ителә.

Моның сәбәпләре дә, серләре дә нәкъ менә халык арасында гомер итүенә бәйледер. Аның туң чаналарда, җилле машина әрҗәләрендә килеп төшкәнен Татарстанның, элеккеге Союзның кайсы гына авыл яки шәһәр клубларында көтмәделәр икән?

Әнә ул тагын Илһам Шакиров белән Себердән 15 көнлек гастрольләрдән кайткан. Үз халкыбызның яшәешенә, тормыш-көнкүрешенә горурланып сөйли дә сөйли.

— Әгерҗедән соң Русия башлана. Анда ут та юк. Ике тәрәзәле йортларның морҗаларыннан төтен чыга. Бездә мунчалардан да төтен чыкмый бит хәзер, — ди. — Себердәгеләр дә югыйсә газ өстендә, нефть өстендә утыралар...

— Ходайга шөкер, Ходайга шөкер, — дип кушылалар залдагылар һәм бу җөмләләрне алкышларга күмәләр. Һәркемнең уе — алдагы сайлауларда. Һәркем Әлфия апага теләктәшлек белдерә.

Шәһәребез хакиме Рәшит Сәет улы Хәмәдиевне күрү Әлфия апаны аеруча шатландырды.

— Яман шеш авырулары шифаханәсендә ятканда, миңа Чаллыдан җимешләр, өрекләр килеп торды. Шуның өчен дә миң рәхмәт аңа. Бөтен халык алдында рәхмәт әйтергә килдем, — диде.

Рәшит Сәет улы да, кып-кызыл розалар бәйләмен бүләк итеп:

— Безнең буын Әлфия Авзалова, Илһам Шакиров җырларында тәрбияләнде, алар моңы белән яшәде.

Әлфия апаның авыр чаклары булды. Әлбәттә, өрекләр һәм алмалар гына әллә ни ярдәм итә алмаслар иде, алар белән аңа Чаллы халкының мәхәббәте ирешкәндер һәм халык мәхәббәте исән калдыргандыр, — диде.

«Камгэсэнергострой» ААҖ төзүчеләре исеменнән сәхнәгә күтәрелгән генераль директор урынбасары Салихҗан Гали улы Гайниев Әлфия апаны «ХХ гасыр йолдызы» дип атады.

— Без бәләкәй чакта, авыл клубының сәхнә тактасын каерып кереп, Әлфия апаны тыңлый идек. Әле дә Әлфия апаны көтеп алабыз, — диде ул.

Сәхнәдә төзүчеләрне күргәч, Әлфия апа да сүзсез калмады:

— Ул Азиноны күрсәгез, исегез китәр. Менә төзиләр анда йортларны! Казанга баргач, карагыз әле. Халык шатланып туя алмый, — диде.

Ә.Авзалованың бу концертыннан күпләр күңелләренә дәва табып кайтып китте.

— Килгәндә башым ярылырдай булып авырта иде, бетте бит, — диючеләр булды.

Баянчы Р.Закиров, нәфис сүз остасы Ә.Вәлиева, биюче Х.Шәрәпова, синтезаторда уйнаучы К.Габидуллин, икенче тавышка җырлаучы С.Габидуллиналарны да тамашачы җылы кабул итте.

Әйе, без кайбер җырчыларны 1–2 ай күрми торсак, исемнәрен дә, җырларын да оныта алабыз. Бу югалту түгел дә сыман.

«Ак чәчәкләр кебек кар ява» да, «Яшь гомер» дә, «Ак күлмәгем» һәм башка озын гомерле җырлар да һәрчак Әлфия апаны искә төшерәләр. Аларны ничә буын җырлаган һәм җырлый. Киләчәктә дә җырларлар кебек. Менә әле дә «Киек казлар»ы колагымда яңгырап тора:

Йөрәгемдә, хисләремдә
Хушлашам казлар белән,
Алар минем хәлне белми,
Мин аларныкын беләм...

Кабат очрашулар насыйп булсын иде. Халык та әнә шундый өметләр белән таралды.

*«Шәһри Чаллы»*
*1996*

**РЕЗЕДА ДАУТОВА**

# «Пусть люди помнят, какой я была...»

Альфия Авзалова исчезла с эстрадного горизонта лет 10 назад. Слухи ходили разные: заболела, спилась, уехала за границу. Но вдруг узнаю: концерты Авзаловой проходят с большим успехом в районах Татарстана.

...И вот открываю дверь ее подъезда. Легенда татарской эстрады живет в 2-комнатной квартире в депутатском доме. При входе милиционер дотошно расспрашивает меня и пропускает только после телефонного звонка к певице.

Разговор начинает сама Авзалова:

— Где только обо мне не писали — в книгах, журналах, газетах!

— Оставим Вашу биографию для историков. Скажите, это правда, что Вы многого добились исключительно благодаря силе своего характера? И никто Вас не проталкивал?

— Почему не проталкивал? Да чего же в Казани добилась бы без помощи — без денег, без родителей, я с 5 лет сирота, детдомовка?! Меня толкал первый секретарь Актанышского райкома партии Камалеев. Прослушал в своем кабинете. Понравилась я ему. И отправил в Казань учиться в музыкальное училище. Но там не было общежития, и я вернулась домой. Потом меня повез в город наш комсомольский секретарь. Прямо из обкома комсомола повели в татарский ансамбль. Спела им свою любимую «Кукушку». Это же народный романс! Это же великое дело! И меня приняли. Сразу взяли на гастроли — в Омск, Томск, Новосибирск. Через несколько лет уже самостоятельно выступала. И так 46 лет.

— Вы знаете, некоторые Вашу историю сравнивают с историей Фроси из фильма «Приходите завтра». Деревенская девчонка приехала в столицу поступать в консерваторию...

— Консерваторий я не кончала, за что была не раз бита своими завистниками и недругами. А вот деревенской была самой что ни на есть настоящей. В 18 лет не знала ни одного русского слова. И голос я теряла, как героиня фильма, — представляете, меня заставляли три октавы брать с моим альтовым голосом. «Сандугач» пела. А какая из меня, простите, сандугач? Результат — несмыкание связок. Я быстренько вернулась в ансамбль, и голос ко мне вернулся.

— Альфия ханум, кажется, недавно Вы пережили еще одно рождение своего голоса?

— Да, у меня был узловой зоб. Вообще не могла разговаривать, изъяснялась только руками. Спасибо врачам 15-й больницы — сделали операцию. Открываю глаза после наркоза, вижу — сидит рядом моя Гульшат (близкая подруга Авзаловой — поэт и драматург Гульшат Зайнашева). И как закричу на всю больницу: «Гульша-а-ат!» А она: «Тихо-тихо, тебе только зашили горло, а ты уже кричишь». А я от радости уже спать не смогла. Все бегала по этажам — всех спрашивала, как дела. Знаю, людская молва ходит: у Авзаловой, мол, рак горла. В Свердловске даже знают об этом: пела там, слушают и плачут — как же ты, Альфия, после такой операции поешь?..

— Считается, что лучше Вас «Кукушку» никто и никогда не исполнял.

— Да, я знаю это. «Кукушку» я стала петь после Гульсум Сулеймановой. Но, думаю, у нее не было «моң»... Что такое «моң»? Это душа. Характерный для татарских мелодий фаршлаг — это еще не «моң». Душа должна быть в самом звуке, голосе. Я брала песни в свой репертуар, если слова трогали меня, тогда даже плохую мелодию можно было спеть с душой.

— А как Вы от своих завистников спасались?

— Меня и оклеветать пытались, и шантажировали. А сколько сплетен ходило! А я отряхнусь и вперед иду: наплевать, пусть говорят! Я никогда не забывала, что я нищая, из народа. Всю жизнь старалась. Говорила себе: стану человеком, стану все равно! И хотя знания получила позже всех, знала: меня народ любит.

— Поклонников у Вас, наверное, всегда было много?

— Много, причем разных национальностей. Но это все были незначительные встречи. Я очень избирательна в знакомствах.

— Интересно, что бы Вы со своим опытом посоветовали женщине, которую бросил мужчина?

— Я вообще не понимаю, когда ахают и охают: не могу, мол, жить без него. Как бы ни был влюблен человек, все забывается — и страдания, и слезы, и печаль. А мужчины... Чем больше отказываешь им, тем сильнее они хотят тебя. А если виснешь на шее двумя руками — ни за что не удержишь! Альфия апа насчет этого очень опытная.

— Чем Вы все-таки завоевывали мужские сердца?

— Наверное, своей независимостью. Я всегда была честной с ними. Всегда, даже когда денег не было, со вкусом одевалась. Порой из ничего изысканный туалет получался. Меня называли француженкой.

— А как сложилась судьба Ваших дочерей?

— Старшая дочь замужем, работает в строительной академии. Младшая закончила театральное училище, голос был. Даже немного поработала со мной. Но вышла замуж, сейчас на Кипре живут. И ничего ей, кроме семьи, не надо. Уже внучки у меня есть.

— Можно уже и почивать на лаврах...

— Нет, еще не хочется. В Заинске дала перед Новым годом 23 концерта, в Нурлат-Октябрьском — 15. Вернулась, а в Казани Салават ждет: «Альфия апа, в Москве открыл ресторан «Салават», поехали». В феврале, Алла бирса, начнется мой прощальный тур. Сначала объедем татарстанские районы, затем по городам России. Пусть запомнят люди, какой была Альфия Авзалова.

*1998, 24 января*

**ЭЛЬМИРА СӘЛӘХОВА**

# Әлфия апа сәхнәдән китәргә җыенмый

Әлфия апа белән күрешү теләгем зур булса да, мәшһүр җырчы белән әңгәмә корырга озак вакытлар батырчылык итмәдем. Ниһаять, мин аңа телефоннан шалтыраттым һәм нәкъ үзенә тап булдым. Әлфия апа очрашырга бик теләп риза булды. Сөйләшү вакытында аның үтә гади, ягымлы, ярдәмчел, юмарт, изге күңелле хатын-кыз булуына кат-кат инандым.

Гүзәл табигатьле, җыр-моңга, шигърияткә бай, күренекле кешеләре белән дан казанган Актаныш районының шифалы суларын эчеп, Сөн елгасында коенып үскән бит ул Әлфия апабыз.

— Әлфия апа, Казанда узган концертлардан үзегез канәгатьме?

— Әлбәттә. Мин халкымнан бик риза булып калдым. Чөнки залны тутырып килгәннәр, хәтта кайберләре басып та тора. Кайсы елый, кайсы миңа кушылып җырлый. Мин тамашачының күзенә карап җырлыйм. Алар еласа, икенче якка карыйм, чөнки үзем дә еларга гына торам.

— Концерт вакытында: «Опера театрына аренда өчен акча түләмәдем, бушка бирделәр», — дидегез...

— Әйе, бу чыннан да шулай. Дөресен әйтәм, әлеге театрга теләсә кем кереп җырлый алмый. Шушы мәһабәт бинаның директоры Рәүфәл Сабирович янына сөйләшергә бардым. (Аның әнисе заманында Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә җырчы булып эшләде, Татарстанның атказанган артисты Разия Тимерханова. Мин ул чорда Актаныштан яңа килгән, яшь, өскә-башка кияргә дә, торыр урын да юк. Разия апа мине һәрвакыт өенә алып кайтып йөрде. Ашатты, эчертте. Бик яраттылар үземне, һәм алар тормыш иптәше Сабир абый белән бергә җәмгыятькә файдалы, акыллы ике ул тәрбияләп үстерделәр.) Рәүфәл, мин әйтәм, арендага акча түләрлек рәт юк, чөнки монда җыйган акча сезгә түләргә дә җитми. Энем, җаным, залны Әлфия апаңа бер генә көнгә бирче, дим. «Әлфия апа, әнә, пожалуйста, кайсы көнгә кирәк?» — ди. Һәм бирде дә. Бөтен мөмкинлеген күрсәтте. Бик зур рәхмәт аңа.

— Белдерүдә язылган шигырь юллары сезнең тамашачылар белән саубуллашуыгызны аңлатамы?

— Юк. Мин халкым белән саубуллашмыйм. Ул белдерүне күптән инде нәшриятта үземә атап бик матур шигырь юллары белән язып биргәннәр иде. Чөнки озакламый 70 яшем тула, Алла боерса. Әмма сәхнәдән китеп буламы соң? Ул мине һәрвакыт үзенә тарта, әгәр китсәм, үләргә дә мөмкин. Тамашачысыз, җырсыз, сәхнәсез көннәрне күз алдыма китерәм дә, кирәкми, дим. Сәхнәдә, халкым алдында үләм. Әлегә тавыш бар бит, нигә җырламаска?

— Кайсы якларга гастрольләргә җыенасыз?

— Мәскәүдә ике концертым көтелә. Алла боерса, Мәскәү мишәрләре белән күрешеп, гөрләтеп кайтам әле. Сизәм, үземне халык бик сагынган икән. Киләчәктә, көзге байлыкта яңа программа әзерләп, элек җырлаган җырларны заманча эшкәртеп, тамашачым белән тагын күрешәчәкмен.

— Әлфия апа, эстрадага килүче яшь буынга нинди күзлектән карыйсыз?

— Алар башта үз тавышлары белән киләләр дә аннан соң фонограммага җырлап халыкны алдыйлар. Булган тавышлары да юкка чыгып, үсә алмыйча төшеп калалар. Гел җырлап торсаң гына тавыш була бит ул.

— Бүгенге көндә яшьләрнең әхлаксызлыгы, эчү, тарту, наркомания белән шөгыльләнүләре сезне дә нык борчый торгандыр?

— Ул наркоманнар, эчкечеләр кая барып бәрелергә белмичә, эш юклыктан, рәхәт тормыштан шулай көн күрәләр. Аларның кайгы-хәсрәте юк. Эшсезлектән ялкауланып беттеләр. Киләчәген уйламый, «атай малы катай». Эчкән аракысы да, тәмәкесе дә ата-ана кесәсеннән бит. Бу очракта ата-ананың каты тормавында, тиешенчә тәрбия бирә белмәвендә гаеп зур. Исерек атада бала кайгысы юк. Менә без бер дә шулай булмадык. Чөнки ятим үстек, ашарга, эчәргә, кияргә дә юк иде. Наркоман дигән сүзне ишетмәдек тә, белмәдек тә. Ул сүзне әйтергә тел дә әйләнми хәтта.

— Сезнеңчә, татар эстрадасында кайсы җырчыны «йолдыз» дип атарга була?

— Йолдыз булыр өчен кимендә утыз ел эшләргә кирәк. Шулай да бүгенге көндә ир-атлардан бердәнбер йолдыз дип, әлбәттә, Салаватны атар идем. Ә хатын-кыз җырчылардан Хәния Фәрхи-Биктаһирова белән Зәйнәп Фәрхетдинованы әйтә алам.

— Элекке эстрада белән хәзергесен чагыштырсак, нәрсәне үзгәртер идегез?

— Хәзер инде апагыз да бозылып бетте. Мин дә заман эстрадасын ярата башладым. (Көлә.) Тик, сәхнәгә күп музыкантларны җыеп, каты тавыш биреп, халыкның колагын тондырырга кирәкми. Салаватка ярый инде, тутырсын шунда, аның акчасы күп. (Көлә.) Аранжировкага килсәк, чит ил җырларының бер кырыен алалар да көй чыгаралар. Менә бу бөтенләй дөрес түгел. Татар көен бозып әллә ни кыландырып булмый. Бүген тамашачыга ул кирәк түгел. Киресенчә, матур уйнаучыга кушылып, моңлы итеп җырларга кирәк. Шул вакытта җырның сүзләре дә аңлашылачак.

— Сез Илһам абый белән мәхәббәтегез турында төрле кызыклар сөйлисез. Ә ул үзе үпкәләмиме?

— Бервакытта да үпкәләми. Ярата гына, һаман да яратам, ди. Илһам үзе дә бик шаян ул. Без аның белән икәү очрашсак, сөйләшеп сүзебез бетми. Үткәннәрне искә төшерәбез. Күптән түгел аның белән Себердә ундүрт концерт куеп кайттык. Шунда Илһамга әйтәм: «Нигә теге вакытта миңа өйләнмәдең?» — дим. Ул: «Әлфия, уйладым-уйладым да, багажың бик күп иде», — ди. Шулай булмыйча, әбием, ике кызым, сеңлемнең балалары да бар иде бит.

— Әгәр тормышыгызны яңадан башларга туры килсә, барыбер дә туры сүзле булып калыр идегезме?

— Әйе, чөнки алтыдагы алтмышка, диләр. Шушы туры сүзлелегем аркасында мин исемнәрне дә ун елдан ун елга гына алдым.

— Сезнең турыда гайбәте дә күп сөйләнде. Үзегез моны ничек кабул итәсез?

— Ишеткән вакытта бик авыр була. Гайбәт беркайчан да дөрес түгел. Миннән көнләшеп, ачулары килеп, теләсә нәрсәне үзләренең башыннан уйлап чыгаралар. Гайбәт ишеттемме, борчылам, ләкин шунда ук үземне кулга алам. Берәр яхшы җыр эзләп табып, аны өйрәнеп тагын халык алдына чыгарга әзерләнәм. Миңа хәзер көч кенә бирә ул гайбәт.

— Кем белән яшисез?

— Берүзем яшим, рәхәтләнеп, Аллага шөкер. Ятсам да, торсам да — үземнеке. Тормышымда иң бәхетле хатын мин. Балаларым, оныкларым бар. Бик бәхетлемен. Төпсез чабата киеп, рәтле ризык күрми үскән кешегә, миңа, Татарстаным — оҗмах, Казаным — Урта диңгез.

— Бүгенге көндә Сез нәрсәдән канәгать түгел?

— Аллага шөкер, бик канәгать. Дусларым күп, җитәкчеләр һәрвакыт ярдәм итәләр. Аерым әйткәндә, Чаллы шәһәр хакимияте башлыгы Рәшит Хәмәдиев мине бик хөрмәт итә, зур ярдәм күрсәтә. Якташым, Президентыма мең рәхмәт.

— Эстрадада тоткан бөек урыныгыз үзегезгә дә шулай тоеламы?

— Мин бөтенләй уйламыйм ул турыда. Мактагач, хөрмәтләгәч тә бик авыр икән. (Көлә.) Үземне бервакытта да әллә кем итеп санамадым. Үз гомеремдә туйга йөрмим, кунакка бармыйм, туган көнемне уздырганым юк, әллә картаясы килми, белмәссең.

*«Мәдәни җомга»*
*1 июнь, 2001*

**АЙСЛУ КАДЫРОВА**

## «Хаха-михаха» — это не про меня, я всегда говорю правду...»

В городе появились афиши о прощальном бенефисе истинно народной певицы Татарстана — Альфии Авзаловой. Просто не верится, что звезда татарской эстрады решила в апреле этого года выйти на сцену в последний раз. «Приезжай ко мне, это не телефонный разговор!» — заинтриговала меня Альфия апа.

...В вестибюле подъезда элитного дома, где живет Авзалова, консьерж старательно выяснял, кто я и откуда. После чего изучил свои записи и сказал: «Да, о вас меня предупреждали... Можете пройти к лифту!»

— Я сольный концерт уже десять лет не давала! — говорит Авзалова. — Чувствую, надо успеть попрощаться со своим зрителем... Но в «солянках», так мы называем сборные «зур» концерты, петь после бенефиса не откажусь. А сейчас три новых платья в Доме быта сшила для бенефиса. Пусть меня публика модной красавицей запомнит! Мне, скажу тебе откровенно, недолго жить осталось.

— ?

— Сказывается, и очень сильно, операция, которую я перенесла четыре года назад. У меня тогда голос пропал... Мне долго не говорили правду, но, когда привезли в онкологическую больницу, я сразу все поняла... Операция по удалению опухоли прошла успешно. Я и не сомневалась в этом, потому что профессор Рифкат Тазиев — профессионал! А на профессионалов у меня нюх. Я как его увидела, сразу передумала ехать лечиться во Францию. После операции голос ко мне вернулся. Но потом мне пришлось пройти 80 сеансов облучения! Я облысела, у меня полгода из подмышек кровь текла ручьями... И это ведь пережила, я — сильная!.. У меня уже и новые волосы успели на голове вырасти — густые и почему-то волнистые. Но сейчас я живу на лекарствах: после облучения у меня стало скакать давление, страшно болит сердце... Уверена почему-то, что я не от новой опухоли умру, — от сердца...

— Вы так откровенны...

— «Хаха-михаха» — это не про меня, я всегда говорю правду. И очень жестко. Вот недавно спецконцерт на Казанском мясокомбинате со своей бригадой давала. Только взглянула на их вкусную продукцию, сразу почувствовала: наверняка воруют! Я ведь и сама воровала...

— Когда?

— В детстве. Я же сироткой была, меня бабушка воспитывала. Ох и злая она была, но по-своему меня любила. Помню, во время войны, чтобы не умереть с голоду, она взяла меня с собой на колхозное поле воровать пшеницу. Напялила на меня жуткие брюки, вокруг колен подвязала их веревочками. И насыпала в эти брюки зерно. Я пока до дома дошла, все ноги этими крупинками до мяса разодрала. Но не плакала — бабушку боялась. Я, кстати, никогда не плачу! Так вот, я этот случай на мясокомбинате рассказала. И подытожила: везет, говорю, вам. Мясо воровать не так больно, как пшеницу. Наверняка вы еще и без костей себе его выбираете! Рабочие стали такие красные! Но смеялись от души.

— Вас часто обманывали!

— Часто. Вот взять, например, мое первое замужество. Хозяйка квартиры, которую я снимала в Казани, знала, что я офицеров обожаю. И сосватала мне своего знакомого, якобы офицера. А этот знакомый странный был — плащ никогда в комнате не снимал. Однажды я не выдержала и стала этот плащ с него сдирать, я тогда уже девушкой его считалась. И вдруг вижу, что погоны на его гимнастерке — не офицерские. Солдафоном он оказался! Как я обиделась... Из жалости я за него замуж вышла и даже после свадьбы долго не могла к нему привыкнуть. Четыре месяца к своей постели не подпускала — пиналась-лягалась. А потом... Надолго меня не хватило, все-таки ушла я от него. Ой, как бабушка ругалась! Я ведь ему квартиру — однокомнатную «сталинку», которую мне тогда только что дали, оставила. С бабушкой и уже двумя детьми опять квартиру стала снимать. А бабушке пообещала: «Еще одно слово про первого мужа — повешусь!.. Вот увидишь, мы еще в суперквартирах жить будем! Не всю жизнь в хоре госансамбля песни и пляски петь буду. Я — талантливая, всего добьюсь!» И ведь добилась...

— В народе до сих пор говорят о Вашем романе с Ильхамом Шакировым...

— Так ведь из-за Ильхама я и ушла от мужа. Знаешь, какая у нас любовь была? Как в кино! Это Ильхам уговорил меня с мужем развестись. Помню, после развода я поехала с Шакировым на гастроли в Ташкент. В гостинице администратор спрашивает: «Вам какой номер? Вы муж и жена?» Ильхам как воды в рот набрал. И я как заору: «Да! Да! Да! Я — жена Ильхама!». Нам дали люкс. А возвращаемся после «медовых» гастролей в Казань — Ильхама опять как подменили. До свидания, говорит мне в аэропорту, увидимся в филармонии! Но я не могу на него сердиться — люблю я его. Думаешь, стала бы я Авзаловой, если бы не Шакиров? Я ведь всегда соревновалась с ним, старалась доказать, что я — лучше...

— А сейчас Вы свободная женщина?

— Мне 68 лет, но на меня еще западают. От мужчины, как от постоянного сожителя, я освободилась в 52 года. Сама сказала Юсуфу: «Ты прожил со мной 20 лет. Я старею, уходи — женись на ком-нибудь, пока молод. Детей заведи. И он ушел. Два раза уже был женат. Юсуф в моем коллективе работал, он — бас-гитарист. Мне 32 года было, ему — 24, когда мы познакомились. Целый год он за мной ходил! Помню, я подумала тогда: «Что я, девушка, что ли? Что я теряю? Пусть со мной живет, и его прокормлю, лишь бы детей моих не обижал...»

— Вы хорошо зарабатывали?

— Мне 6 рублей за концерт платили, я старалась в день по четыре концерта дать. Но меня так любили, что после концерта устроители всегда спрашивали: «Альфия ханум, может, вам чего-нибудь надо?» Я отвечала: «Все надо!» И привозила с концерта в деревне по 500 яиц, мяса — целую корову, масло — ящиками... Я ведь, помимо детей и бабушки, еще за детей сестры переживала. Их шестеро было, когда она и ее муж умерли. Как я ненавидела себя, что пришлось устраивать племянников в детский дом. Ну не могла я содержать такую ораву, понимаешь? Зато сейчас всем им квартиры выбила, до сих пор помогаю. Мне ведь и теперь после концертов подарки дарят, когда уже за выступление тысячу рублей получаю. Недавно, например, в Бугульме норковую шубу подарили. Это настоящая народная любовь...

— По обстановке Вашей квартиры легко догадаться, что вы часто гастролируете: чемоданы, коробки... Так всегда было?

— Нет. Это я к переезду готовлюсь — скоро в самом центре города буду жить. Мне тесно в этой двухкомнатной квартире! Я ведь не всегда здесь одна со своей собакой кукую — ко мне часто гости приходят. И мне уже неудобно, когда они приходят с ночевкой, самой уходить ночевать к соседям.

— Дети к вам часто приезжают?

— По возможности. Одна дочка у меня на Кипре давно живет, другая — в Казани. А на прощальный бенефис, наверное, придут обязательно, как и все мои близкие. Знаешь, я на сцене оживаю! Никакой боли не чувствую! Правда, перед концертом море таблеток сейчас выпиваю. Могла бы и не принимать — утомительно это, страшно дорого к тому же. Но мне врачи сказали, что надо. Иначе долго не протяну. А я так хочу, чтобы Бог мне подарил еще хотя бы десять лет жизни. Я бы для себя наконец-то пожила, я ведь всю жизнь «пахала»...

**ЗЕМФИРА ГЫЙЛЬМЕТДИНОВА**

# Рәхмәт, Әлфия апа!

Әлфия апа Авзалова белән очрашып сөйләшү җиңелләрдән булмады. Айдан артык телефоннан шалтыратып эзләсәм дә, олы җырчының тавышын ишетү йөзенче талпынудан соң гына насыйп булды миңа. «Ай-яй, Әлфия апа, өйдә тормыйсың икән», — диюемә: «Өйдә гырлап йоклап ятсаң, эш бармый шул, үскәнем», — диде ул, нәкъ Авзаловача итеп. Әлфия апаның минутлап исәпләнгән көннәрен барлап чыкканнан соң, җырчы белән сөйләшү мөмкин булырына өмет уянды.

Редакциябезгә егетләрне бер читкә куярлык энергия, ябь-яшь кызларны көнләштерерлек нәзакәтлелек, матурлык алып килеп керде ул. Чын артист әнә шундый була. Сәхнәгә чыкса, җыры, моңы белән тамашачысының һәр күзәнәгенә үтеп керә дә күңелләрне айкый. Сөйләшкәндә авызыннан күзеңне ала алмый, мөкиббән китеп тыңлыйсың. «Талант» дип атыйлар андыйларны. Ә талант ул — акчага сатып, алтынга алыштырып алып булмый торган Ходай бүләге. Әлфия апа Авзалованы талант дип кенә атау да дөрес булмас иде. Ул чын мәгънәсендә халык байлыгы. Җир шары буйлап чәчелгән, сибелгән татарның бу җырчыны белмәгәне юктыр. «И җаным, яңа гына Себердән кайттым. Илһам Шакиров белән 15 концерт бирдек. Онытмаган безне Себердәге татарлар», — ди Әлфия апа. Онытмаячаклар да. Онытырга хакыбыз да юк. Татар җырын, җыр аша милләтне милләт иткән кешебез бит син, Әлфия апа. «Әллә кайларда йөреп кайтам. Күптән түгел Свердловскида булдым. Дөрес, хәзер элек йөргән Урта Азия якларына бик чыгып булмый. Юллар бик кыйммәткә төшә. Татарстанымны яратам. Кайсы районга барып төшсәм дә, кочак җәеп, «Әлфия апа» дип өзелеп көтеп торалар. Туган Актанышыма кайтсам — якташларым, хакимият башлыгы Энгель Фәттахов нинди генә хөрмәтләр күрсәтергә белмиләр. Актанышның үзен карагыз сез. Диңгез уртасында утыра бит. Бер ягында — Агыйдел, икенче ягында — Сөн, Ык елгасы дисеңме. Халкының кунакчыллыгына чик-чама юк. Анда бит урамнан узып барган чит кешене дә тәрәзә шакып чәйгә чакыралар. Барганнары булмаганнар барып күрсен минем Актанышымны. Чаллыга барсам, Рәшит Сәетович Хәмәдиев үз апасын хөрмәтләгәндәй хөрмәтли. Миңа бит онкология больницасында бик озак булырга туры килде. Бервакыт: «Сезгә Зәйдән килгәннәр, Әлфия апа», — диләр. Ул вакытта Рәшит Сәетович Зәйдә иде әле. Күп итеп күчтәнәчләр җибәргән. Минем сәламәтлегемне кайгыртткан, булмаган тәм-том юк күчтәнәчләре арасында. Авыр чакта бик беленә ул кемнең сине хөрмәт иткәне. Салават бик карады үземне. Үз өендә 1 ай тәрбияләде. Кара икра гына ашап тордым. Шөкер, аякка бастым, өйдә тик ятып булмый бит. Җырлыйсы килә, халкымны күрәсем килә. Тиздән Нурлатка барырга җыенам менә. Фатыйх Сибагатуллин күптәннән: «Кил, Әлфия апа», — дип тора. Йөри алганда, җырлый алганда ник бармыйм. Барам да җырлыйм. Күптән түгел Азнакайда концертлар куеп кайттым. Хакимият башлыгы Әнәс Исхаков бик матур каршылады, хөрмәтләп озатты. Кайтыр юлга чыккач, автобусның төбе җиргә тиеп кайтты. Шулкадәр күчтәнәч төяп җибәргәннәр азнакайлылар. Шулай хөрмәтләп, яратып көтеп торучылар булганда тагын 100 ел җырларлык. Татарстанымны 1000 кат урап чыктым инде мин, туктамыйм әле, җырлыйм, Алла боерса».

Әлфия Авзалованың сәхнәгә аяк басуына тиздән, бик тиздән 50 ел тула. Ярты гасыр гомер. Җырлы гомер. Халык тарафыннан да, хөкүмәт тарафыннан да күрсәтелгән хөрмәт. Ләкин җиңел яуланганмы соң ул?

«Шөкер, мине беркем дә эткәләп-төрткәләп үстермәде. Гайбәт белән үстем. Минем гайбәтемне сөйләделәр, мин аның саен үҗәтләнеп, тырышып җырладым. Илһамның булуы да миңа бик булышты. Аннан калышмыйм дип тырыштым. Минем өчен маяк булды ул. Тагын ул мине дөрес сулыш алып җырларга да өйрәтте бит әле. Ул бит консерватория тәмамлаган, ә минем белемем юк. Белемем булыр иде дә, һаман да шул ятимлегем комачаулады. Музыка училищесына аласылар иде — торыр җирем юк, акча биреп торырга әти-әни юк. Ничек укырга кирәк. Шул вакытта училище директоры Әүхәдиев әйтте миңа: «Кызым, тавышың әйбәт, озак җырлагансың син», — диде. Дөрестән дә күп җырлаган идем. Агитбригадалар бар иде элек авылларда. Әнә шул агитбригада концертларыннан калдырмыйлар иде мине. Гел «...шомыртым» җырын җырлаганга, «шомырт кызы» дип йөртәләр иде. Укып булмады. Эшли башларга туры килде. Башта Илһам Шакиров белән бергә эшләдек. Аннан соң инде үз группам белән».

Әлфия Авзалова иҗатыннан хәбәрдар булмаган, аның җырларын яттан белмәгән кеше, әйткәнемчә, юктыр. «Назлы гөлкәем», «Сагынам, дуслар, илкәйне», «Картаямыни соң йөрәк»... һәм башкалар дип язарга кул бармаса да, һәммәсен дә санап чыгу мөмкин дә түгел. Бүгенниләр җырлый соң Әлфия апабыз?

«Халык җырларын күп җырлыйм. Урамда да авыз эченнән көйләп йөрим мин. Кайчагында әллә кайчан җырлап онытылган берәр җыр исемә төшә дә, як-ягыма каранып алып, кычкырып ук җырлап җибәрәм. Аннары, мин трамвайда йөрергә бик яратам. Утырып барасың, тәгәрмәчләр «тек» тә «тек» килә. Шул вакыт әллә нинди җырлар искә төшә. Кайвакыт трамвай белән әллә ничә «круг» бирәм. Кайтып Кәримгә шалтыратам. (Кәрим Габидуллин Әлфия апа белән 33 ел эшли, музыкант, Татарстанның атказанган артисты.) Кәрим, шул-шул җырым искә төште, яңартып җырлыйбыз», — дим. Ләкин бүгенге көндә Николай патша заманыннан калган җыр белән генә дә булмый. Репертуарны гел яңартып торырга кирәк.

Яңаларны да күп җырлыйм, темпераментлы җырларны. Сүзләрнең мәгънәле булуына бик игътибар итәм. Хәзер бит яшьләрнең күбесе «пи-пи, па-па» дип, бер куплетны биш кат кабатлап җырлыйлар. Алай булмый ул. Җырның яхшысын сайлап, үз тавышы белән җырласа гына гомере озын була җырчының. Хәзергеләр җиңел кәсепкә ияләштеләр. Һәммәсе дә димим, күбесе фонограммага авызларын гына ачып торалар. Шуның белән үзләрен бетергәннәрен аңламыйлар. Тавыш бит ул җырлый-җырлый чарлана, җырлый-җырлый ныгый. Мин, шөкер, үз тавышым белән җырлап күтәрелдем. 18 яшемдә Җыр һәм бию ансамбленә эшкә килгәч, «Кәккүк», «Салкын чишмә», «Гөлҗамал»ларны җырладым. Мине тыңлаган Ключарев ул вакытта: «Ничек шулай оста җырлыйсың бу җырларны, кем өйрәтте?» — дип шаккатты. Ә өйрәтүчеләрем Мәсгут абый Исхаков белән Мәрзия апа Юнысова иделәр. Мәсгут абый — радиода эшләүче Фәйрүзә Исхакованың әтисе. Ә Мәрзия апа Юнысова — фотога төшерүче. Җырчылар да түгел үзләре. Зифа Басыйрова кебек осталарны да тыңлап өйрәндек без. Бүгенге җырчылар да үзләренең халыкны нәрсәгә, ничек җырларга өйрәтүләре турында уйласыннар.

Әлфия апа барлык яшь җырчыларны сүгеп утыра дип уйлама, сеңлем. Әйбәтләре дә күп бит. Кара син ул Салаватны. Патша егете бит. Тынгысыз, тырыш үзе. Түшәмгә төкереп, мич башында йоклап ята торган җырчы түгел. Ә Хәнияне әйт. Нинди ягымлы, нинди сөйкемле. Халык юкка яратмый ул. Халыкны җүләр димә син. Сайлап-сайлап кына ярата ул. Моң чишмәсе Зәйнәпне әйтсәң дә юк. Каян килгән шулкадәрле матурлык, ничек сыйган шулкадәрле моң?! Шаккаткыч бит. Зөфәре дә һич калышмый. Бик молодец егет. Без Илһам белән икәү иркенләп, конкуренциянең ни икәнен дә белмичә җырлап йөрдек. Хәзергеләр, күп булганлыктан, көрәшеп, ярышып яшиләр. Аларга авыррак. Ләкин конкуренция булмаса, үсеш тә тукталыр иде. Шуңа күрә ярыш булырга тиеш».

«Мин гайбәт белән үстем», — дигән иде бит Әлфия апа. Чыннан да, заманында аның мәхәббәт маҗаралары, башка кызыклары белән шактый тел чарладылар. Халык кына түгел, үзе дә сәхнәдән сөйләп йөрде ул маҗараларны, хәзер дә сөйли.

«Мәхәббәт турында, Нижгар мишәрләре әйтмешли, 20 ел элек «совсемга» оныттым. Аның кайгысы булдымы соң. Бер итәк баласын калдырып сеңлем үлеп китте. Ул ятимкәйләремне үстерергә, урнаштырырга кирәк иде. Күз салучылар, сүз катучылар бар инде ул. Кайвакыт шулай трамвай көтеп торганда текәлеп-текәлеп, борыла-борыла караучылар бар. «Исәнмесез, Әлфия апа», — диләр. «Апа дип әйтсәң дә, үзеңә ничә яшь соң, егет? Миннән олыраксыңдыр да әле», — дим. Ирләрне хәзер аракы бик картайта бит. Яшьләре минекеннән яшь булса да, кыяфәтләре бик таушалган. «Әлфия апа дип әйтмә. Син бит миннән картрак күренәсең», — дим андыйларына. Бер биш елга яшәрсәң әйбәт булыр иде дә бит. Юк шул, картлыктан качып котылып булмый. Алдап-йолдап төрмәдән дә котылып була, ә картлык белән үлемнән котылып булмый. Бик ямьсезләнеп, картаеп беткәч сәхнәгә чыкмам инде мин. Әлегә, шөкер, чыгарлыгым бар әле».

«Табигать талантлы кешеләрнең балаларында ял итә» дигән сүз бар. Әлфия апаның оныклары да бар инде. Балаларында ял итсә, табигать, бәлки, онкыкларына талант орлыкларын салгандыр.

«Җырламыйлар, сеңлем. Оныкларым да, кызларым да җырламыйлар. Икенче кызым — Зөлфиям — элегрәк минем белән концертларда җырлаштыргалап йөрде. Ләкин мин аңа әйттем: «Кызым, — дидем, — җырлый башлаганчы киләчәктә шәп җырчы булырыңа өмет бармы, юкмы, шуны уйла. Өмет юк икән, башка юл сайла», — дидем. Ул кызым бүгенге көндә Кипрда яши. Кияве бик әйбәт, дәрәҗәле кеше. Иренә булышып эшләп йөри. Үзем дә кунакка барам, алар да кайталар. Зөлфиям үзем кебек үткен, Аллага шөкер, бәхете дә булды. Быел икебез бергә җырлаган аудиокассетабызны чыгардык. Олы кызым — Гүзәлем — бик сабыр, тыйнак. Анысы дингә бик бирелеп китте. Бик акыллы үзе. Оныкларымның тавышлары гел юк дип әйтеп булмый. Ләкин сәхнәгә менәрлек түгел. Җырламаган кеше юк бит ул. Кеше түгел, тавык та җырлый. Йомырка салып чыга да, и китә җырлап. Тавык кадәр генә җырлап сәхнәгә үрмәләмәскә кирәк. Дөньяда башка эшләр дә бетмәгән, вакытында үзең өчен дөресрәген сайла. Йөрмә юкны бушка аударып».

Безнең әңгәмә, билгеле, алай тәмамланмады. Әлфия апа өметле яшь җырчылар турында матур-матур сүзләр әйтте. «Лилия Муллагалиева озак җырлаячак, гомерле җырчы булачак. Тырышып үз өстендә эшләсә, билгеле. Азат Тимершәех бик матур җырлый. Шәпләр күп. Тырышлыкларын гына киметмәсеннәр», — диде ул.

Шау-гөр килеп, редакциябезне яңгыратып озак сөйләштек. Әллә бер мизгел генәме. Тагын, тагын тыңлыйсы килеп калды Әлфия апаны, үзе чыгып киткәнче үк сагындырды ул безне. Ләкин күпме энергия, күпме матурлык калдырып китте үзеннән соң. Рәхмәт, Әлфия апа!

*«Сәхнә»*
*Ноябрь, 2002*

**ФӘНДИДӘ ХАРРАСОВА**

# «Җырларымда калсам иде...»

Соңгы арада бәйрәм тантаналарына бай булды Уфабыз. «Шәрекъ» радиосы да Нефтьчеләр сараенда үзенең 10 еллыгын билгеләп үтте. Тантанага бик күп кунаклар, шул исәптән Русиянең атказанган, Татарстанның халык артисты, Тукай бүләге иясе Әлфия Авзалова да килгән иде. «Сәхипҗамал» татар хатын-кызлар оешмасы күренекле җырчы белән редакциябездә очрашу оештырды.

Татар һәм башкорт халкының сугыштан соңгы берничә буыны алар моңында — Мәгафур Хисмәтуллин, Фәридә Кудашева, Илһам Шакиров, Әлфия Авзалованың кабатланмас серле көй-аһәңнәре кочагында тәрбияләнеп үсте.

Клуб, мәдәният сарайларының түрләренә генә кунаклап яшәмәде аларның җыры, ә халык янәшәсенә төшеп, шаулы табыннарны да, туй мәҗлесләрен дә күтәрде. Ул моңнар көндезләрен кызу эш өстендә авыл кешесен эшкә, яшәүгә дәртләндерсә, кичләрен туган-тумачаның, гашыйкларның күңелләрен берләштерүче көч булды.

Әй ул балачакның татлы хатирәләрен кузгаткан җырлы тәлинкәләр!

Сабырсызланган сыман «чыжылдап» утырган патефонга кидереп тылсымлы энәне җайлап куюың була, ул күз иярмәслек тизлектә әйләнә дә башлый. Әнә шулай әйләнә-әйләнә, җырчы тәлинкә сине дә әллә нинди бер әкияти моң дөньясына бөтереп алып кереп китә. Әкренләп үзеңне дә шул өздереп җырлаучы Әлфия, Фәридә апаларың халәтендә тоя башлыйсың. Тормыш менә-менә ишекләрен ачып җибәрер дә үзенең сәхнәсенә дәшәр кебек... Менә шулай балачактан ук күңелебезгә кереп урнашкан моң алиһәләренең берсе — Әлфия апабыз — бүген каршыбызда утыра. Элеккеге Әлфия апабыз белән бүгенге кунагыбызны тоташтыручы җеп — аның тавышы, һаман да шулай көчле аһәңле, көй-бизәкләргә бай затлы тавыш.

Әмма вакыт дигәнең аны да аямаган шул. Шундый мәшһүр затларны урап кына үтәсе иде дә бит югыйсә. Күзләрендәге шаян очкыннар сүрелә төшкән, буй-сыны һәм хәрәкәтләрендә дә элеккеге җитезлек шәйләнми инде. Заманында сәхнәдә орчыктай бөтерелеп йөргән, балкып торган карашлары белән үк күңелләрне кабындыра алган Әлфиясен тамашачысы тәү карашка танымас та, мөгаен.

Җырчының сәхнәдән китеп озак кына югалып торуының да сәбәпләре булган икән. Берничә ел элек операция кичергән. Түшәктә дә тик ятмаган. Тормыш һәм сәхнә юлын чагылдырган «Үзем турында» дигән бик матур һәм эчтәлекле китап чыгарган. «Узган гомерем турында еш уйланам, — ди ул. — Ничек яшәдем? Картлыгым матур киләме? Уйланам-уйланам да шундый фикергә киләм. Яшьлегем сәхнәдә, шөкер, яшьнәп узды. Картлыгымда да җан дустым җырдан аерылмасам иде. Яшәү матурлыгы җырга бәйләнгән бит. Дөнья җыр булганга матур ул. Җырланган җырларым узган юлларыма сибелеп калган чәчәкләр кебек. Ул чәчәкләр шиңмәгәндер, орлыкларын сипкәндер, дөнья тулы чәчәкләр җырлардан яралгандыр дип, кайчакны хыялланып китеп үз-үземне юатам, рухландырам. Яңа җырга сусаган йөрәгем дәртләнеп тибә башлый. Яңа җырлар җырларга теләп яшәү яшәтәдер җырчыны!»

Аның китабында шундый юллар бар: «Мөфти Тәлгать Таҗетдин үзенең бер вәгазендә, халкыбыз динен, гореф-гадәтләрен, телен югалтырлык төрле кысуларга дучар булган елларда җыр тирәсенә тупланды. Җыр аны үзен югалудан саклап калды, диде».

Әлфия апа әлеге фикерне үстереп җибәргәндәй тагын сөйләп китә: «Чит өлкәләргә концертлар белән чыгып йөргәндә шуңа игътибар иттем. Үз ана телен яхшылап белмәгән татарыбыз да чыгышларыбызга атлыгып килде. Җырларымның сүзен бик аңлап бетермәсә дә, моңын үз иткәндер, моңга тартылгандыр, мөгаен. Концертлардан соң, сәхнә артына менеп, урыс телендә булса да тойгы-кичерешләре белән уртаклаша, рәхмәт әйтә, бахыр. Җыр яшәсә, милләт яши ул».

Кунагыбызның халык әле һаман яратып җырлаган элеккеге репертуарына әйләнеп кайтабыз. «Кәккүк», «Актаныш таңнары», «Яшь наратлар», «Күл буена килсәң иде», «Йөрәк сере» һ.б. Бу популяр җырларның туу тарихы кызыксындырды безне. Әлфия апа бераз дулкынланыбрак та китте бугай. Ни әйтсәң дә, олы сәхнәдә аны җырчы буларак таныткан кадерле ядкәрләр бит болар. «Җырларга минем ярты җаным кушылган. Бу җырларның күбесенең дөньяга ничек килүе, ничек тууы минем күз алдымда булды, — дип сөйли ул. — Көй авторы да, сүз авторы да, кайбер җырларның каралама вариантын миңа күрсәтеп: «Менә бу урыны ничек яңгырый, болай итеп үзгәртсәк, ничек карыйсың?» — дип, минем белән киңәшләшеп, миннән җырлатып карый-карый эшләделәр. Мин җырларны үз күңелем генә «әйтеп торган» борма-бизәкләр белән җырларга омтылдым. Бигрәк тә Зиннур Гыйбадуллин, Гөлшат Зәйнашева, Александр Ключарев җырлары шулай туды. Композиторларыбыз Җәүдәт Фәйзи, Сара Садыйкова, Рөстәм Яхин әсәрләре һәрвакыт репертуарымда булды. Башкортстан композиторларыннан Бәхти Гайсин, Рим Хәсәнов, Тәлгать Шәрипов көйләренә язылган җырларны ярата идем. Җырлар бик җиңел генә дөньяга тумый, җиңел генә язылмый. Озак уйланулар, эзләнүләр белән туган җырны композитор һәм шагыйрь иҗат итә, ләкин җырны беренче башлап җырлаучы дөньяга чыгара. Җырлар нотада чакта әле җансыз бер сөлдә кебегрәк була. Нота

әле ул мамыксыз канат шикеллерәк. Җырчы аңа мамык өсти, җырны шомарта, майлый, баллый. Шуңа күрә кайбер җырлар үзенең чын башкаручысын тапмый әрәм була. Башка җырчылар ничектер, белмим, мин үзем җырны җырларга дип алгач, иң элек сүзләрен укып карыйм. Сүзләре матур, күңелгә керерлек, эчтәлеге тирән мәгънәле булса, аннары җырның көен тыңлап карыйм. Көе ошаса, өйрәнә башлыйм. Матур көй бер тыңлауда күңелгә керә. Моңардан тыш һәр җырчының үз тавышы булырга тиеш, аны беркем белән дә бутарга мөмкин булмаска тиеш дип саныйм.

Җыр сәнгате өлкәсендә зур тәҗрибә туплаган җырчы буларак, Әлфия апа хәзерге эстрада җырларына да үз мөнәсәбәтен белдереп үтте.

«Музыка дөньясында хәлләр төрлечә, заманга карап үзгәрә дип әйтимме. Кемгәдер моң-аһәң кирәк, кайберәүләр, бигрәк тә яшьләр, ритм, шау-шулы музыка белән мавыга. Алар җырның эчтәлегенә, мәгънәле, мәгънәсезлегенә игътибар итми. Тыңлыйсыздыр инде, кайбер җырларның эчтәлеге бары берничә генә сүздән тора бит: «бардым», «кайттым», «киттем» кебек. Вакыт үтү белән мондыйлар онытыла, әлбәттә. Алар эзләнү чорына гына хас булган «әсәрләр».

— Мин дә заманга иярергә тырышам ул, — дип елмая Әлфия апа. — Репертуарга хәзерге эстрада җырларын да керттем. Халык көйләре белән чиратлаштырып чыгыш ясыйм. Тамашачының да төрлесе бар бит, кемгә нәрсә ошый. Ходай җырымнан аермасын иде, җырга багышланган гомер юлым һәрчак дәвам итәр төсле, халкым өчен җырлыйм бит мин. Сәхнәдә 40 елдан артык җырлап йөрүем тикмәгә генә булмагандыр, шәт? Яшьләр дә файдалы җырлар җырласын иде. Халык күңелендә кала бит ул. Ә халык онытмый. Мин дә, җырларымда калсам иде, дип, Ходайдан сорыйм. Ярый, анысын вакыт күрсәтер.

Безнең, чагыштырмача яшь буынның, Әлфия апаның балачагы, яшьлек еллары хакында да ишетәсебез килде.

Актанышта туган ул. Биш яшьлек чагында тифтан әнисе үлеп китә. Әтиләре, өч баланы калдырып, каядыр китеп югала. Кече сеңелләре үлә. Ике ятим кыз бала язмыш кулында кала. Ачлыктан шешенә башлагач хәтта хәер сорашырга да туры килә. Аннан — балалар йорты. Әнә шулай күңелләрне тетрәндерерлек ачы язмыш тия булачак җырчы өлешенә.

«Әле дә шуңа сөенәм, — ди Әлфия апа. — Ходай мине изге бәндәләреннән аермады. Авылдашларым хәер-фатихасы белән Казанга юлландым. Анда да игелекле абый, апалар очрап кына торды. Табигый сәләтемне бәһаләп үсәргә ярдәмләштеләр, олы сәхнәгә менгерделәр».

Хушлашканда Әлфия ападан җырлавын үтендек. Ул кыстатып тормады, «Саубуллашу вальсы»н җырлап җибәрде. Күкрәк төбеннән чыккан көчле моң күңелләрне актарып ташлады. Бер-беребезгә күрсәтми генә күзләрне сөрткәлибез. «Кем белә, дусларым, бәлки, соңгы очрашуыбыздыр бу, — дип, Әлфия апа үзе дә яшьле күзләрен яшереп елмайган була. — Гастрольләрем көтә әле, әй, онытмыйлар бит».

Саубуллашу вальсы... Кешенең гомер көзләрендә ул аеруча сагышлы яңгырый икән. Әмма Әлфия апага боегырга урын юк. Аның шаулап ачылган таланты безнең җыр сәнгатебезгә тирән уелып калган. Ул үзенә күрә бер мәктәп булып, яңа җырчылар, көйчеләр тәрбияләргә булыша. Һәм шушы күчеш-эверелешләр аркылы аның таланты җыр сәнгатендә яшәвен дәвам итәчәгенә иманыбыз камил!

*«Мәдәни җомга»*
*22 март, 2002*

**РЕЗИДӘ ШӘРӘФ**

# «Картаямыни соң йөрәк, маңгайлар сырланса да...»

Татар эстрадасына 40 елдан артык иҗат гомерен багышлаган Әлфия ханым Авзаловага гыйнварның 15 ендә 70 яшь тула. Чын мәгънәсендә җырлы, моңлы гомер.

Агыйдел һәм татар иле кызы сәхнәдә кәккүк кебек моңлана да, сандугачтай сайрый да, илкәе белән бергә яшьтән сөйгән иркәсен дә сагына белде. Белде дип әйтү генә аз, төрле җиргә сибелгән татарның моңзарын, сөенеч-көенечен, сагыну-мәхәббәтен аһәңле тавышы белән халыкка җиткерде.

Сөекле җырчыбыз кайларда гына куандырмады үз татарын: Урта Азиядә дисеңме, Төмәндәме, Свердловскидамы, ерак Себер якларындамы — бар җиргә дә өлгер иде ул һәм бүгенгәчә шулай, вакытын, сәламәтлеген һич тә жәлләмичә халыкка хезмәт итә. Ә туган Татарстанын ул аеруча ярата, үз төркеме белән концертлар куеп, авыл хезмәтчәннәренә олы бәйрәм ясый. Һәм бу фидакарь хезмәте өчен илебез аны Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләсә, тугрылыклы тамашачысы олы мәхәббәте белән иркәли.

Татарстанның халык, Русиянең атказанган артисткасы, Республиканың Тукай бүләге лауреаты Әлфия Авзалова — Актаныш авылы кызы. Җәмгыятькә ифрат күп танылган шәхесләр бүләк иткән бу төбәктә Әлфия исемле талантлы җырчы кызның дөньяга килүе гаҗәп хәл түгелдер. Туган җиренең яме, гаме юктан гына Әлфиянең моңлы җырларына күчмәгәндер.

Әлфия Авзалованың җырчы булып китүе очраклы хәл түгел. Табигать-ана биргән сәләт, җырга булган мәхәббәт, кешеләрне ярату аңа үз юлын табарга ярдәм итә.

Аңа бер үк вакытта нота грамотасын да, күренекле композиторлар иҗатын да өйрәнергә кирәк була. Күңеленә хуш килгән җырчыларның иҗатын ныклап йөрәк түренә сеңдереп бара ул. Яшь башкаручыга тәҗрибәле остазлары: Разия Тимерханова һәм Зөләйха Әхмәтова ярдәмгә килә. Һәм менә уку-өйрәнү еллары артта кала. Әлфия Авзалова үзенең эстрада бригадасы белән республика авылларын армый-талмый аркылыга-буйга иңли башлый. Ул елларда авылларның сикәлтәле юллары, карлары-бураннары җырчыны күп мәртәбә җырлатып кына түгел, хәтта елатмыйча да калдырмагандыр. Чи утын ягып җылытыла торган салкын клубның сәхнәсенә чыгып, баянга кушылып, күкрәк тавышы белән җырлап җибәрүгә Ильич лампасының кинәт сүнеп китүен һәм Әлфия апаның җиделе лампа яктысында «Актаныш таңнары»н «аттыруын» бик яхшы хәтерлим. Әмма шулай да ерак авылларда тамашачыларның аны зарыгып көтеп торуын һәм ул кунарга төшкән фатир хуҗабикәсенең горур рәвештә концерт карарга беренче рәткә килеп утыруын мин әле дә онытмыйм. Әле ул гынамы: концерт тәмамлангач, бу әби Әлфия апаның (!) үзе белән кич утырып, гөрләшеп чәй дә эчә бит! Болар һәммәсе дә минем балачак-яшүсмер чакта хәтер төпкелендә яшеренеп калган моңсу хатирәләрем. Рәхмәт сиңа барысы өчен дә, безнең Әлфия апа! Җырларың, җор сүзләрең өчен, тормыш авырлыкларына бирешмәвең, яшьлек хатирәләренә кайтарганың өчен мең яшә!

*«Татарстан хәбәрләре»*
*15–21 гыйнвар, 2003*

**ФӘНИЯ ХУҖИӘХМӘТОВА**

# Ап-ак атларга атланып төшләргә кергән егет

Әлеге концерт — Әлфия Авзалованың 70 яшьлегенә багышланган бенефисы — бик тә авыр, әле 6–7 ел элек кенә бөтен республикабызны, алай гына да түгел, бөтен дөнья татарларын дер селкеткән вакыйгага белән башланып китте. Ул чакта бөек җырчыбыз тавышсыз калган иде. Өстәвенә өч хәрефле яман чир дигән күкле-яшелле хәбәр барыбызны да тетрәндерде. «Израиль табиблары да дәваларга алынмый икән», — диделәр. Алар шулай, дәваларга тулы ышанычлары булмаса, алынып та тормыйлар. Мактаулы, данлыклы элеккеге обком хастаханәсенә киңәшергә дип тә, нәрсә әйтер дип тә республика онкология клиникасыннан онколог, хирург, профессор Рифкать Минһаҗ улы Таҗиевны чакыралар. Ул чакта легендар җырчыбыз нәкъ менә Рабит Батулла видеотасмага яздырып алып, олуг бәйрәм кичәсендә экраннан зур итеп безгә күрсәткәнчә була... Тавышы да юк, үзен дә тануы кыен.

Зур концерт Әлфия апаның экраннан тавышсыз сөйләве белән башланып китте. И-и, оста да инде бу Батулла: шундый бәйрәм кичәсендә йөрәкләребезне әчеттереп, күзләргә яшь китерде. Нинди аяныч, бер дә дәвалана алмас кебек. Ул вакытта, Батулла белән озаклап сөйләшкәннән соң, Әлфия апа йокымсырап китә һәм бик матур төш күрә. Ап-ак атка атланган егет Әлфия апаны алып очып китә. Дус-ишләре шикләнәләр, үзе исә: «Тереләм», — ди. Рифкать Таҗиевны ул елмаеп кабул итә.

Шулай булып чыга да. Рифкать Минһаҗ улы аз гына шикләнми дә, икеләнми дә, данына күләгә төшәр дип тә уйламый. Башта Әлфия апаның тавышы кайта, аннан үзе терелеп аякка баса. Калганы инде барыбызның да күз алдында: дүрт сәгатьтән дә артыграк дәвам итте ул кичә. Арытмады да, ялыктырмады да Әлфия апа. Сөйләде дә, җырлады да, ә икенче көнне бәйрәмен дәвам итәргә Чаллыга китеп барды.

Минем исә ак атларга атланып, коткаручы булып төшләргә кергән егетне күрәсем килде. Беләм, күп мәртәбәләр ишеткәнем бар: кемнеңдер төшенә ул ак сакаллы бабай, кемгәдер гүзәл кыз булып керә. Хәер, кем булса да — коткаручы инде. Җөмһүриятебезнең кайсы гына ягына барып чыксаң да, аны беләләр, ул коткарды, операцияне үзе ясады, дип сөенеп тә, горурланып та сөйлиләр.

Миңа яшь чагында ук Рифкать абыйны күрергә, аны тыңларга насыйп булган иде.

Рифкать Таҗиевны концерт, театрларда да очратканым бар. Инде менә күрешергә килгәч, операциядән чыкканын көтеп алдым. Байтактан күргәнем булмаса да, коридор башыннан күренү белән, ерактан ук таныдым. Ул әле һаман да югалмаган яшьлеге, сөйкемлелеге, барыннан да бигрәк сабырлыгы, гаҗәеп бер ягымлылыгы һәм гадилеге белән сокландырды. Югыйсә, визит карточкасына язылган титулларга караганда, бер дә гади булырга тиеш түгел кебек. Анда «Татарстанның атказанган табибы, профессор, онкология һәм хирургия кафедрасы мөдире, Петровский Фәннәр академиясе мөхбир-әгъзасы» дип язылган бит.

Үзем куйган сорауга җавап эзлим. Ничек шулай матур, гади кеше булып кала алган соң ул? Сәгатьтән артык ашыга-ашыга сөйләшәбез, күбрәк беләсем килә. Күңелемдәге сорауларга җавап табам да нәтиҗә ясап куям. Менделеев районының Бәзәкә авылында гап-гади гаиләдә туып үскән Рифкать абый. Ләкин тыштан, читтән караганда гына гади ул.

Бик яшьли гүр иясе буласын сизенгәндәй, әниләре ашыга-ашыга яши. Бер-бер артлы дүрт баласы — ике улы, ике кызы башлы-күзле булып үз гаиләләрен корып өлгерәләр. Минһаҗ абзый 1, 4, 8 нче сыйныфларда укучы 3 улы, барлыгы 7 баласы белән ятим дә, тол да кала. Еллары нинди бит әле: кияргә киемнең кадерле, ипинең бигрәк тәмле чаклары. Шуңадыр инде, мәктәпне тәмамлап...

Хыялсыз буламыни соң яшьлек, аңа ашау, киенү бөтенләй кагылмый диярсең. Рифкать икесен бергә кушып юлга чыга. Аның капитан буласы, су өсләрендә ак пароходны идарә итәсе килә. Ләкин язмыш бүтәнчә хәл итә. Нәкъ менә документларны тапшырып Казан белән танышып йөргәндә, класс җитәкчеләре Зәйнак абый очрый. Кирәк бит шулай: нәкъ менә ул хәл итә Рифкать Таҗиевның язмышын. Ничә еллар янәшә яшәгән укытучы, үз укучысын беренче күргәндәй:

— Син врач булырга тиеш, — ди.

Бар, бар иде ул андый хыял, тик күңел төпкелләрендә күмелеп кала. 8 нче сыйныфны тәмамлагач, ул үзе дә, училищега барып, медбрат булам дип, диктант язып кайткан була.

Зәйнак абыйсы ияртеп үк китә, документларны бер җирдән алып икенче җиргә тапшыралар. Менә бәхет, анда имтиханнарны гел татарча гына алалар. Укуын тәмамлагач, Рифкать Чувашиянең Яльчик районында эшли башлый. Иң зур мәктәпне Рифкать Минһаҗ улы шунда уза. Үз-үзенә ышаныч та, беренче горурлык та аңа шунда иңә. Ләкин «мин» дими ул, һаваланмый, мактанмый.

Ай-һай авыр икән хирург булып эшләү. Аның әле үзенең дә йөрәге гел чыгымчылап тора. Ул инде күпме сырхауның гомерен озайткан кеше, ике абыйсыз, ике апасыз калырга өлгергән. Шул инде — йөрәк чире. Рифкать абыйның үзенә дә операция өстәленә ятарга туры килгән. Аңа операцияне Мәскәүдә Ринат Акчурин үзе ясый. Бер ай дигәндә ул терелеп эшенә чыга, тагын операция өстәле янына баса.

Урыс халкында, «икенче тавышы ачылган» дигән бер гыйбарә бар. Чү, бу бит Әлфия Авзаловага кагыла түгелме соң? Ләкин безнең «икенче яшьлеге башланган» дигән үз гыйбарәбез дә бар. Бу сүзләр халык җырчысы Әлфия Авзаловага да, халык хирургы, профессор Рифкать Таҗиевка да турыдан-туры кагыла. Әйе, әйе, мин ялгыш әйтмәдем, — халык хирургы. Түрәләрне, байларны дәвалаучылар табылыр ул. Ә гади халыкны?.. Әлфияләребез гади халыкның җанын-рухын дәваласа, Рифкать Таҗиев кебекләребез гади халыкны сортларга аермый гына тәнен-җанын дәвалый.

*«Мәдәни җомга»*
*16 май, 2003*

**ГАБДЕЛБӘР РИЗВАНОВ**

# Таш астыннан чыккан Салават

Татарстанның халык артисты Салават Фәтхетдинов җитәкчелегендәге иҗат төркеме күптән түгел Русиянең бик күп шәһәрләрендә булып, 98 көнлек гастрольдән кайтты.

«Мин гастрольдән бик канәгать, — диде Салават. — Татар булмаган җир гомумән юк, әмма татар җырчысы аяк басмаган җирләр бар икән, бу юлы без менә шундый урыннарда булдык, киләчәктә дә шундыйрак төбәкләргә барырга тырышачакбыз».

Шулай да бу гастрольдән үтә илһамланып, дәрт-көч алып кайтканы, әлбәттә, Әлфия апа Авзалова булгандыр. «Оҗмахта булган кебек тоелды миңа, — дип сөйләде ул. — Өрмәгән урындыкка да утыртмам, дип әйтәләр бит әле, менә шундый кадер-хөрмәт күрдем. Ходай Тәгалә исәнлек-саулык кына бирсен инде Салават балакайга. Каян башкайларына килә диң син аның: мине афишаларга яздырмыйча гына алып барды да, аннан тамашачыга һич көтмәгәндә-уйламаганда курортта очраткан хатыны сымаграк итеп сәхнәгә алып чыга иде. «Законлы хатын Казанда балалар карап калды, монысы икенчесе», — дип тә җибәрә. Сәхнәнең буеннан-буена мәтәлчек атып йөрүче ташбаш малайны да: «Безнең малай», — ди. Танымыйлармы соң Әлфия апаларын?! Гөж килә халык. Мин инде яраткан тамашачым белән кабат очраштыручы Салаватка рәхмәтләр укыйм. Аңа нәрсә сөйләсә дә килешә. Шулай да халыкның аңлаганы бар, аңламаганы бар, концерттан соң, сәхнәгә менеп: «Сез чыннан да өйләнештегезме?» — дип сораучылар да булды. «Өйләнештек, — дидем, — өйләнешмәслекмени? Егете таш астыннан чыккан бит. Минем дә төс-кыяфәт, килешкилбәт ничаво». Салават та: «Өйләнештек», — ди. Әби булырга җыенганым юк, әби булып күренмим дә. Сәхнәдә мин гомер буе мәхәббәтле булдым. Мәхәббәтле җырчы булып олыгайдым да. Бу инде бик зур бәхет. Хәзер менә күп җырчыга мәхәббәтлелек җитми. Салават та мәхәббәтле. Аның да сәхнә иҗаты озынозак һәм бәрәкәтле булыр. Бик тырыш бит ул. Любой җирдә авторитеты бар. Репертуар өстендә бик нык эшли. Халтураны җене сөйми. Живой җыр булсын аңа.

Пермьнән Свердлауга барганда, Салаватның туган авылы Аксәеттә тукталдык. Хәтердә мәңге җуелмас хатирә булды ул. Элегрәк тә булганым бар иде ул авылда. Авыл танымаслык хәзер. Салават үзе генә дә туган-тумачаларына биш йорт җиткергән. Ләйсәннең әти-әниләре дә шул ук авылда яңа йортта яши. Салават дус-ишләрен, классташларын, гомумән, авылдашларын аш мәҗлесенә җыйды. Табын ишегалдына мулдан әзерләнгән иде.

Бу гастрольдән кайткач, Салаваттан: «Тагын гастрольгә алып чыгарга онытмассыңмы мине?» — дип сорадым. «Әлфия апа, бер ел эшлә әле безнең белән, — диде Салават. — Бер ел булырмы, ун ел булырмы, күз күрер», — дип тә өстәде. Гастрольләргә чыгам, чыкмый ни — автобуслары йомшак, тирбәтеп кенә алып бара, Салават үзе мине үсендереп, көч, энергия биреп тора.

Хатыны Ләйсәнгә дә зур рәхмәт. Кыйммәтле тун бүләк итте. «Әлфия апа, ки әле шуны рәхәтләнеп!» — ди. Мин аларга исәнлек телим, балаларының игелеген күреп яшәсеннәр.

Врачлар мине ерак юлга чыгудан тыйганнар иде. Инсульт та бетте, рак та юкка чыкты. Салават белән бергә «Картаямыни соң йөрәк...» дип рәхәтләнеп җырлап йөрим хәзер. Без бит икебез дә Кәҗәмөгезләр. Аның туган көне гыйнварның унысында, минеке — унбишендә. Тиз кызып китәбез, аннан тиз генә сүнәбез дә. Ачу сакламыйбыз. Ходай эш өчен яраткан инде безне.

— Мировой ул безнең Әлфия апа, — дип сүзгә кушыла Салават. — Яз айларында Себергә чыгып китәргә торабыз. Авырыйсың булса, шуңарчы авырып бетер, дидем.

Салаватның үзенә килгәндә исә, туган көнен ул орденлы Салават буларак каршылады. Рәсәй Мөфтиләр Шурасының иң югары бүләге — «Әл-фәхер» дип исемләнгән II дәрәҗә Почет ордены белән бүләкләнде. Орден халыкка, милләткә тугрылыклы хезмәт иткәннәргә, мәдәниятне үстерүгә зур өлеш керткән эшлеклеләргә бирелә. Орден белән беренчеләр рәтендә Мәскәү мэры Юрий Лужков бүләкләнгән. Хәзер менә Салават. Бүләкне Мәскәүдә концерт барышында мөфти Равил Гайнетдин халык алдында тапшырган.

*«Ватаным Татарстан»*
*9 гыйнвар, 2004*

**РӨСТӘМ МИНГАЛИМ**

# Әлфия Авзаловага

*Әлфия Авзалованың җитмеш*
*яшьлеге уңаеннан*

Бу арада Казанда гел бер хәбәр:
— Әлфиягә 70 яшь җитмеш! — диләр.
Ну, ялган да сөйли инде бу халык.
Мин дә бераз сөйлим әле
Әлфиягә туктальп:
— Бисмилләһир-рахманир-рахим дип
Башлыйм сүземне.
Иншалла,
җитәрмен азагына.
Дәва булып милләте ярасына,
Актанышта туган Әлфия Авзалова —
Нәни генә көмеш чишмә булып ул
Тизүк Казан тарафына йөгергән,
Тиз арада ил корабы кереп тирбәлерлек
тирән дәрья булып өлгергән.

Зур бер залда карап тордым
Җырлаганын, атлавын.
Сәгать ярым карап тордым,
Җитмешлеген тапмадым.

Әлфияле Казан кала гына түгел,
Ул — моңнар башкаласы.
Әлфия Авзалованы
Һәм моңнар башкаласын
Ходай рәхмәтеннән ташламасын!

*Казан*
*2003–2006*

## АВТОРЛАР ТУРЫНДА БЕЛЕШМӘЛӘР

***Минтимер Шәймиев*** — Татарстан Республикасы Президенты.

***Әхмәт Рәшит*** — шагыйрь, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.
***Рабит Батулла*** — язучы, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.
***Мөхәммәт Мирза (Илфак Ибраһимов)*** — шагыйрь, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.
***Рәниф Шәрипов*** — шагыйрь, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.
***Гариф Ахунов*** — Татарстанның халык язучысы.
***Илдус Ахунҗанов*** — әдәби тәнкыйтьче.
***Хәлим Гайнуллин*** — журналист, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.
***Рәйсә Юсупова*** — журналист, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.
***Ислам Галин (Ислам Әхмәтҗанов)*** — журналист, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.
***Мирһади Разов*** — шагыйрь.
***Алсу Кадыйрова*** — журналист.
***Айрат Арсланов*** — Татарстанның һәм Русиянең халык артисты, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.
***Гөлшат Зәйнашева*** — шагыйрә, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.
***С.Галиева*** — журналист.
***Флора Әхмәтова-Урманче*** — фольклорчы, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.
***Рәшит Сабиров*** — Татарстанның халык артисты.
***Илһам Шакиров*** — Татарстанның һәм Русиянең халык артисты.
***Мирхәт Мәрдәнов*** — журналист.
***Анна Мусатова*** — журналист.
***Кирам Сатиев*** — баянчы, Татарстанның атказанган артисты.
***Фәния Хуҗиәхмәтова*** — журналист.
***Рәйсә Яхина*** — журналист.
***Харрас Әюп*** — шагыйрь, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.
***Ләйлә Дәүләтова*** — шагыйрә.
***Нәсих Таҗиев*** — журналист.
***Рәмис Аймәт*** — шагыйрь.
***Таңчулпан (Чулпан Әхмәтова)*** — шагыйрә.
***Фирүзә Җамалетдинова*** — язучы.
***Резидә Даутова*** — журналист.
***Эльмира Сәләхова*** — журналист.
***Айслу Кадырова*** — журналист.
***Земфира Гыйльметдинова*** — журналист.
***Фәндидә Харрасова*** — шагыйрә.
***Резидә Шәрәф*** — журналист.
***Габделбәр Ризванов*** — журналист, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.
***Рөстәм Мингалим*** — язучы, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.

**ЭЧТӘЛЕК**

*Минтимер Шәймиев*. Бәхет кошын тоткан кыз
*Мөхәммәт Мирза*. «Ак пароход көтеп алдым...»

*Рабит Батулла*. Якты йолдыз гасырларда балкыр
Дуслык
Каен җиләге
Беренче кинотасма
Карлыгач җыры
Җанатар
Кич утыру
Тәнәкәй
Җыр-моң турында
Якташлар, теләктәшләр
Бозылган ураза
Шомырт кызы
Аерылышу
Беренче никах
Икенче никах
Шөһрәткә таба
Бер чемодан җон оекбаш
Беренче ялгышу
Рәшиткәем минем
Иҗат берләшмәсе
Гөлҗамал
Бер рәхмәт йөз баладән коткарыр
Йосыф
Миһербан ияләре
Гүзәллекнең сере

*Әхмәт Рәшит*. Нурлы җырлар белән
*Рәниф Шәрипов.* Әлфия Авзалова
*Гариф Ахунов*. Филармониянең бер концертында

*Илдус Ахунҗанов*
*Хәлим Гайнуллин*. Рухи бергәлек
Сөем — ...
*Рәйсә Юсупова*. Күктә йолдызлар атыла
*Ислам Галин*. Һаман синдә күңел
*Мирһади Разов*. Рәхмәт сиңа, җыр!
*Алсу Кадыйрова* . «Аны халык кушаматы аша белә...»
*Айрат Арсланов*. Татарның моңлы кәккүге
«Очрашырбыз әле җыр аша...»
*Гөлшат Зәйнашева*. Халкыбызның сөекле кызы
*С.Галиева*. Голос, трогающий душу
*Флора Ахметова-Урманче*. Народная артистка
*Рәшит Сабиров*. Аны халык үзе үстерде...
*Илһам Шакиров*. Күгебездәге якты йолдыз
*Мирхәт Мәрдәнов*. Халкыбызның моңлы кошы
*Анна Мусатова* . «Я вам спою еще на бис...»
*Кирам Сатиев*. Уртаклык
*Фания Хузиахметова*. Сама мелодия
*Рәйсә Яхина* . «Яшьлегемә кире кайтыр идем...»
*Харрас Әюп*. Сандугачлар ызгышмый...
*Ләйлә Дәүләтова* . «Бәхет — ир белән тору гына түгел...»
*Нәсих Таҗиев* . «Миннән дә бәхетле җырчы юк!»
*Рәмис Аймәт*. Казанны шаулаткан бер көн
*Таңчулпан* . «Мин сезнеке инде...»

*Хатлар* . «Чибәр түгел, мәхәббәтле булдым...»

*Фирүзә Җамалетдинова*. Халыкның нәкъ үзе кебек ул
*Резеда Даутова* . «Пусть люди помнят, какой я была...»
*Эльмира Сәләхова*. Әлфия апа сәхнәдән китәргә җыенмый
*Айслу Кадырова* . «Хаха-михаха» — это не про меня, я всегда говорю правду...»
*Земфира Гыйльметдинова*. Рәхмәт, Әлфия апа!
*Фәндидә Харрасова*. «Җырларымда калсам иде...»
*Резидә Шәрәф* . «Картаямыни соң йөрәк, маңгайлар сырланса да...»
*Фәния Хуҗиәхмәтова* . Ап-ак атларга атланып төшләргә кергән егет
*Габделбәр Ризванов*. Таш астыннан чыккан Салават
*Рөстәм Мингалим*. Әлфия Авзаловага

Авторлар турында белешмәләр

*Китапта А.Авзалова архивындагы фотолар һәм Рушан Шәмсетдинов фоторәсемнәре файдаланылды.*

Литературно-художественное издание

## Альфия Авзалова

Составитель **Батуллин** Роберт Мухлисович

Казань. Татарское книжное издательство. 2007

На татарском и русском языках

Әдәби-нәфис басма

## Әлфия Авзалова

Төзүче **Батуллин** Роберт Мөхлис улы

Мөхәррире *Р.М.Касыймова*
Рәссамы *Р.Г.Шәмсетдинов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Т.В.Гредюшко*
Корректорлары *Г.Н.Галимуллина, Г.Х.Сундукова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 31.07.2007. Форматы 70x100 $^{1}/_{16}$.
Офсет кәгазе. «School Book» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 17,55 + форз. 0,33.
Шартлы буяу-оттиск 72,15. Нәшер-хисап табагы 16,97 + форз. 0,53.
Тиражы 3000 д. Заказ С-845.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
http://tatkniga.ru e-mail: tki@tatkniga.ru

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.